## Сайланма әсәрләр

**Өч томда**

# 2 том

**Шигырьләр, поэмалар**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г24
**Гаташ, Р.К.**

Сайланма әсәрләр : 3 томда / Рәдиф Гаташ ; кереш сүз авт. Р.Зәйдулла. – Казан : Татар. кит. Нәшр., 2009.
ISBN 978-5-298-01864-7
2 т. : шигырьләр, поэмалар. – 2009. – 271 б.
ISBN 978-5-298-01866-1

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ әсәрләренең бу томына шагыйрьнең, нигездә, узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларда дөнья күргән шигырьләре, «Европада татар шагыйрьләре», «Күңелдә ике яз», «Гомер уртасыннан хатирә» һ.б. лирик, публицистик цикллары һәм туксанынчы еллар башы иҗатындагы үзгәрешләрен чагылдырган «Шәрекъ чоры» шигырьләре туплап бирелде.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01866-1 (2 т.)
ISBN 978-5-298-01864-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2009

© Гаташ Р.К., 2009

### МАТУРЛЫК ЭЧКӘН КҮЗЛӘР

Шигырьне аңлау өчен җанның ниндидер галәми авазларга көйләнүе кирәктер, мөгаен. Шагыйрь, сәмави нурларны үзе аша үткәреп, аларны кешеләрнең йөрәкләренә юллый. Кемнәрнеңдер йөрәк урынына амбар йозагы йөртүендә эше юк аның. Әмма гамьле шагыйрь өчен гавамның шул саваплы нурланышын тоймавы гомуми илкүләм фаҗигагә тиң...

Шигърият орлыгы сабыйлыкта, яшьлектә салынса гына, олыгайгач та аның ябалдашыннан йолдызлар коела ала.

Шүрәле күрергә өметләнеп урманга барулар истә. Кышкы төндә өй почмагында сызгыручы – җил түгел, серле әкият пәриләре.

Кеше шагыйранә туа — йөрәге ачык килеш!

Шул байлыкны без олыгая-олыгая җуя барабыз – үзебез үк уйлап тапкан кысалар эченә сыймый кала ул! Мөгаен, өлкәнәйгән шагыйрьләр юкка гына биртелгән күз карашларын гомернең шул чагына төбәмиләрдер:

Матурлык эчсен күзләрем яшьлектән! –
Байлыктан бит зәкят алу ярыйдыр?

Рәдиф Гаташның күзләре тирә-юньнән гел матурлык эзли. Сызылып аткан таңмы ул, йолдызлар яңгырымы, гөлләрнең керфек кагуымы, чибәр туташның сүзсез ишарәсеме – шагыйрь барысын да күңеленә сыйдыра, шул ләззәтне безнең белән дә уртаклашасы килә.

Гаҗәпләнү хисен җуймау – шул бит инде шагыйрьлек!

Ләкин аның иң нык гаҗәпләнгәне – кешеләрнең күбесе әлеге матурлыкларга битараф икән бит, кем таң чыкларына чыланып, болын гөлләреннән сәрхуш бүген?

Моның өчен дә Тәңре биргән сәләт кирәк.

Сөю илтәм сиңа! Шуңа
Мин — талант, көчле талант...
Әй, горур гүзәл!
Шагыйрьне
Шул талант өчен ярат!

Ихлас бер табигать баласы булып килеп кергән икән татар шигъриятенә Рәдиф агабыз. Һәм бүген инде рәхәтләнеп икърар итеп була – ул нәкъ шул килеш калган да. Аның өчен шигърият идея-фикерне кемнәргәдер җиткерү коралы да, җәмгыяви баскычта ниндидер бер кунача тиенү чарасы да түгел... Шигырь юллары аша капшана-капшана кешеләр күңеленә матурлык эзләп юнәлә ул.

Шигырь юлының рәсми юллар белән уртаклыгы юк.

Сазлыклар сагалап торган чытырманлыкларны ерып барасың да барасың, йолдызларга карап юнәлешне билгелисең...

Ялгыз син, һәм тәгаен беләсең: барып җитәсе тиягең дә – Ялгызлык...

Тоталитар система шартларында коргаксыган татар шигърияте бакчасында яңгыраган беренче авазлары белән үк яшь шагыйрь күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Гөлләр су сорыйлар! Аның самими, якты аһәңнәре кипшенгән гөлләргә гүяки әллә кайдагы таңнарның җиләс һавасын алып килә. Шагыйрьнең көчен катлаулы метафоралар, шаккатыргыч чагыштырулар билгеләми, аның көче ихласлыкта, җан хөрлегендә, күңел күгенең биеклегендә. Шигырь алдашуны кичерми. Хөсетле уйлар биләгән күңелдә дә яхшы шигырьләр туа ала, әмма ул беркайчан да җан авазына әверелмәячәк.

Гасырлар дәвамында чарланган халык җырлары беренче ишетүдә үк җанга ята, челтерәп аккан чишмә сулары кебек үтә күренмәле гади дә, тешкә тиеп сискәндерә дә алар. Шуңа аларны бүтән телләргә тәрҗемә дә итеп булмыйдыр.

Шулай да шагыйрьнең иҗатын тирән кое белән чагыштыру кулайрактыр. Төбендә җир куенындагы ком-ташларның салкынлыгын, борынгылыгын үзенә сеңдергән су тын гына сулый... Кем ирененә тияр ул? Әмма...:

Зәңгәр кое яннарыннан
Синдә тик китү уе;
Минем сыман авыр сулап
Шыгырдап кала кое.

Совет поэзиясе багларында мондый саф тавыш ул замандагы «бакчачылар»ның күңеленә хуш килеп бетми, әлбәттә. Кайда монда социаль яңгыраш, хезмәт кешесенә дан җырлау, КамАЗ төзелешен мактау?

Польша халык республикасына барыр алдыннан ниндидер комиссиядә Зөлфәткә сорау биргәннәр, имеш. «Шигырьләр язу ярый, тик син берәр иҗтимагый эштә катнашасыңмы?» «Шигырьләр язу иҗтимагый эш түгелмени?» – дип гаҗәпләнгән ихлас күңелле Зөлфәт. Янәсе, хезмәт кешесе аның шигырьләрен укып рухланса, ул да социалистик ярышка үзенең өлешен кертә.

Билгеле, һәр җыелышта, һәр басма сүздә «социаль яңгыраш», коммунистик җәмгыятькә тугрылык таләп итеп даими тукып торганда, шагыйрьләрнең күбесе әлеге афәттән котыла алмады. Рәдиф Гаташның да андый тезмәләре шактый. Биредә аларны кабатлап тору кирәк микән? Ләкин гаҗәп хәл – аның бу әсәрләре ризасызлык, ачу түгел, ә елмаю уята иде. Мәсәлән, «Мактаулы дөньяда» дигән шигырьне укыгач, ничек рәхәтләнеп елмаймыйсың? Шагыйрь Лондонда хатыны белән «Кеннеди һотеле»нә урнаша. Йокларга яткач, «дивар аша ишетелде тавышлар, акырышу, ят авазлар, ят сүзләр...» Күрше бүлмәдә хәтта янгын чыга яза. Нишлисең, капитализм... Шагыйрь, әлбәттә, хатыны белән бергә моңа бик нәфрәтләнә: «Шулмы, дидек, бөек Британ иле? «Мактаулы киленең», «Көнбатыш, шулмы инде?» Шигырь гаҗәеп гыйбрәтле тәмамлана: «Ун көн буе сагындык Туган илне, хәтерләп шул төнне – «Кеннеди-отель»не!»

Тик шагыйрь шуны истән чыгара – күрше номерда бит аның кебек үк туристлар яши. Бәлки, алар аның сагынычлы туган иленнән үк булганнардыр әле.

Сандугач, саесканнарга ияреп, аларча чырылдый башласа, башта, әлбәттә, көләсең. Аннары...

Юк, барыбер җитди кабул итеп булмый Р.Гаташның мондый иҗат юнәлешен. Әлеге шигырь дә ул замандагы газеталарны тутырган «ватанпәрвәр» тезмәләргә бер пародия сыман яңгырый.

Ләкин мин аңлыйм, шагыйрь аны чын күңелдән язган. Кемне-кемне, Рәдиф агайны рияда, икейөзлелектә гаепләп булмый, һәм күпмедер еллар үткәч, шул әсәрләре өчен шагыйрьнең үз-үзен кырыс хөкем итүе табигый. «Йа Ходай, бу минме? Ничек шулкадәр самими рәвештә, беркатлы хисем бу коммунистик атрибутларга төренгән соң әле? Нишләдең син, ихлас җаным, шагыйрь җаным?» дип өзгәләнеп яза ул. Ләкин «алар – минем гомер, минем язмыш. Хәзер алардан баш тартып та, юкка чыгарып та булмый».

Чын шагыйрьләр һәрвакытта үз-үзләренә аяусыз!

Ялган идеология җәтмәсе һәрвакыт самими җаннарны аулый. Без барыбыз да шул җәтмәнең корбаны түгелмени?

Шөкер, Рәдиф Гаташ та ул сазлыкны исән-имин гизеп чыкты. Шигырь юлы – үзе ышанычлы сукмак!

Сары яфраклар коела, яз килүгә агачны тагын яшел ялкын чорнап ала – тамырларың гына сау булсын. Ә алар халкыңның күп гасырлык шифалы катламнарына тоташкан. Шуңа күрә Рәдиф агайның шәрекъ шигърияте биләмәләренә кайтуына гаҗәпләнәсе түгел. Кандалыйларның, Тукайларның җан сыкравыннан тернәкләнгән татар шигърияте төрле төсләргә кереп балкыган шәрекъ дөньясының аерылгысыз өлеше бит. Һәм әлеге күренмәс җепләрнең беркайчан да өзелгәне юк. Рәдиф Гаташның яңа бер әверелештә шигърият мәйданында пәйда булуы, газәлләр һәм робагыйлар белән сөендерүе моны үзе үк раслап тора лабаса.

Хәер, әверелеш микән соң бу? Шагыйрьнең иҗатын игътибар белән күзәтсәк, аның шәрекъ әдәбиятына беркайчан да битараф булмавын күрербез. Шигырьләренә сибелгән бихисап бөек исемнәр арасында фарсы-төрки шагыйрьләренең намнарын очратып та, Нәсимидән тәрҗемәләрен укып та Р.Гаташның шәркый мирасны һәрвакытта күз уңында тотуын хәбәрдарлар яхшы белә. Ләкин татар кояшының чыгышын гел көнбатыш яктан гына көткән заманда, ә шәрекънең томаналыгын көн саен сүгеп торганда, әлбәттә, шагыйрь әйтмешли, «җырыңның бугазына» басмый мөмкин түгел иде. Аны Язучылар берлегенә тәкъдим иткәндә, Әхсән Баян турыдан-туры әйтә: «...баштарак мине аның Көнчыгыш поэзиясе белән мавыгуы борчый иде, ләкин хәзер күрәм: аның үз тавышы матур, табигый». Әйтерсең үзенчәлекле тавыш Көнчыгыш поэзиясе биләмәләрендә яңгырый алмый.

Минем үземә шигъриятне Көнчыгышныкына яки Көнбатышныкына бүлү бераз урынсыз да булып тоела. Есенин шәрекъ шагыйреме, гарепнекеме? Ә Гете? Гомәр Хәйям әлегә кадәр Көнбатышта иң күп укыла торган шагыйрь түгелмени?

Бөтен шагыйрьләр дә бер кавемнән. Хыял иленнән!

Шагыйрьнең кояшы көнбатышта калкып, көнчыгышта баерга да мөмкин.

Милли рух шигырьне егәрле итә. Бу җәһәттән Рәдиф Гаташ чын татар шагыйре. Шуның белән ул безгә кадерле дә.

Ул – дөньяваклыкларына бирелмичә шигырьдә яшәүче, шигъриятнең могҗизаи кодрәтенә чын күңелдән ышанучы соңгы могиканнарның берсе бугай. Шул шаукымны бүтәннәргә дә йоктыра белгән остаз да әле ул. Уразмәт мәктәбендә аның күпмедер укытып алуы татар әдәбияты өчен гаять уңдырышлы булды. Аңа ияреп, Казанга әдәби үрләрне яуларга дип, укучылары Зөлфәт, Наис Гамбәр, Фәрит Гыйльмиләр килде.

Шул елларны искә алып, киләчәккә өметләнеп, Зөлфәт болай яза: «Иртәгесе көн сабыйлары, бәхетегез булып, сезгә дә яңа укытучы – тере шагыйрь килсен! Бу – олуг бәхет. Ачылсын күңел күзләрегез! Ул күңелләрегезгә бөек шаукым – мәхәббәтле шигырь шаукымы салсын!»

Бу язмаларымны миңа, бәлки, «Зөлфәтнең хәлфәсе» дип атарга кирәк булгандыр?

Юк, Рәдиф агайның бүтән шәкертләре дә һич ким-хур түгел – Наис Гамбәр искиткеч нечкә зәвыклы шагыйрь,

эссеист, ә Фәрит Гыйльми исә Мөслимчә сыгылмалы телгә ия үзенчәлекле прозаик иде. Фаҗигале рәвештә иртәрәк китте...

Газинур Морат та яшьлегендә Рәдиф агайдан күргән хәер хаһлыкны даими искә ала.

Хәер, Зөлфәт кебек үк, мин дә аны «хәлфәм» дип атый алам. Кече яшьтән үк мин аңа олау-олау шигырьләр җибәрә идем, ул мине хуплап, кирәк чакта салпы якка салам кыстырып, кирәк чакта битәрләп тә хатлар язып тора иде. Менә 1977 елның 1 феврале белән билгеләнгән бер мәктүптән өзек: «Тагын да шомара төшкәнгә охшыйсың: инде образлы фикерләү дә бар синдә, кыю да, шигъриятне үз итеп тә сөйләшә аласың. Киләчәктә, шиксез, тагы да зуррак үсеш, үзгәреш күреп булачак синдә!

Әлбәттә, бу ике шигырьне дә әле журналга биреп булмый: аларда синең яшеңә, синең кичерешләреңә, халәтеңә хас булмаганча олыларча, өлкән шагыйрьләргә ияреп язу сизелә. Ә болай шигырьләр форма, тел ягыннан уңышлы гына. Алар синең шигъри сәләтең барлыкны раслыйлар. Молодец!»

Шундый хат алгач, ничек тагын шигырь язмыйсың? Иң мөһиме, Рәдиф агай кайбер мөхәррирләр кебек машинкада күбәйтелгән шаблон җавап җибәрми, хатын кулдан яза. Әле шигырьләр журнал («Казан утлары») өчен өлгереп җитмәгән икән, зарар юк, шундый зур шагыйрь өметле сүз әйткәч, кайчан да булса өлгерер, һәм Казан тарафларына яңа шигырьләр тулы калын конверт оча...

Каләм тибрәтүче әллә кайдагы бер малайга киңәшләр биреп, сәләтенә ышандырып шундый эчтәлекле хатлар язып тору өчен шагыйрь булу гына җитми, киң күңелле кеше булу да кирәк. Хәер, киң күңеллелек шагыйрьлекне билгели торган төп сыйфаттыр, мөгаен.

Казанга килгәч тә, бүтән иптәшләрем кебек үк, яңа шигырьләремне мин иң элек аңа алып килә идем. Үзе дә безнең белән аралашырга ярата иде бугай. Безгә инде ул бөтенләй бүтән дөнья кешесе булып тоела. Шигырьләрендә – Париж, Лондон, Истанбуллар... Шотландиядән кайткач – туган илне сагынып үткәргән теге ун көнлек сәфәрдән түгелме әле? – ул миңа Аллоуэй авылында Роберт Бернсның музей-йорты түбәсеннән йолкып алынган бер уч салам да бүләк иткән иде. Һай, егетләр, андый бүләк теләсә кемгә эләкми ул... Шотланд саламы минем маҗаралы юлларымда әллә кайчан инде коелып калды, ләкин Бернс шигъриятендәге басулар исе һаман җанымда...

Көннәрнең берендә ул безне Аккош күлендәге язучылар бакчасына чакырды. Анда аның тавык кетәклеге кадәр генә йорты бар икән. Ләкин Ләис Зөлкарнәй белән миңа әлеге йорт хан сараеннан да затлырак тоелды. Шагыйрь хөҗрәсе бит! Ләкин хөҗрәнең ишеге авышкан, чабуы җирдән сөйрәлә, ачылса, ябылмый, ябылса, ачылмый иде. «Сез, егетләр, авылдан яңа гына килгәнсез, балта-пычкы тота беләсездер, рәтли алмассызмы ишекне», – диде шагыйрь. «Була ул, – дидек без, бертавыштан, – җырлап ачылачак!» Һәм без мәнсез ишекнең чабуын кисеп тә алдык. Ул уңышсыз верлибрга охшап калды.

Икенче килүемдә Рәдиф агай мине Хәсән Туфан янына да алып керде. Ләкин бераздан, икебезне генә калдырып, үзе тиз генә чыгып та китте. Мин ике шагыйрьнең арасындагы киеренкелекне тоеп калдым. Хәсән Туфан иректә шигырьләрне бер дә өнәми иде. Югыйсә үзе яшьлегендә андый нәрсәләрне бик күп язган кеше. Татар шигыренең калыбына шактый соң керә ул... Шуңа күрәме форма җәһәтеннән эзләнүчеләргә шактый килешмәүчән караштa тора иде мәрхүм...

Рәдиф Гаташ та олыгая төшкәч кысага керде. Бу җәһәттән аның язмышы Туфанныкына охшаш. Шигъри сүзнең мең еллар дәвамында сыналган үз үлчәме бар. Вәзен... Шунда гына бәргәләнә, баш күтәрә, шигырьгә әверелә сүз. Йөрәк тә үз калыбы эчендә генә тибә ала бит...

Рәдиф агай бүген дә яшь иҗатчыларга хәер хаһ. Ул аларга яхшы сүзен кызганмый, кереш сүзен язып газета-журналларга тәкъдим итә. Үзе дә күп яшьләргә юл ачкан Илдар Юзеев (авыр туфрагы җиңел булсын!) бу турыда менә ни яза: «Аның шашкын табигатенә үзләренең нәфис җаннарын шигырьдә ачучы кызлар бигрәк тә якын. Шигърият остаханәсендә дә, үзе эшләгән «Казан утлары»ның шигърият бүлегендә дә күпме шагыйрьләрне әдәбият мәйданына чыгарганын мин яхшы беләм. Кызлар да рәхмәтледер. Берәр яшь авторның әйбәт шигырен укыса, сабый бала кебек сөенгәнен күрсәгез иде! Егетләр өчен дә шулай сөенер иде, кызганычка, алар сирәк килә шул».

Әйе, соңгы елларда каләм тибрәтүче яшьләрнең барысы да диярлек кызлар. Дөрес, дөнья әдәбияты тарихыннан беләбез – шигърият тирәсендә һәр заманда да алар күп булган. Беренче мәхәббәт очкыннары, табигый ки, шигырь учагын кабызучан. Урыс шагыйре Юрий Кузнецовның гыйбрәтле сүзләре бар: «Женщина, когда пишет, смотрит на мужчину, а мужчина – на Бога». Әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләр үзләре дә хатын-кыз язучыларның иҗатына туры бәяне бирүдән тайчаналар. Җыелышларда, телмәрләрдә, мәкаләләрдә хатын-кызлар шигъриятенә аерым тукталу, бәя биргәндә «хатын-кызларга хас нәфислек белән» дигән гыйбарәне даими куллану, аларның иҗатына, әлбәттә, ташлама ясау билгесе. Беркемгә дә сер түгел, Гете, Пушкин, Блок кебек шагыйрьләр хатын-кыз шигъриятенә көлемсерәп караганнар.

Мин фәкыйрь дә моннан ун еллар элгәре, бер җыелышта «Табигатьтә ата сандугачлар гына сайрый» дип белдереп, хатын-кызларыбызның ачуын китергән идем.

Табигать белән бәхәскә керү җүнлегә илтми. Иң әүвәл шигърият тә, сандугач сайравы кебек үк, сөйгән кызның йөрәген яулау өчен яңгыраган... Ләкин бүген кем генә шигырь белән хатын-кызның күңелен аулый икән... Сөйгәненең балкон төбендә төннәр буе серенада җырлап торган кавалерны кайда күргәнегез бар? Шигърияткә хәзер егетләрнең килмәвен, бәлки, шул үзгәрешләр белән дә аңлатып буладыр? Хатын-кыз сандугачларның сайрый башлавы табигый...

Яшь кызларыбызның шигырьләрен укыгач, сөенми мөмкин түгел. Нәкъ Рәдиф агай язганча, «табигатьнең үзе тудырган эчкерсез, саф сулышлы, курай тавышы кебек садә, ә кайчакта заманыбыз кебек көтелмәгән борылышлар, аһәңнәр белән сискәндерүче ихлас, якты авазлар».

Күрәсең, татарның Ватанын, сабыйларның телен һәм шигъриятен бары тик хатын-кызлар гына коткарып калачак заманалар тагын җитте...

...Шул заманалар һәм кызлар турында сөйләшеп нәшрият йортының лифтында өскә күтәреләбез. Кайсыдыр катта безнең янга бер чибәр туташ керде. Рәдиф агай гадәттәгечә кулын өскә чөеп аңа эндәште: «Бәхетлеме сез, кадерлем?!» Һәм җавапны да көтеп тормастан: «Ә менә бу егет шагыйребез Ркаил була», – дип, мине таныштырды. Мин уңайсызланып керфекләремне төшердем. Туташ чыгып киткәч, Рәдиф агайдан: «Кем иде ул?» – дип сорадым. «Кыз!» — дип җаваплады шагыйребез. Бу, әлбәттә, төгәл җавап иде.

Келт итеп аның бер шигыре искә төште:

Гөнаһлымын:
бик ошаттым парижанкаларның үзләрен.
Аларга татарчалап:
– Сез искиткеч гүзәл! – дидем.

Әйткәндер... Болай эндәшү нәкъ Рәдиф агайча, һәм ул аңа килешеп тә тора.

Бүген мин аңа: «Бәхетлеме син?» – дип сорау бирмим. Бөтен күзәнәкләреннән моң ташып торган кешегә мондый сорау бирү мәнсезлек булыр иде.

Шигырьгә андый сорауны бирмиләр...

*Ркаил Зәйдулла*
*Гыйнвар, 2005*

# *I. Тел ачкычлары*

***(1972–1978)***

## ТЕЛ АЧКЫЧЛАРЫ

Бала чакның бер ядкяре –
Карт әбкәмнең теләкләре.
Һаман истә тотам берсен:
– Дөнья бездән калыр, бәбкәм,
Инде тегесендә менә
Тел ачкычкайлары бирсен! –
Сиңа, миңа...

Тел ачкычы!..
Газиз әбкәм, шушы сүзең күңелемдә
Күпме еллар яңгырап торды.
Белсәң иде,
Андагысын уйлаган юк,
Бу дөньяда оныгыңа
Ачкыч бик еш кирәк булды!

Күпме яшерен серләр, сүзләр...
Чит телләр йә чит күңелләр...
Күпме ишек, күпме йозак!
Кешеләр дә
Йә лабиринт,
Йә бер җомак...
Тормыш гүя бер сфинкс,
Гел җавабын тора сорап...

Әй сез, яшәү баскычлары!
Һәр адымда
Кирәк икән ачкычлары!
Яшәр идем! Дөньяда мин
Телсезләрне телле итәрлек,
Юньсезләрне юньле итәрлек,
Чукраклар да ишетерлек,
Авыруларны терелтерлек
Сүзләр табып,
Сөйләр идем иртә-кичен.
Әбкәм, синең доган миңа
Шул тел ачкычларын бирсен!

Әмма мәкер-хыянәттә
Халкым бәхетен урларга
Дошман кора калса авын;
Мин белмәсәм,
Сер сөйләргә әзерләнсәм,
Бирә белгән кырә белсен –

Ачкычларын кире алсын!

## ГӨЛЛӘР ЕЛЫЙ, УЛЫМ...

Нәни улым, күземә карап сөйлә:
– Тимим, димсең, гөлгә?!
Әбиең әйткән: – Чәчәкләрен өзсәң,
Гөл ул елый, үлә...

– Гөл елыймы, әтием? – дисең. – Чынмы?!
Нәрсә әйтим сиңа...
– Гөл елый шул, улым, бик нык елый,
Өзмә аны, тимә.

Елатма! Гөл елый. Җирдә, белсәң,
Бөтен нәрсә елый.
Таш җанлылар гына үлән-чәчәк
Тоймый диеп уйлый.

Болытларның салкын яше тама,
Таулар иңри, түзми.
Елгаларның күңеле тулып таша,
Бөгелеп, таллар үкси.
Кеше елый бик еш! Дөнья булгач,
Нинди чагың булмый...
Кайгы-шатлык, гарьлек-гамьнән елый...
Ир – эченнән елый.
Елый белү, улым, әйбәт нәрсә!
Яшь юшкынны юа.
Ярасына, нәфрәтенә дәва
Таба шулай дөнья.
Шулай, улым! Яшькә тула калса
Беркөн ике күзең,
Ела... Ләкин елак дип атама
Бу дөньяның үзен.
Кеше булсаң, яшьләреңне сөртеп,
Юатучы була.
Юанырсың... Тик бел бәләкәйдән
Елатучы булма!
Елатучы булма! Бик сак кагыл
Үләннәргә, гөлгә.

Гөл елый ул. Җирдә бөтен нәрсә
Шулай елый, көлә,
Хәтта үлә белә!

## УЕЛ

*Х.С-га*

Күпне күргән сиксән яшьлек әби
Бер җырлады безгә «Уел»ны;
Күзләр коры иде, тавышындагы
Яшьләр гүя җанга коелды...

Агыйделнең көләч ярларында
Шатлык иле – Илеш ягында,
Тарих, бәлки, безгә очрагандыр
Аһәңнәре, моңы сагында.

Уеп алды гүя йөрәгеннән
Ераклардан килгән сагышны –
Агыйделнең үзенә охшап акты
Халык моңы, җаны, тавышы.

Җилләр исте... Батыр ирләр үтте,
Илләр үтте кичеп уемнан;
Ил язмышы йөрәкләргә безнең
«Уел»лары белән уелган.

Бар булганы белән халык җаны
Яшеренгән шушы моңнарга...
...Ятим моңнар, ятим җырлар булмас
Халык яшәгәндә, ил барда.

Озата бара киләчәккә шулар...
Онытып буламыни үткәнне? –
Заман үзгә, тормыш үзгә, яңа,
Ә чын җырлар – иске, күптәнге...

## КУНАК

Кичә генә кунак идек без дә...
Ә нинди ул кунак?
Тыйнак булу таләп ителгәндә,
Булдык микән тыйнак?

Сабыр булып, өлкәннәргә карап,
Уйлап, акыл җыйнап
Яшәдекме ул чак?.. Киресенчә...
Бүген менә – тыйнак:
Давылланып, күккә очмый йөрәк,
Дөнья күпкә тынрак.
Үзгәртердәй, үзгәрердәй чаклар
Әллә кайда, ерак...

Көлү – элеккечә көлү түгел,
Сирәк чыга яшь тә...
...Уйлыйбыз: әй, як-ягыңа кара,
Нәрсә әйтер яшьләр?

Ә аларның туры әйтер чагы...
(Без дә булдык кунак!)
Кемгә тыйнак булу килешми дә,
Булмасыннар тыйнак.

Ә без – хуҗа, бәлки. Әдәп белән
Мактый белик, тыңлап.
Һәм кушылыйк, көйне бозмас өчен
Эчтән генә җырлап...

Гаеп итсә, хәмер түксә дә бит,
Кунак – барыбер кунак.
...Хуҗа була белеп утырыйк әле,
Булыйк әле тыйнак!

## СӘЛАМ

Уралларга барсаң, туктал, болыт,
Уфаларга туктап сәлам әйт:
Ат өстеннән үрелеп кенә сине
Тартып алыр, бәлки, Салават.

Уралларга барсаң, җил, күреп кит,
Узаманнар рухы сәламәт:
Җыр укларын, ирлек җәяләрен
Иленә мирас иткән Салават...

Яманатлар түгел, дан атлары –
Халык улларына әманәт;
Шагыйрьләрнең сабан туе, бәлки,
Уфаларда күпме азамат! –

Үз кулыннан бүләкләрен бирер
Баһадирларына Салават.
...Халык күңеледәй ак сөлгеләр,
Ак сөлгедәй күңел – аман, ак...

Уралларга барсаң, туктал, болыт,
Уфаларга, җилкәй, сәлам әйт! –
Атта җилеп, Тукай бәйрәменә
Килеп китсә иде Салават. –
Сәлам әйт!

## БИЕКЛЕККӘ КАРАП

Сиңа карап уйга чумдым әле нигә,
Сөембикә манарасы?
Син торасың... авышсаң да бераз,
Шул ук –
Җыр-дастаннар баганасы.

Тарих үзе саклап, аклап калган;
Хәзер
Ник ят күрсен заманасы?
Биек яки бөек булган өчен, бүген
Юк үләсе йә авасы...
(Башка хәзер заманасы!)

Биек булу – җиңел язмыш түгел юкса,
Сөембикә манарасы!
Нигезе халык күңелендә булса гына,
Нык торадыр баганасы...

Сез – мәңгелек, халык һәйкәлләре!
Сезне
Юк һичнинең аударасы...
Шундый язмыш бәхет түгелме соң,
Сөембикә манарасы!

## КАЯ АШЫГАСЫҢ?

Кая ашыгасың? Зур юлыңның,
бәлки, башында син.
Карурманнар очрар, көчең сакла,
кая ашыгасың?

Кашка атлар, алмачуар атлар...
Меңдең кайсына син?
Теләкләргә тизрәк җитәргәме –
кая ашыгасың?

Алда таулар, урман-кырлар улы,
тукта, ярсынма син,
бул син Рәсүл – бөркет канатлы ир,
бул син Кайсын, ләкин...
кая ашыгасың?

Исемең яздың тимер дага белән
кыя ташына син;
ир-егетләр җырын җырла шуннан,
кая ашыгасың?

Алда – диңгез, кырмыскадай нәни
аның каршында син;
корабың көт, йөзеп чыгалмассың,
кая ашыгасың?

Дөнья чиксез, табалмассың ахырын,
һаман башында син.
Ул ашыкмый, кабаланмый...
Ә син...
кая ашыгасың?

* * *

Хыялымда минем Кояш яна,
Яна алтын Кояш!
Шул Кояшның эссе нурларыннан
Җаным мәңге туймас.

Хыялымда алтын Кояш, тоташ
Ак алтыннан койган.
Йөзен тирәләгән алтын чәчләр,
Битен алтын юган.

Алтын Кояш яна, алтын бәхетем,
Якты көнем-кичем;
Алтын нурлар белән алтынлана
Өнем минем, төшем.

Ул бүлмәмдә китапларга төшә,
Өстәл, кәгазьләргә...
Уйламастан җылы бирә суык
Фикер, вәгазьләргә.

Шатлыгыма күчә, уйларыма,
Юлларыма бага.
Ничә еллар шулай яна-яна
Минем белән бара.

Хыялымда алтын Кояш яна,
Яна табу – Кояш;
Әрсезлегем ялгышып та аңа
Кул сузарга кыймас!

## ТУКАЙ УРАМЫНДА

Кышкы көндә, февраль буранында,
килдем тагын Тукай урамына.
Ишелеп кар ява юлларыма,
тик аяз монда уйларыма:
мәңге кояш Тукай урамында –
шагыйрь урамында.

Ыгы-зыгы трамвай юлларында,
тормыш шавы – завод җырларында,
басып торам шулар уртасында.
Кушыла уй җилгә, буранына...
Шатлык туа Тукай урамында.

Булдым илнең күп урыннарында,
Кавказ, Себерләрдә, Уралымда...
Күп илләрдә булдым – уйларымда.
Булдым мин Бөекләр урамында...
Ләкин һаман кире кайттым монда,
кайттым һаман Тукай урамына.

Юлларымда
яңгыр була, җил-бураннар була,
һаман киләм, йөрим һаман монда,
җырлар да күп монда, газиз моң да...

Шул урамнан күрим сине, дөнья!
Булыйм мәңге Тукай урамында –
халык урамында!

## ДУСЛАРЧА БЕР КИҢӘШ

Дөнья бу, бел: картайса да, бер-бер
Хәлгә тарыса да,
Син кизәнмә ялгыш мәгърур җанлы
Мәҗрух арысланга!

Мәсәлдәге мәхлук – ишәк кебек
Килеп тибә күрмә;
Арысланга хас зур, горур хискә
Саксыз тия күрмә!

Аңла: рухы белән җиңәр сине,
Җаны шул ук, көчле...
Ваклыклардан өстен гәрчә һәрчак
Арысланнар үче.

Яшьме, картмы – шул ук аның исеме,
Ул – арыслан затлы.
Табылырмы арыслан белән тик
Бер алышкан атлы?

...Мәңге бу адымнан саклана күр,
Мәңге асылын аңла:
«Үлгән бу!» – дип якын килмә... йоклап
Яткан арысланга!

* * *

Кемнәрдер бер дәшкән иде мине
тылсым бакчасына:
– Нәрсә тапсаң, күтәрә алган кадәр
барысы да сиңа!

Онытканмын әкият хикмәтләрен:
күреп асылташлар,
комсызланса асыл ирләр шулай,
ятып калган башлар.

Онытканмын чамаларны мин дә:
инде китәм дисәм,
кузгалалмыйм... тапканнарым, баксам,
миннән авыр икән.

Кире мин бушаттым тапканымны,
чыгарга дип барам.
Кайда капка?
Инде чыгар юлны
югалтканмын тәмам.

Кемдер дәшкән иде...
Адаштым да
йөрим монда һаман.

* * *

Кал җырымда, апрель булып кал син!
Якты таңдай син бер балкыдың,
Мартта туган җаным шунда белде
Апрельгәчә дөнья салкынын.

Апрель булып килдең, юк, май түгел,
Мәңге миңа апрель булып кал;
Мәңге шулай якты булсын кичләр,
Сабый яшьле булсын болытлар –
Апрель булып кал син!

Бөреләрнең
Тик ачылган чагын, саф чагын,
Каеннарның суты ташыган мәлен
Күзләреңнең язы сакласын.
Апрель булып кал тик!

Ташкын сулар
Күңелеңдә калсын шул килеш.
Төенләнгән килеш торсын сорау,
Юк, кирәкми җавап, чишелеш...
Апрель килеш...

Беләм, табигатьнең
Үзгәрмәгән юк бер мизгеле;
Тукталу юк сиңа, алда яшьлек
Көтә яшел урман шикелле.
Кемнәргәдер әзерләнгән бәхетең
Елап ашыктыра майларга...
Юк, туктатып булмас бугай аны,
Күңелең синең әллә кайларда.

Ләкин миңа апрель булып кал син,
Минем өчен апрель булып кал!
...Җырларымда синең кояш яна,
Елау катыш көлә болытлар.

Кал җырымда, апрель булып кал син...

* * *

*Зөлфәткә*

«Ике урман арасы,
Йөри болан баласы...»
Дип, кем иде җанны өзгән,
Нинди моңнар баласы?
Нигә шулай янасы?

Шул җыр өчен, бер моң өчен
Килә эзләп барасы.
Җиде урман кичәр иде
Бер мәхәббәт баласы, –
Ничә язмыш – арасы?!

«Ике урман арасы» дип,
Каян хәзер барасы?
Яшьлек белән ара ерак,
Әрнесә дә ярасы.

...Кайда болан баласы да
Кайда моңнар баласы?

Җанны җырда яга-яга
Барасы да барасы.
Иясенә илтер идек,
Ник мәңгелек – арасы?
...Ә мәхәббәт баласына
Барасы да барасы!

* * *

Атлар йөри утлап, атлар монда –
Җәйге яшел болын...
Тик кайда ул – кайчандыр мин күргән,
Яраткан бер колын?

Уйнап тешләүләре, кешнәүләре
Ул колынның истә.
Иртә бер яз иде күргән көнем.
Яши һаман хистә!

Чәчмәсәм дә, туган җирдә мин дә
Сөрдем, тырмаладым.
Беркөн киттем, буразналар калды
Һәм җыр сызмаларым.

Шул язымда торып калды мәллә
Бик шаян ул колын?!
...Пегас-Пегас атлар йөргән урын –
Парнас түгел, болын!

* * *

Болытлы көннең кояшы
Югалып, ерак йөри.
Иртәдән бирле офыкта
Борчулы йөрәк йөри.
Мәңгегә китмәгәндер ул,
Үз юлын белми булмас.
Болытлар үтәр, аязыр...
Кояшын табар бу яз!

Күгеннән, күздән югалып
Китсә дә вакытлыча,
Борчылып, кояш юлыннан
Күңелләр күккә оча!

Болытлы күңелдән дә бит
Кояшы ерак йөри.
...Күр, күктә давыл агышы...
Болытлар белән тартышып
Ул минем йөрәк йөри!

* * *

Карлар яуды, яуды карлар,
Беренче карларым...
Карлар яуды. Ник аларга
Мин каршы бармадым?
Тәрәздән карадым.

Кар эреде, тагын яуды...
Аклыкны яраттым.
Карлар яуды – юлларымны
Күмсәләр, тараттым...
Урамга кар аттым...

Карлар яуды – бураннарга
Сүз куша алмадым.
Карга күмелеп нәрсәнеңдер
Мәңгегә калганын
Мин хәзер аңладым...

...Карлар ява, гомер бара...
Белсәм дә, карганмыйм.
Беркөн аяз күңелем аша
Соңгы кат карармын,
Елмаеп багармын.
...Явыгыз, карларым!

* * *

Калган гомеремне әйтми сәгать,
Йөдәтсә дә сорап җан аны...
Менә тагын бер ел үтеп бара,
Минутлары инде санаулы.

Озатамын иске елны уйчан,
Яңасына әзер елмаю, –
Мөлдерәмә тулы җанда – ялкын:

Саубуллашуга һәм каршылауга –
Шул ук сорау катыш моң, яну...

Иске елдан ниләр алып калыйм,
Һәм моңаю бүген ярармы?
Килер елым нинди булыр? Аны
Бәхетле дип дөнья табармы?

Саный гына сәгать, әйтми – юкса
Кемгәдер бит минем үз гомерем дә
Минутына кадәр санаулы?!
Гомер, гомер... Яңа ел алды...

## ДӨНЬЯ БИТ

Әйтерсез: «Кемнәр ул?»
Сорарсыз: «Ул кайда?»
...Казанда, көчекләр
Өргәннәр Тукайга,
Тукайга!

Йолдыздан көнләшеп,
Түбәннән өргәннәр.
Иснәнеп яманын,
Һау-һаулап йөргәннәр
Заманның этләре! –
Өргәннәр ал-арттан,
Газеттан өргәннәр.
Болактан, почмактан...

Тик Тукай көчлерәк
Яндырган йолдызын;
Ул янган – саф, якты,
Төнен һәм көндезен –
Халкымның йолдызы!

Булган бит заманнар,
Булган бу – Казанда...
Бер гаҗәп хәл кебек
Бу безнең заманда:
Максатлар бер, уртак,
Теләкләр кояшлы...

Йолдызга урын күп,
Күгебез колачлы.
Гайбәткә урын юк,
Дөньябыз түгәрәк;
Бәхетебез карлары
Күбәләк, күбәләк...
Тукайга тиң булыр
Юк болай юклыкка,
Шагыйрьгә, әдипкә
Юк бугай кытлык та.

Этләргә бәхәскә
Урын юк бугай да, –
Дөнья бит... Кайвакыт
Өрәләр шулай да...

* * *

Нигә куркып яратырга, нигә
Яшеренергә безгә?
Гайбәт үзе кыеп карый алмас,
Бәхет уты – күздә.

Мин гөнаһтан өстен син булганда:
Ярлыкаучым янда.
Бар ялгышлар, хыялларым белән
Җаным синең җанда.

Нигә әле пәрдә тәрәзләргә?
Бөтен дөнья күрсен!
Төнен, кәрваннардай агылып, аннан
Йолдыз иле керсен.
Алар безне күрсен!

Юк, кирәкми куркып яратырга,
Язык түгел инде!
...Мин яшеренми алып килдем изге
Михрабыма сине.

* * *

Көзге утлар кабынып ялмадылар
Агачларны тагы...
Офыкларга кабыныр төсле яна
Чаган яфраклары.

Нигә җыйдың утлы яфракларны,
Сихерләпме төсе?
Мин курыктым: баскан урыныбыз
Янып китәр төсле.

Сүндерергә иде ул утларны,
Сүндерергә... көзне!
...Бәхеткәме – язлар түгел, ут-көз
Якынайтты безне?

Көзге утлар сүнәр, яфрак кояр
Бу чаганнар тагы.
...Мәңгелекме бәхет? Кулда безнең
Яфрак кына янды.
Ә җан ялкыннары?

* * *

Хатлашудан, бәлки, башладык без,
Хисләрдәме хәзер дәвамы?
Соңы нидә? Бәлки, беләсеңдер,
Ә мин белмим әле – янамын.

Кар яуса да, күңелемдә эри,
Җил иссә дә, тия җаныма;
Әллә нигә сизгер хис җепләре:
Бөтенесе аңа кагыла.

Дөнья өчен юкса ни генә соң,
Чылансам ни, утлар алса ни?
Миндә менә, миндә гаҗәп барсы,
Бар халәтем – сәер, гасаби.

Хәтта сиңа кайчак аңлашылмыйм,
Ә бит синең утта янамын.
Хатлашудан башланды, әй, барсы,
Язмышымда күрәм дәвамын.
Соңы нидә? Әле – язамын...

## КЫЗЫЛ ЯУЛЫК, КЫЗЫЛ ГӨЛЕМ

Кызыл яулыгың бик килешә сиңа,
Карама тартынып;
Күңелемдә калдың яулык япкан
Язгы яшь тал кебек.

Кызыл яулыгыңдай кызарма тик,
Кызыл гөлем, дисәм.
Кемнең генә күзе бездә булмас,
Син янымда килсәң!

Очрашканда ерактан ук күренеп,
Син күтәрсең мине:
Сәламләрмен танып яулыгыңны,
Кочармын үзеңне.

Кызыл яулыгың бик килешә сиңа...

* * *

Нечкәрә күк һаман күңелемдә
Җырларымның күзге кыллары;
Шул кылларга кагылып узгангамы,
Син озаткан кошлар – юллары.

Әллә нигә түземлекләр кимеп,
Күзге көндәй күренәм сабырсыз.
Әкрен генә җырга иңә бара
Күз кабынган уттай якты төс.

Үзелергә җитеп сузыла ник
Күңелемнең нечкә кыллары?
Әгәр, шулар тотып торган булып,
Аерсалар синнән дөньямны?!

Нечкәрә күк кыллар күңелемдә...

* * *

Кай төшендә соң син – кем әйтә алыр –
Язмышымның минем, моңымның?
...Шундый җиңел рухым: сабый кебек
Яшьләремдә бүген юындым.

Тик гали кул тудыра алган рәсемең
Ачыкланды җанда тагын да;

Моңнар илен онытмаска чакырып,
Садә тавышың яңгырый адымда.

Эзсез калырмы бу – безнең яну?
Бәхетләргә дәштем мин сине;
Бәлки, синең җырларыңнан әле
Табар – килер еллар исемемне.

Ә син, онытылырбыз, дисеңме?!

## ЭЛЕГИЯ

Мең уйлардан авырайган башым
Иелергә синең янга килә.
...Әкрен генә соңгы йолдыз сүнә,
Әкрен генә гашыйк чәчәк үлә.

Мең кайгыдан арынган бер җаным
Юл таба да һаман җаныңа килә.
Әкрен генә йомыла кайгы күзе,
Әкрен генә ләкин хыял үлә.

Мең утлардан исән чыккан рухым
Мең дә бергә – тагын сиңа килә.
Әкрен генә тынсам җыр ахырында,
Уты сүнеп, шагыйрь үлде, димә!

## КҮҢЕЛЕМДӘ ИКЕ ЯЗ*

Бу көннәрне якты дию генә,
Алтын дию генә аз мәллә?!
Нәрсә булды көзгә? Нәрсә булды безгә?
Тирә-юньдә яшел яз мәллә?

Бу күңелдә нинди шатлык хисе,
Каян килә җылы май нуры?!
Нәрсә булды безгә? Нәрсә булды көзгә?
Җанга ява ләйсән яңгыры...

Бу гөлләр, күр, соңгы гөлләрмени?
Күпме матур төсләр, күпме наз!
Нәрсә булды безгә? Нәрсә булды көзгә?
Килде җиргә быел ике яз!

## БӘХЕТЛЕ БУЛ!..

Сиңа багышланган шушы җырлар
Бәхетләргә озата барсын сине!
Туй атына таккан кыңгыраудай,
Сискәндереп шатландырсын сине
Җаныңа үтеп кергән көе белән...
Котлап
Язмышка кул биргән көнең белән,
Тарантасың артына ук басып,
Ак йортыңа озата барсын сине!

Ә син
Искә алма бу көнеңдә мине:

Ахры, җиңә алдым мин үз-үземне,
Өстен куеп синең бәхетеңне...
(Тик, бәхетле булсаң иде, их,
булсаң иде!)

Җырым
Бәхетләргә озата барсын сине!
Борыла күрмә үткәннәргә кире:
Анда
Яфрак койган урман, хыял иле.
Ә алдыңда тормыш үзе инде:
Тигезләр йә тигезсезләр җире!

Ләкин җырым
Бәхетләргә озата барсын сине!
Туй узгач та, якты моңы белән
Һаман, һаман яңгырар кыңгырау күк,
Хәтереңдә күпкә калсын иде
Сиңа багышланган шушы җырым!

## АҢЛАШУ*

Сөйләшкән дә идек,
Гөрләшкән дә идек.
Очрашкач җирдә бер,
«Без бәхетле», – дидек.

Югыйсә арада
Җил йөргән идеме?
Белдеңме син мине,
Белдемме мин сине?

Аңлашкан идек без,
– Мәңгегә! – дидек без.
Бүген ник үзебез
Читләшеп йөрибез?!

Сәбәбе синдәдер,
Ә бәлки, миндәдер.
...Мәхәббәт каршында
Син дә бер, мин дә бер.

Очрашыйк тиз тагын,
Аңлашыйк без барын:
Суларның акканын,
Яшьлекнең узганын.

Сөйләшик җилләрнең
Ак хәбәр йөрткәнен.
Мәхәббәт илендә
Мәңге яз икәнен!

## ЯЗГЫ ТАШУ*

Канат какты гомер,
Җилкендерде җанны
Язгы җырларында.
Сокландык без, карап,

Язның бозларына,
Язның суларына.
Язгы ташу,
Су тавышы –
Моң агышы:
Әллә кавышу,
Әллә аерылышу?!

Гөрләгәндә сулар,
Безнең ярсу җырлар
Нигә һаман тынмый?!
Язлар саен сулар
Шаулаганда, шулар
Нигә онытылмый?
Язгы ташу,
Су тавышы –
Моң агышы:
Әллә кавышу,
Әллә аерылышу?!

Язлар шулай килер:
Еллар моңы эрер
Ташкын суларында.
Кабатланыр мәңге
Безнең күңел яме
Яшьлек җырларында:
Язгы ташу,
Су тавышы –
Моң агышы:
Әллә кавышу,
Әллә аерылышу?!

**АЛМА АПА...**

Алма апа!
Өй турында
Тупылың корган димә,
Моңайма, апам, көймә:
Бакчагызда зифа буйлы,
Инде җимеш бирер булып,
Алмагач үсеп килә!

Алма апа!
Бакчагызда
Сандугач сайравы тынса,
Җәйләр авышкан димә:
Өеңдә сайрар кошың бар,
Яшь моңнар әле яңгырар –
Тик сайрат безнең көйгә!

Алма апа!
Кышлар килсә,
Урам тулып карлар ява,
Карны кем көрәр димә:
Турыгызда такыр сукмак,
Нинди сәбәп ул, нигә? –
Турыгыздан кемнәр үтә?!
Безне белмиләр димә...

Алма апа!

Авыл буйлап
Кыңгырау чыңлый нигә?!
Кемнәр йөриләр димә:
Яшь чакларыңны хәтерлә...
Сезгә кодалар килә.
Кызым яшь әле димә...

Каршыла: туйлар килә!

## ЯЗЛАР ҖИТКӘЧ*

Язлар җиткәч, бер ярсыйлар сулар,
Дәрьяларга ашыгып ярсыйлар.
Күңелем минем мәңге ямансулар,
Хисләренә тиңдәш яр сорар.

Ташыса да, бер тыналар сулар,
Бер кузгалса, тынмый ярсулар.
Ярсу күңелем ярын табалмаса,
Туктап уйланырга ял сорар...

Көчле явымнарда агымсулар
Ярларыннан чыкса бер чыгар.
Күңелем минем, гомерем буе янып,
Туган җирдән артык җир сорар.

Юл башыннан бер кузгалган сулар –
Мәңгелеккә барган юлчылар.
...Туган җирдән артык җир табалмас,
Күңелем кире кайтыр юл сорар.

Язлар җиткәч, ник ярсыйлар сулар?!

## ТӨНГЕ ИДЕЛ*

Тып-тыныч төн, күкләр аяз,
Идел өсте зәңгәр, зәңгәр...
Асылташ нур белән балкый,
Иделенә карый шәһәр:
Идел – зәңгәр.

Җиргә карап йолдыз яна,
Сиңа карап яна йөрәк.
Йөрәк яна: без эзләгән
Әллә якын, әллә ерак?!
Яна йөрәк.

Җил кагыла, чәче тузгып
Дулкынлана Идел өсте.
Зәңгәр төндә бер икәүбез,
Зәңгәр – матур, яшьлек төсе...
Идел дә шул – япь-яшь төсле!
Яшьлек төсе!..

## БЕЗНЕҢ ҖЫР*

Ул аклык, ул сафлык турындадыр.
Гаҗәпмени өзми кабатласак?
Бәлки, ул тик безнең, безнең җырдыр?
Ул безнең якты моңдыр!

Ничә мыскал энҗең, әй, ак калфак?
Их, мәңге ак калсак!

Ул вәгъдә, ул сөю турындадыр,
Ул – яшьлектер безнең, гел җырласак?
Бездән соң да кемдер аны җырлар,
Без янган кебек янар!

Ничә мыскал энҗең, әй, ак калфак?
Их, мәңге яшь калсак!

Ул тормышның үзе турындадыр,
Мәңгелек моң, җирдә ул калачак.
Бәлки, безне кемдер искә алыр,
Бәлки, онытылмас бу җыр?

Ничә мыскал энҗең, әй, ак калфак?
Их, мәңге пакь калсак!

## БЕР ХАТ*

Бер хатың бар синең миңа язган,
Бер хатың бар минем исемгә:
«Син кайчандыр сөйгән идең мине,
Төшәмме соң хәзер исеңә?!

Мин бәхетле тормышымда, белмим
Нинди утта синең янганны?
Ә беләсем килә, уйларыңда
Исемем генә минем калганмы?!»

Бер хатың бар гаҗәп миңа язган,
Бер сорау бар синең хатыңда:
«Син... кайчандыр... сөйгән... идең, дисең,
Оныттыңмы сөюең хакында?!»

Бер хата бар минем хакта уеңда,
Ничек шуны әйтеп язарга?!

«Кайчандыр бик сөйдем» дияр идем,
Сөймәсәм мин сине һаман да...

## ЙОЛДЫЗ ҖАВАП ЯЗМЫЙ

Аңа барып җитми әллә хатым?
Җавап язмый нигә?
...Кызыгыздан күптән бер хәбәр юк,
Инде дәшәм сезгә:
Хөббениса апа,
Хат язганнар ласа
Сезгә дә яшь чакта!

Әллә хатым барып та, ул үзе
Җавап язмый микән?! –
Ата-аналарча кызыгызны
Орышсагыз икән.
Габдуллаҗан абзый,

Ярдәм итегез сез! –
Йолдызыгыз язмый!

Хатым тулы минем аңа дигән
Яшь күңелнең назы.
Кызыгызга шуны аңлатыгыз,
Аның да бит язы!
Хөббениса апа,
Бар өметем, хәтта
Язмышым шул хатта!

Беләм дә бит, сезнең гаеп түгел,
Миңа шулай язган:
Мин хат көтәм – кемгә килгән әле
Җавап – йолдызлардан?!
Габдуллаҗан абзый,
Хөббениса апа,
Ник кызыгыз язмый?!

* * *

Гомер чишмәсеннән ерак итеп,
Якынайган саен диңгезгә,
Ешрак сагынам һаман әнкәм өен,
Ныграк табынам туган нигезгә.

Чит җирләрнең күреп йолдызларын,
Җилләр көчен тойган хәлемдә,
Туган җиремә мин урап кайтам –
Тукаема, Такташ, Җәлилгә...
Өмет белән сугылам якташларга –
Мостай ага, Наҗар Нәҗмигә...

Гадирәк хәзер идеаллар да,
Матильдалар түгел йә Сандлар:
Истә күбрәк Сәмитова апа,
Мозаффария, Гыйффәт туташлар*.
Эйфель манарасын күрдем инде,
Ләкин
Сөембикә җанга якынрак,
Парижларда сагынам Казанымны,
Тик каладан авыл артыграк.

Зур хыялга тимик, дөнья гизсен,
Әүвәлгечә, юлым диңгезгә.

Тик еш сарыл, җаным, арышларга,
Төштә, әйдә, һаман ныграк үксе
Үзең ташлап киткән нигездә...

* * *

Җирдә тагын нинди өн?
Кайсы илдә ни зар, моң?
Күңелдә ник борчу, шом?
Кайда күкләр каралды?
Кайсы аккош яралы?

Нинди илдә нинди шау?
Нидән гауга, нинди дау?
Золым-җәбер бар җирдә
(Яши күңеле тар – җирдә!)
Сагыш, кайгы бар әле.
Аккош бик еш яралы!

Үз илемдә нинди гөр?
Нинди шатлык? Аваз – көр...
Сөенечле йөзләр, күр! –
Ирек алып бер-бер ил,
Болытлармы таралды?
Аккош, бәйлик яраңны!

Җирдә тагын нинди дау?
Ни хәбәрләр? Юкмы яу?
Иминлеккә куркыныч
Юкмы анда? Ут-кылыч
Айкамыймы илләрне?
Яу дәшмиме ирләрне?

Күңелдә ник борчу, шом,
Хәвеф көтәм мин ник соң?
...Мылтык тавышы яңратты
Тыныч елга ярларын,
Каурый тузгып таралды, –
Җирдә хәвеф бар әле.
Аккош... аккош ялары!

## ӘГЕРҖЕ ПОЕЗДЫ

*Э.Г-кә*

Тукта әле, тукта тик беразга,
Әгерҗе поезды!
Әллә нигә гомер, синең кебек,
Гел ашыгып узды.
Ашкынганга чыккандыр рельсыннан
Кайчакта яшьлегем.
...Тойгыларның авыр йөген бүген
Яшемә яшердем.

Тукта әле, поезд, гамьсез узып,
Син калдырган якта,
Шпалларга башын салып, бәлки,
Үкенечем ята?!

Төшлегенә җитә гомер, ахры,
Гүзәл мизгел узды;
Тоталмадым. Син дә туктамадың,
Әгерҗе поезды!

## ТАЯК ТУРЫНДА

Шагыйрь өендә шундый бер
Тамаша булган икән:
Таянып килгән таягын
Бер карт онытып киткән.

*Мостай Кәрим*

Әллә ни зур вакыйга да түгел,
Кирәк иде микән язарга?

...Чал шагыйрьнең таягы тик калган,
Онытылып калган Нажарда* –
Кунакханәдә бер, Казанда.

Ниндидер бер мәгънә күрдем шунда,
Шигъри мәгънә... син дә искә ал:
Шагыйрь энесенең сүзләреннән
Яшәргән бит, күрче, аксакал.

Таянырга таяк кирәкмәгән,
Пегас канатында, күрәсең.
Кайтып киткән өенә... Бүген миңа
Шул таякны илтеп бирәсе.

Шул таякны... Ә бит үз җилкәмдә
Аксакалның авыр таягын
Күп татыдым. Еллар буе төшкәч,
Кыйналуга күнеп барамын.
Әллә соң, дим, кулга эләккәч бер,
Кемнедер мин үзем чүт кенә
«Сыйпап» карарга мы? Күп бит яшьләр, –
Ә кыйналу шундый үстерә!..

Мин шаярам гына, кыйный алмам,
Гөнаһ ала алмам өстемә.

Мин урамнан барам, очам гүя,
Җиргә тидермим дә аякны.
Үзем уйлыйм: аксакаллар – көчле...
Нигәме? Бит алар таяклы.
Таяк саклый мәллә талантны?
Ашыгып атлыйм. Уйлыйм, таяксыз соң
Аксакалның көне узмаса?
Янып язар җыры тумаса?
...Мин дә язмас идем бу шигырьне,
Шул таякны оныттырган Нажар,
Ә оныткан Туфан булмаса!

* * *

Ничек шулай үзгәрде бу күкшел ярлар?
Җанга якын төстә хәзер алар.

Сары песи сарган яшел таллар ботагында
Тирбәлергәме әллә бер тагын да?

Күңеле тулып ташкан, тузын ачучыга
Каен күзләреннән яше чәчрәп чыга.

Ташый елга, шарламалар, гөрләвекләр...
Су тавышы төшләреңдә гүләр, күкрәр.

Уятмакчы булса иртән кояш күзең ачып,
Хисләр күптән уяу, йокы киткән качып.

Монарланган* һаваларның, күкнең төсе
Күзләреңә керә, килә җир, дым исе.

Апрель! Гаҗәп җылы хисле гүзәл кыз син! –
Гомерем буе җанга яланаяк басып уз син!

## ХЫЯЛ-РӘССАМ

Һәрвакыттагыча
бу язым да мине рухландырды.
Тагын җаныма үтеп керде тургай җыры!
Тагын күз алмыйча карыйм
каеннарның нечкә гәүдәсенә,
тирбәлүче нәфис җиңеллеккә –
яшел яфрак өрфиясенә...

Хыял-рәссам күкнең
бәхетләләр күңеле кебек аяз-ачык
зәңгәр гөмбәзенә тагын гашыйк;
җилләр белән куышырга вакыт таба,
оча әллә кая, йолдызларга таба...

Тагын бүлмәмдә тик гөлләр исе...
Һәм ак чәчәк кебек якты сагыш үзе:
төштә һаман
чуар болыннарда чабып йөргән
яшь тай күрәм.
Кушылып кешним гүя, көләм!..

Язларга тиң сүзләр табасы иде!
Вакыт агышын рәсем итеп алып каласы иде!
Һәр язымда янам шул уй белән.
Юкса чынлык шагыйрь хыялыннан
күп матуррак. Күптән беләм...

## КОЯШ УЛЫ

Ригада,
Бирзе аллеясында
Такташ кабере искә төште.

*Р.Фәйзуллин*

Кабереңдә шундый һәйкәл синең, Райнис:
Яшь бер егет үрелә,
омтыла Кояшка!
Гүя безнең көннәр яктысында
мәгърур хыял, акыл күккә аша.
Даугаваның, Балтик буйларының
бөек улын кочкан бу җирдәге
биек гөмбәз –
сихри, серле ореол булып балкый;
алтын нурлар –
Кояш кебек, Рига өстендәге.
Үрмә гөлләр үрелә гөмбәзеңә,
гүя Аспазиянең* ак куллары
таҗ кидерә сиңа;
гүя шиңми торган яшел таҗны
шагыйрьдән ала шагыйрь җаны!
Өстегезгә ява
бәрәкәтле Кояш яңгырлары.
Кабереңдә һәйкәл-символ, Райнис:
Кеше

мәңгелеккә ашкан!
... Гомере җырда янган Кояш улы
аерылмый Кояштан!

## ЛАТЫШ УКЧЫЛАРЫ ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА

Таш атларын тыеп, тынып калган
латыш укчылары.
...Туктал, Кеше, башың иеп уйлан
бер минутка бары:
– Нәрсә сөйли сүзсез
латыш батырлары?

«Җиңеп кайттык. Тик югалтулар зур...
Авыр хәбәр, ничек әйтик аны?
Иптәшләрнең күбесе кайталмады,
еракта – атлары...
Кайтты илгә канлы байраклары...
Ерак Идел, Уралларда ятып
калды
латыш укчылары, җайдаклары...
Таш атларда
ярып үтик әле бу тынлыкны! –
ул кургаштай авыр.
Сузыйк матәм көен сүзсез генә –
кыен ул җыр...

Ә аннары тарих өчен аны
мәңгеләштерер чор».

Һәйкәл булып калган таш атларда
кайткан авыр минут.
...Туктал, Кеше; синең хәтерең өчен
яна Мәңгелек ут...

Таш атларда – латыш укчылары.

## БЕР ЮГАЛТУ

*Хәсән Сарьян истәлегенә*

Яздың:
«Бер ананың биш улы»... –
Бәхеткәме, җиргә ник туды?
Язмышлары белән ни булды?
Кайда, нишли алар бу җирдә –
(Шатлык тулы анда, гамь тулы!)
Бер ананың газиз биш улы?

Син – әнкәңнең бердәнбер улы –
Үзең
Җир-ананың идең кайсы улы?
Нигә безнең күзләр яшь тулы?
Нигә кыен бүген? Ни булды?
Җирдән кичте
Әллә бер ананың бер улы,
Әллә Җир-ананың бер улы?
Әллә «тирәк төптән киселде,

Тирәк әллә кинәт егылды»*?

Моң тетрәтте күпме кыз-улны:
Бер югалту – күпме җан тулы!

### ӘМӘКӘЙДӘ «ГАМЛЕТ»

*Наис Гамбәргә*

– Кая барыйк? Урәзмәттә клуб ябык – ял бит...
Әмәкәйдә – кино, – ди, әй,– Әмәкәйдә – «Гамлет»!
...Без, биш егет, Шекспирга шашып гашыйк булган...
Алты чакрым ара ни ул? Чаптык кышкы юлдан.
Киче шундый: буран тузгый, бөтерелә карлар.
Җилгә каршы йөгерәбез – җан яшь безнең, кайнар...
Ике арада авыл – Бүләк, Илдар Маннаповны –
Батыр егетне үстергән... Сәламлибез аны!
Йөгерәбез... Кем дә әйтми, «Җитте, бераз ял!» дип.
Алда – утлар. Әмәкәйдер, анда – көтә «Гамлет».
Ашыгыгыз, әй, малайлар, яшьлек, дәрт җилкетә.
Йөгерегез – алда шатлык, бәхет – барсы көтә.
Йөгер, Дөлфәт, утка кадәр байтак узасың бар.
Янып-пешеп җыр язасың – Зөлфәт буласың бар.
Үзе татлы, үзе ачы – иҗат шәраб кебек:
Ахыргача эчәрсең, син – яшьтән бунтарь егет
(дустың Наис кебек!)
Йөгер, Фәрит, алда – Казан, Әлмәтнең утлары,
Уйлыйсыңмы нефтьчеләр бирер повестьларны?
Яңа сюжетларны?
Йөгер, Роберт, Илдар абыең калышмаска өнди,
Маннапов син, тормышның гел эченәрәк кер, ди.
Чаллы көтә сине... әле ул да аны белми.
Минем кабул була, ахры, әнкәм теләкләре! –
Буран катыш җырлар туа – «Урәзмәт дәфтәре»!
«Бәхетле булыйк, дуслар! – дим, – йә, кызулыйк әле!»
Йөгерәбез. Алда – утлар, алда – киләчәкләр.
Буран каплый бары...
Алда тере ак чәчәкләр.
Алда – Казан. Шагыйрьләрнең бәхәсе, даулары.
Әле катгый басар алга Гамлет сораулары.
Әле ерак җанның яшерен Офелиялары.
Әле уйда калкыр батыр чорыбыз геройлары,
Монологлар, диалоглар...
Алда әле бары!
...Буран тынды. Менә авыл. Әмәкәй, кабул ит!
Урәзмәттән килдек. Саумы, безнең яшьтәш, Гамлет!

## *II. Европада татар шагыйрьләре*

*(1973–1985)*

### ФРАНЦУЗ ЯУЛЫК

Француз яулык, француз яулык!
Кемнәр йөри икән ябынып?!
Эре чәчәкле иде, әй, яулыгың,
Әнкәй, ничек синең саулыгың?

Француз яулык ул – әбиләр яулыгымы?
Олыгайгач, аны ябындыңмы?

Париж.
Эйфель манарасында мин,
Яулык болгыйм бүген.
Ул яулыкка – Эйфель үзе, Версаль,
Күперләре белән Сена –
Гүя Париж төшкән.
(Казан сурәте ясалган яулык ник янымда юк?! –
Җилфердәтер идем аны биектән!)

Бүген ераклардан күренә миңа илем,
Туган җирем, әнием!
Иң татлы хис, ахры – Ватанга мәхәббәт.
Читтә – сагыныр җирең,
Сагыныр кешең булу нинди рәхәт!

Әнкәй, ничек анда синең саулыгың?
Кайткач,
Күзләреңнән сагыну яшен сөртер
Шушы яулык – француз яулыгым!

## ЕВРОПАДА ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Колагымда нигә яңгырый әле
Бер җыр димме:
– Европада... татар... шагыйрьләре!
Европада –
Одер, Висла, Влтавада каберләре...

Китермәгән монда дипломатик миссия,
Вәкаләт тә.
Сорбоннага, Краковка
Укырга дип килгән алар, бәлки?
Юк,
Хәтта чит илләргә сәяхәткә
Сирәк чыга татар шагыйрләре.
Европада ләкин каберләре...

Сугыш җиле алып килгән дә ирләрне,
Берлин төрмәсеннән
Европага баккан Җәлил.
Атакада чакта кергән анда Кәрим.
Польша аша узган Кутуй.
Европада – Баян.
Илләр яшәве өчен гомерләре янган.

Алар чакыра безне,
Чакыра истәлеге,
Соңгы шигырьләре, каберләре:
–Европада,
Европада татар шагыйрьләре!
Якташларын эзләп, шагыйрь менә
Бара Гете иленә,

Фучик җиренә.
Текә, горур тота шагыйрь башын:
Саклый дуслар рухын, бөек хакын.
Ачыла бар дөньяга зур, сабыр җаны...
Колагымда яңгырый,
Һаман яңгырый:
– Европада...
Татар шагыйрьләре!

## ОРЛЕАН КЫЗЛАРЫ

Төш әле атыңнан, Жанна д’Арк!
Күрәмсең,
без Орлеанда. Һәйкәлең янында
Орлеан кызлары белән
рәсемгә төшәм мин.

Эвелина, Сильвия, Софи... –
һәммәсенең күңелендә синең сурәт.
Синең символ күзләрендә,
синең девиз:
– Францияне коткарырга кирәк!

Һәрчак яңа Жанна туа тора...
Бүген соң коткарырга кемне? Нидән?
Кемнән?
Фикер коллыгыннан? Тук фикердән?
Аек акыл җитмәүдән, түбән төшүдән?
Коткарырга ярый
хәтта үзеңнән-үзеңне!
Жанна д’Арк!
Ә син коткаргансың Францияне – илеңне!
Шул турыда сөйли синең алтын һәйкәл.
Безнең белән ул рәсемгә төште.
Эвелина, Сильвия, Софи...
Алар белән син дә Иделемә
кунак булып бер килерсең төсле!

## СӘЯХӘТТӘН – МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

Париж!
Минем өчен булдың бер матур төш...

– Европа, – дип,
Шаккатмасам да мин, авыз ачып,
Матурлыкка булды күңел ачык.
Зур тарихлы,
Киләчәге, шиксез, якты француз халкын
Мин якыннан таный алдым.

Исем китмәде рекламаларга,
Неон белән язган алдауларга,
Адаштыргыч төнге утларга да...
Башым идем Эйфель-манарага.
Гаеп булмас иде,
Гашыйк булдым дисәм
парижанкаларга.

Ләкин алай димим.
Сәяхәттән кайткач, әйттем сиңа:
– Париж минем өчен бер төш иде,
Ул төштә дә, шатлан, сине күрдем!

Ун көн дәвам иткән төштә
Минем белән бергә идең,
Казан кызы!
Алтын кояшым минем!

## ЧИТ ИЛДӘН ШАГЫЙРЕБЕЗГӘ ХАТ

Люксембург бакчасында
нәкъ Алмаздай, Салаваттай балалар...
Люксембург бакчасында
чәчәк кебек кызлар, малайлар.
Балалар – кайда да шул:
күбәләктәй җитез, шук;
каршыңа басалар,
тел күрсәтеп, көлеп,
аннан тагын уенга чабалар...
Әтиләренең уе нинди икән? –
Балалар күк тату, садә булсын
дөнья, илләр!
...Парижда, Люксембург бакчасында
уйларымнан мин хат юллыйм сиңа!

Әле хәзер генә Нотр-Дамнан
чыктым месса тыңлап...
Гаҗәп матур икән собор, чынлап!
Квазимодо, Эсмеральданы күрмәдем.
Гөнаһлымын:
бик ошаттым парижанкаларның үзләрен.
Аларга татарчалап:
– Сез искиткеч гүзәл! – дидем.

...Син фольклор өйрәнәсең бугай?
Хәтереңдәме «Рус-француз сугышы бәете»?
Юкка түгелдер бит – искә төште...

Аннары бер шигырь:
исе китсен – терелеп чыксын кабереннән
Элюар... Аполлинер! –
Кычкырып сөйлим:
– Кабан – Казанның моңлы бер күзе... –
дим.
«Эх, шәп!» диюче юк. Гәрчә бу – верлибр...
Европаны, ай-һай, шаккатыру авыр!

Уйлар таркау.
Миндә – бер моңсулык хисе!
Уйда – күп шагыйрьләр күргән,
хәтта ирекле шигырьне дә сыйдырган Казан.
Читтә нинди генә гүзәллекләр күрмә,
Казанымнан язмыш аермасын!
Безгә шунда язган.
Шөкер!
Ә Парижда булу –
үз җырыңны, үз-үзеңне, олылыгың аңлау юлы! –

бүләк итсен чын, кешелекле бер шигырь.
Ә калганы... Хәер, җитәр.
Кайткач сөйләшербез. Әмма бүген
Тәкәбберлек тулы шигъри бәллүрне син
Илдә
Минем өчен дә бер күтәр!
...Илдә үпкә-ачу озак тормас,
үтәр...

## ПАРИЖДА

*(Н.Хикмәттән)*

Әле вакыт барында, кадерлем,
Париж яндырылмаганда, җимерелмәгәндә,
әле вакыт барда, кадерлем,
йөрәгем торганда үз ботагында,
Парижда, Вольтер урамында,
диварга кысып сине, мин
ireннәреңнән үбәрмен бүген...
Һәм борылырбыз аннан Нотр-Дамга –
гаҗәеп тәрәзәләргә карарга.
Ә син миңа сыенырсың шунда
куркынып, гаҗәпсенеп,
тын гына елап шатлык белән...
Йолдызлар да безнең өскә
вак яңгырдай сибелерләр.
Әле вакыт бар, кадерлем,
Париж яндырылмаган, җимерелмәгән.
Әле нәкъ вакыты, кадерлем,
әле йөрәгем минем үз ботагыннан
өзелмәгән.
Шушы гүзәл май төнендә
яр буенча барыйк бергә
бөдрә таллар, юеш таллар ышыгында...
Һәм мин сиңа шундый сүзләр әйтермен:
алдаусыз, якты сүзләр.
Ә аннары сызгырырмын берәр көйгә,
шатлыгымнан кешеләргә ышанычтан
шашып.
Безнең өстә биек йортлар,
сыенышып йоклый алар,
диварлары гүя нурдан...
Тәрәзәләре йоклый төшләр күрә-күрә...
Әнә Лувр –
безнең өчен бәллүр сарай.

Әле вакыт барында, кадерлем,
әле Париж яндырылмаганда,
әле йөрәк үз ботагында булганда,
без бу ярда, склад янында,
буш мичкәләргә утырып торыйк.
Карыйк. Әнә канал,
караңгыга ул кереп югала...

Уза баржа... Кул изик аңа –
Бельгия яки Голландиягә
барган баржага...
Сары каюта ишеге төбендә

ак алъяпкыч япкан ханым
кемгә елмая бу төндә?

Кадерлем, әле вакыт барда...
Әле Париж, бу гүзәл Париж яндырылмаганда,
Сокланыйк без аңа.
Париж халкы, әй парижлылар,
ирек бирмәгез сез
Парижны яндырырга, җимерергә!

## ЛУВРДА, «ЯҢАРЫШ» ЗАЛЫНДА

Бүген
Луврда, «Яңарыш» залында
Җаныма бер яңарыш теләдем мин,
тезләнеп
Мона Лиза – Джоконда алдында.

Сәнгать көченә ышанычым зур, какшамас...
Джоконда,
«догамны» онытма,
дөньяда –
тагын бер гашыйгың артты,–
мәңгегә, бел, сине
ул «ташламас»!

* * *

Ага Сена, ага Сена...
Ниләр әйтим, Париж, сиңа?!

Маяковский язганча,
Синдә «яшәп үләр идем,
Шундый җир – Мәскәү булмаса»...
Юк, кайнар Казаным, димен!

Якын миңа шагыйрьләрең,
Таныш Гаврош-гаменнарың,
Өч бөек революциянең
Шаһитлары – урамнарың:
Бастилия мәйданында,
Зират шәһәр Пер-Лашезда –
Коммунарлар диварында, –
Париж, уем – Казанымда!

Ага Сена, ага Сена,
Ни алыйм, Казаным, сиңа?

Мин аңладым шуны, Париж:
Туган ил – үзең белән ич –
Кайда булма, кайда йөрмә!
Ә уең – туган җирләрдә.
Ватан хисе булса гына
Ышаналар шигырьгә дә.
(Ярап кара Әгъләмнәргә!)

Ага Сена, ага Сена...
– Нәкъ татарча сәлам булып,
Кер син, Париж, шигыремә!

## АЛЛОУЭЙДА, БЕРНС АВЫЛЫНДА

Дулкыннармы, әллә аның тавышы?
Нинди өн диңгез ярында?
Йөрәк, без тын торыйк... Бүген без ич
Роберт Бернс авылында.
Аллоуэйда салам түбәле йорт,
Нәни үзе, тәрәзләре...
Монда кояш, таулар, Шотландия
Ничек сыеп кергән әле?
Кергән бөтен дөнья яме!

«Тауларда минем йөрәгем...» Шул җыр
Үзәннәрдә яңгыраган...
Тауларга тиң халык моңы. Шагыйрь
Шул моңнан, бәлки, яралган –
Бар дөньяга яңгырый алган...

Мин дә җырлар идем... Минем аваз
Кемгә тансык булыр монда?!
Тик тавышны бер сыныйсы килә,
Нәкъ үземчә бер җырлыйсы килә
Роберт Бернс авылында!

## КОВЕНТРИ

– Сэр, әйтегез, озакмы килә
Экспресс поезд Ковентридан Лондонга?
Кемдер килер кебек бүген аннан миңа.
Беләдер ул: мин Англиядә, монда.
Кинодагы кебек, Ковентридан Лондонга
Киләдер экспресста кемдер, ул – юлдадыр.
Ничә сәгать килә поезд Лондонга, сэр?

Нигә безнең маршрут соң илтми анда?
Бик буласым килә минем Ковентрида.
Сталинград белән тугандаш ул, батыр кала!
Легендаларын саклаган Ковентридан
Нигә килми экспресс поезд Лондонга?

Күргәнем юк аны, ләкин күз алдымда
Фашист бомбасы, ут яуган корымлы кала...
Тик акыллы кешеләр яши булыр анда:
Катгый нәфрәттер аларда сугышларга –
Минем күк этисез үскән чордашларда –
Ирек бирелмидер яңа фашистларга?
Тынычлык сүзе хакимдер Ковентрида!
Нигә безнең маршрут кагылмаган анда?!
Көне буе көтәм мин кемнедер
«отель Мостин»да,
Кемдер эзләп килер кебек мине монда.
Кемнеңдер бик җитди сүзе бардыр миңа –
Әллә соң үзем китимме экспресс поездда?
– Сэр, озак барамы ул поезд Ковентрига?

## ИСПАНИЯ ТУРЫНДА ҖЫР

*(Сәяхәттән – романсеро)*

Испаниям! Әйт, нидән соң
Ак диварларыңда сагыш –
Кара үгезләр шәүләсе?!

*Ф.Г.Лорка*

**Кереш – багышлау**

Федерико Гарсиа Лорка!
Кабул ит җырымны минем:
Бүген синең истәлеккә
Ал канәфер мин китердем,
Федерико Гарсиа Лорка!

Романска сыймас хисем,
Нәфрәтемнең кайнар көче –
Һаман канмаган зур үчем –
Синең иртә үлемең өчен,
Федерико Гарсиа Лорка!

Чыклы август иртәсендә
Син егылгач, Гранадаңда
Әфлисуннар – алтын түгел,
Нәкъ кырык ел – кан төсендә,
Траурда – испан халкы,
Федерико Гарсиа Лорка!

Дон Кихотлы Испаниядә,
Син сөйгән Андалузиядә
Үтерелгән шагыйрь җыры.
Шәүләң – кара жандармга,
Инде башсыз франкочыга
Яный көчле дәһшәт булып.
Егерменче гасыр шигыре!
Синең төсең – көрәш төсе.
Синдә инде күпме яра:
Лорка өчен, Җәлил өчен,
Фучик өчен... арта бара.
Көрәш тынмый... Шигырь – байрак,
Ал каннардан ул кызара.
Ул байракта – синең исемең,
Федерико Гарсиа Лорка!

**1**

Испания! Син соң – синме
Данлы уен корридасыз –
Үгез сугышың – «торо»сыз?!
Матадорларыңа гашыйк
Кызу канлы публикасыз?!

Барселона, Мадрид – сездә,
Карап таза үгезләргә,
Үткен, очлы мөгезләргә,
Курку белмәс егетләргә,
Өзлексез «афәрин» диеп,
Синьорларча шәраб эчеп
Атаклы тире сабадан, –
Корридаңда утырдык ла
Без, ике шагыйрь – Казаннан.

Циркның өске рәтеннән
Горур күз карашы белән
Публиканы кат-кат сөзде, –
Гүя Кама ягы үгезе! –
Атаклы безнең Фәйзуллин!
Хэмингуэйча шәп бәдән,
«Болын кадәр маңгае»на
Испан кояшы сыенды,
Үзе мәйдан тоткан төсле
Әй кинәнде, әй сөенде
Тирләп-пешеп безнең шагыйрь,
Үзе сикереп төшәр булып
Тореадорлар янына –
Уен барган аренага...
Ә анда, күрәм, кан ага!
Каршылыклы уйлар туа...
Һәр халыкның үз гадәте –
Үз уены... ни әйтәсең?!
Әмма булдык корридада.

**2**

Күрдек бүген барысын да:
Милли музыка тавышына,
Уен алдыннан халыкны
Сәламләп, матадорларның
Саф-саф булып узуларын –
Җем-җем иткән киемнәрен,
«Торо»ның һәр ритуалын –
«Король»нең яулык болгавын,
Башлануын корриданың.
Өч матадор, алты үгез...
Ике сәгать вакытта без
Үлем уены осталарын
Күзәтергә бүген тиеш.
Публиканы сокландырып,
Үлем белән уйнап, алар
Хәзер мәйдан тотачаклар.

Борынгыдан килгән һөнәр:
Үгез белән йөзгә-йөз син,
Пычак кебек мөгезне тик
Яныңнан уздырып җибәр!
Чират көтә матадорлар.
«Броня» кигән ат өстендә
Рыцарь киемле пикадор
Сөңге белән кадар... Үгез
Ярсып атны сөзәр... Күрегез,
Кызыл плащ тоткан берсе
Үгезгә якын ук килеп,
Аны ярсыта, котырта.
Аннан кача... аны арыта,
Аннан чыга тагын берсе.
(Бандерильеро монысы!)
Каршына ук килеп, ташлый
Үгез җилкәсенә пычак:
Алты пычак кадалачак!
Үгездән инде кан ага...

Хәзер төп уенчы чыга,
Җитди өлеш башланачак!
Ярсыган үгез алдында
Тыныч мастер – тореадор –
Кулда плащ-мулетасы,
(Шунда аның шпагасы!)
Ул үгезне якын китерә,
Читкә сикерә, әйләндерә,
Шул мулетасы артыннан
Йөртә үгезне, арыта
Һәм, кадап, аны үтерә!

Өч матадор, алты үгез...
Ә кешегә тисә мөгез?!
Мөгез – үлем, үгез, син сөз...
Үлем белән алышта ир,
Публикага бу тик уен;
Эләгеп мөгез очына,
Очсаң син койма артына,
Яра алсаң – халык шаша.
Торып баса... дәртен баса!
Аңа булсын уен гына,
Бу – арена, үлем монда
Тик тамаша! Күр: кан акса,
Яңгыр юа һәм ком күмә.
Барсын күмә вакыт... Ага...
Яшәү – охшаш корридага!

**3**

Үгез кебек көчле дустым!
Ә безнең соң ир-егетләр,
Сабантуйда мәйдан тоткан
Батырлар, Алып кебекләр,
Нишли хәзер туган илдә?!
Татарстан – туган җирдә
Тиздән сабантуйлар җитә.
Җилкендерер безнең җанны
Туган як, көрәш мәйданы
(Мин батыры булалмадым!),
Күпме янып мин карадым.
Тыныч бәйрәм, көч сынашу,
Ирлек урыны – сабан туен...
Түгел үлем һәм кан уены:
Халыкның үлмәс җыены!

Үгез кебек көчле шагыйрь!
Бар безнең дә шигъри мәйдан,
Анда без дә бер хәрәмсез,
Көнләшү – аяк чалусыз,
Бил алышып көрәшәбез.
Кем чын батыр? Сынап аны,
Күреп халык үзе таный.

Шуңа кайчак сөзешүләр,
Маңгай белән этешүләр
Була калса, әй, шагыйрь дус,
Хәл итәр вакыт-хөкемдар!
Бар судья-чор: ә ул исә

Иң усал мөгезне кисә –
Сөзешер идең, авырта...
Йә сине эш аты итә...
Усаллык кая! – арыта...
Юк, барыбер, безгә, шагыйрь,
Үрнәк бугай тореадор;
Кирәк икән, бу гомердә
Җәлилләрдәй, чын ирләрдәй,
Без горур барыйк үлемгә,
Көрәш – бер һәр чорда җирдә:
Ир язмышы булсын – иргә!

**4**

Испания, ирләр иле! –
Мәңгелек Коррида иле;
Ташларыңда үгез каны,
Ирләр каны... Үлем каны...
Үлемнән курыкмас ир ил,
Шулай атар идем сине,
Бүгенге Испанияне.
Әллә кайчан җанда иде
Синең горур, гүзәл сурәт.
Хәзер күрдем мин үзеңне –
Шуңа озак сурәтлимен! –
Инде кунак шагыйреңне
Ныграк аңларга син өйрәт
Чын рухыңны, испан иле!

Франконың үгез башы
Түгел хәзер байрагыңда,
Кырык ел бит сыкрап яндың,
Республика җиңелгәч, син
Зур яра йөртteң җаныңда.
Хәзер – өмет байрагыңда.
– Но пасаран! – дип киткәннәр
Кайтты кабат ватанына,
Инде ярты гасырдан соң
Җырлар кайта үз иленә,
Испания кайта үзенә! –
Дон Кихотлар гүя кайта
Сагындырган Ламанчына,
Исән җил тегермәннәре,
Канатларын чишкән алар, –
Көтеп алдылар җилләрне!
Исән халык өметләре,
Дульсинея кебек кызлар,
Җир улы Санчо Пансалар,
Исән баск егетләре...
Астурия, бүген синдә,
Кастилия ташларында,
Гвадаррама тауларында
Таныйм сине, көрәш иле,
Таныйм яңа Испанияне!

**5**

Әй сез, борынгы кальгалар! –
Шәһәрләрдә әлхисарлар! –
Сезне күреп гаҗәпләнмим:
Беләм, күпме эзе калган
Бу якларда гарәпләрнең:
Мавританнар стилендә
Сарайлар да, фонтаннар да.
Колак сал гына – көйлиләр,
Гүя азан тавышы килә –
Әндәлестә, Гарнатада,
Картабада мең ел элек
Сәедләрең сөйли кебек,
Шәрекъ канлы гареп җире,
Искә алган Тукай сине!
Испан белән гарәп җыры –
Фонтаннарың дәртле әле.
Тама ләкин кем яшьләре?
Кайда киткән ул чорларның
Идел-Болгарыма җиткән
Гарнатидай галимнәре?!
Тарихчылар, фән ирләре?!
Ләкин шуннан килгән, беләм,
Ул чорның фән җәүһәрләре,
Китаплары, белемнәре;
Түгел гарәп җәберләре,
Алгебралар-Әльҗәбралар
Калган синдә испан иле, –
Гарәп сүзе, эзе һаман,
Ләкин тынган «кичке азан».
Испан-гарәп кушылган чор
Калган тик шигырь канында –
Моңсу да ул, дәртле дә ул
Халык романсларында!
Синең җырлар – романсерон,
Безнең көннәр Гранадасы,
Нинди чишмәдән чыга соң?!
Фонтаннардан сулар ага,
«Күз яшьләре чишмәсе» дә
Бар шагыйрьне аткан җирдә –
Айнадамар – һаман агар...
Яңа җыр туармы анда?!
...Кичер безне, испан җире!
Юл төшмәде Гранадаңа.

**6**

Барселона, синдәме ул
Колумбка... кем, Изабелла
Фатихасын биргәч, юлга
Беркөн тәвәккәлләп чыккан
Данлы кораб – «Каравелла»?
Испан иле! Син үзең дә
Гасырларның корабы ла,
Америка ачып кына
Бәхет иле булмадың ла:
Күпме чорлар син айкалдың,
Йә тулды трюмың синең
Алтын белән, йә буш калдың.
– Колумбкача Испания,
Нигә портыңда калмадың?

Материклар азмы иде,
Нигә дөньяны айкадың?
Бәлки, башка булыр иде
Тарих үзе, чорлар җиле...
(Тарих агышын сүтәм – тиле!)
Бүген нәрсә көтә сине,
Нәрсә көтә бүген җирне?!

Илле ел элек шул сорау
Яуда күпме кабатланды,
Синдә, канлы Барселона!
...Җавап бирерме корабың, –
Нәрсә көтә испан илен,
Ник дәшмисең, «Каравелла»?!

**7**

Төнге Мадридта йөрдек без –
Атаклы мәйданнарында;
Франкосыз илнең инде,
Триумфаль аркаларыдай,
Иркен, киң урыннарында,
Ирекле урамнарында
Уйлап йөрдек: булгандыр ла
Ярты гасыр элек монда
Республика ирεге өчен
«Интернационал» җырлап
Мадрид өчен сугышларда
Башын салган якташлар да.
Әй, илдәшләр, улларыгыз
Сезне искә ала монда!
Ә исәннәр көрәш рухын
Республика җиңелгәч тә,
Алып кайткандыр Ватанга,
«Испания кайтыр!» дидек,
Юккамыни ул чакта да?!
Шул ышаныч белән кердек
Илләр азатлыгын яклап,
Фашизмга каршы, утка –
Халыклар ирεген җырлап
Янды Җәлил Моабитта.
Без тугры һаман шул рухка:
Эзлибез дөньяны урап,
(«Эзлибез Европа буйлап»)
Көрәштәшләрне бүген без,
Һәм яңа сугышка каршы
Теләктәш дуслар эзлибез,
Төрле җирдә, төрле телдә
Көрәш романсы көйлибез.

Без килдек, Испания, сиңа:
Дон Кихотлы бөек илгә,
Синең хаклык рыцарьларың,
Зур идеаллы ирләрең,
Ышаныйк, яши бүген дә! –
Дәвам итә синең данны,
Кызу рухлы, корридалы,
Әфлисун һәм лимон исле
Һәм көрәш, көч, моң бөркелгән
Җырлар туар һаман синдә,

...Төнге Мадрид урамында,
Шаулы, шат мәйданнарында
Сөйләштек без, ике шагыйрь,
Катлаулы заман турында.

Җырлап йөрдек Җәлил өчен,
Батыр Фатих Кәрим өчен –
Рәхмәт көчле җыр, моң өчен! –
(Әйттек остаз шагыйрь исемен)
Зур максатлар булсын юлда,
Вак эшләрдән, тар хисләрдән,
Ызгышлардан, бәхәсләрдән
Арынырга – тагын монда
Ант иттек! – Туды яңа җыр
Республика урамында.

Горур илнең башкаласы!
Зур мәгънә – сиңа килүдә,
Йөрәкләр аңлашсын синдә –
Үлемсез Лорка илендә –
Изге синең туфрак-җирдә:
Юккамыни Европаның
«Мадрид сөйләшүләре» дә
Дәвам итә, шәһәр, синдә –
Без булган бу көннәрдә дә?!

Дөньякүләм аңлашулар,
Килешүләр, дуслашулар,
Акыл, хаклык урыны бул
(Уянсын яңа Колумбың!)
Син, борынгы Испания, –
Яңа рухлы Испания!

*Барселона–Мадрид–Казан*

* * *

Истанбул!
Ничә тарих катламында,
Ничә диңгез ягасында
Һәм кыйтгалар арасында
Һаман исән кальга син...

Гасырларның сәүдәсендә,
Дипломатия телендә,
Илләрнең теләкләрендә
Гел яңгырап баргансың:
– Истанбул!

...Олуг Солтан сарайларың,
Җами, Ай-Суфияләрең,
Һәм айлы манараларың
Хыялданмы хисап ул,
Истанбул?!

Босфор аша күперләрдә
Европага – Азиядән,
Бүгенгегә – үткәннәрдән
Илтә нинди кыска юл?!
Нинди теләк,
Истанбул?!

Табигатең сокланырлык,
Халкыңа хас чын горурлык...
«Шул халыкныңмы хаккы юк»
Бәхетенә,
Истанбул?!

Истанбулда бер кош бар, дип,
Канатында көмеш бар, дип,
Үзем монда, ярым анда,
Арабызда диңгез бар» дип,
Кем ул җырлый,
Истанбул?!

Диңгез түгел, уй, сүз, ахры,
Аерган безнең җаннарны...
Тик ышаныйк: үтәр барсы,
Якынайтыр халыкларны
Акыл, йөрәк,
Истанбул!

* * *

Азиз Нәсин! Син ни дисең?
Бүген менә синең белән
Татар әдипләре. Без кем
Көлү-һөҗү шаһы өчен?
Безгә кадерле зур исемең!
Бүләк китабыңны бүген
Биек тотам:
дөнья күрсен!

Үзгәртерме җирне көлү,
Бомбалардан көчле һөҗү
Уятырмы илләрне соң
Тыныч, зур бәхете өчен?
Ни уйлыйсың, кылыч сүзле,
Моңсу күзле
Азиз Нәсин?!

Ятимнәргә йорт төзисең...
Җирнең үксезләрен, бәлки,
Сыйдырмас ул йортың синең,
Әмма беләм: күңелең киң!
Әлегәчә әдипләрнең
Йорты төрмә булды, димсең,
Шуңамы ап-ак чәчләрең,
Йөзең моңсу,
Азиз Нәсин?!

Насретдиндай мәшһүр исемең,
Бөек Төркия безгә – син:
Киләчәге зур, якты, чын...
Юкса синсез монда кем без? –
һәм гаугалы дөньяда соң
Бер-беребездән башка без кем,
Азиз Нәсин?!
Син ни дисең?!

## ТАШКА ЯЗЫЛГАН ҖЫР

Хәере белән!.. Җырның башы булсын!
Язылды бу – бер юл.
...Июль. Тарих мең дә тугыз йөз дә
Җитмеш җиденче ел.
Шәһри Болгар энесе ак Казан
Тарафы – бер авыл...
(Үзе җиңел кебек бүген уйлар,
Үзе шундый авыр.)

Тауга мендем. Күрим, кемнәр ни дип
Язганнар ташына?
Ничә сәгать утырам күз текәп
Шушы тау башында.
Бәлки, иң кирәкле сүзне бүген
Таштан укып табам?
Бәлки, шунда васыятен уйган
Бер-бер оста – бабам?

Ташны еллар юган... Ә мин бары
Кәгазьгә җыр язам.

Укырлармы эзләп васыятьләрне,
Имин булырмы Җир?
Минем тауга алмаш, дәвамыммы,
Җилгә бирергәме язганымны –
Кайсы онык килер?

Шәһри Болгар дәвамы Казаным
Тарафы – бер авыл.
Ташта бик борынгы бер сүз – җырдан
Исән калган бер юл.
...Ләкин җанда ул җыр!

**ФЕНИКС – ҮЛЕМСЕЗ КОШ!**

Әй, Феникс, әкияти кош!
Күктә
Өч әйлән дә кил, җиргә төш!
Янып көл бул,
Үз көлеңнән янә терел:
Синдә шундый зур сәләт, көч.

Әй, Феникс, тылсымлы кош!
Сөйлә, күпме мәдәният,
Күпме тел, җыр, әдәбият
(Әй, Көнбатыш!.. Син, Көнчыгыш!)
Олы тарих дәвамында
Юкка чыккан – алар кайда?
Ул халыклар үткәненнән –
Үз көленнән –
Кабат терелеп, яралырмы?
Тагын алар җанланырмы?
Тарихта бар, бар яңарыш –
Янып, янә чәчәк ату – ренессанс!

Әй, Феникс! Безгә күрсәт
Син шулардан тере сурәт:
Янып терел бер каршымда,
Хәтерләт – аң, җанны уят,

Аннан... башка җирләргә оч!
Әй, Феникс, үлемсез кош!

## ҖИТМЕШЕНЧЕ ЕЛЛАР БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ

Әйе, үттегез сез...
Хушыгыз, мәңгелеккә,
Җитмешенче еллар!
Хушыгыз!
Әһле каләм, күңелләргә алыгыз:
Бу еллардан
Гыйбрәт булыр ни бар?

Тулы көчкә җиктекме без җанны,
Янып
Эшләдекме эшне?
Акылны без хаклы яклый белдек,
Тыймадыкмы хисне?
Шаулы ярсу шигырьгә алмаш
Безгә
Шулай хуш килдеме?! –
Тыныч, тын булганга, әйбәт, дидек
Түгелме шигырьне?

Җитмешенче еллар!
Ә бит сездә иде
КамАЗ, БАМнар рухы...
Сезгә аваздашмы безнең иҗат,
Һәйкәл булырлыкмы?
Калырмы соң лаек истәлекләр
Сездән – шедеврлар,
Онытылмас җырлар?!

Киләчәктә әйтерләрме:
– Күрегез,
Онытмагыз, кайтып өйрәнегез.
Җитмешенче еллар!
Үттегез сез...

Эшләнмәгән эшләрне уйлап, бәлки,
Хәзер вөҗдан елар,
Бәлки, соңдыр. Хушыгыз!
Әһле каләм, инде аң булыгыз,
Языгыз!
Ишек шакый сиксәненче еллар:
– Әй, саумысыз!
Котлы булсын туар яңа җырлар!

## ХАЛКЫМ БЕЛӘН

*Сибгат ага Хәкимгә*

Ике кеше күрәсез миндә –
Ике шагыйрь – яхшы кайсысы?
Кайсы аның фәкать хыял колы?
Ә кайсында Ватан кайгысы?

Кайсы икән мине – җир баласын

Марс авылы киңлекләреннән
Биеккәрәк дәшеп, романтика –
Хыял күкләренә китергән?

Кайсы аның гамь, шатлыклар телен,
Бабамнардан мирас – моң илен
Үзенеке иткән? Халык белән
Уртак җырым... Моңым бер минем!

Нигә ике кеше? Игезәгем –
Алчак күңел өчен җәзадыр?!
Бер-берсенә дошмандыр бит миндә
Ике зур көч – Алла, Газазил?!

Берүземдә – ике... Ә бит уйда
Максатта бер кояш – яктылык.
Үстерерме мине чын ир итеп,
Үтерерме рухи каршылык?

Яши миндә, яши игезәгем.
Юлым җиңел түгел, беләм мин.
Ахыргача бара алсам иде
Халкым белән, сезнең белән мин.

Ике шагыйрь сез күрәсез миндә...

## ҖАВАП БИР, ТАБИГАТЬ

Табигать! Сорыйм, җавап бир,
Соравым – йөрәгемнән:
– Күчеп китмәдеме җаным
Беренче тирәгеннән?
Җуймадыммы хыялларны,
Омтылыш, теләкләрне?
Саумы җан эзләнүләре,
Тибрәнеш – күкрәктәге?
Җиргә тик гашыйклар кебек
Сокланып карау хисе
Яшиме миндә? Исәнме
Өметнең сихри көче?
Бер шиксез, шашып, яратып
Ашкына белгән сәгать,
Гаҗәпләнә, табына алу,
Рух очышына сәбәп –
Эчкерсез, табигый халәт!
Син миннән китмәдеңме?
...Тәңрем – Табигать! Шулар соң
Беркөн ят итсә мине,
Аерылсам иң зур байлыктан –
Хушлашсам мин гамь белән?!
Бүгенге, канатлы яшьлек
Миннән баш тартыр, беләм. –
Табигый ихлас нәфрәтен
Ул әйтә калса – хаклы:
Килешүләргә бармый ул,
Бар дөнья яшьлек яклы.
Ышана ул: үзгәрмәс һич,
Ул тугры хакыйкатькә.
Ул хыянәт итмәс мәңге

Зур хискә – мәхәббәткә,
Иманга, рухияткә.

...Ул ни әйтер минем хакта,
Җавап бир, Табигать, йә?!

## АЛИБИЛАР БУЛМАС

...Без – бүгенге заман шаһитлары:
Сонгмилар янган, напалмнар шартлаган,
атом янаган,
гаугалы Җир кешеләре –
нәрсә әйтер идек икән
чорыбыз җинаятьләре өчен,
иртәгә хөкем була калса?!
Кайда алиби?!

– Без әле яшь идек... Күрмәдек, белмәдек,
бәхетләрдә онытылган идек, –
дисәк, ышандырмас ласа!

Киләчәк ул фаш итәчәк
үз вакытында көрәштән качып,
 читкә борылган йөзне,
гыйш-гыйшрәткә чумган каләмнәрне,
гамьсез, битараф күзне;
Җиргә ташласа ул
ак перчаткалы кулыбыз
 пычраткан кәгазьләрне?

Дөнья өчен янып яшәмәсәк,
тарих гафу итмәс безне,
алибилар булмас, чордашларым;
Җинаятьтер бүген:
– Мин гаепсез, намусым пакъ, – диеп,
үз-үзеңне юатып яшәү, җирдәшләрем!

## ОЛҖАСКА

Олҗас!
Кил Казанга,
яши монда калган
истәлегең синең.
Ышан:
заллар хәтерлиләр тавышыңны,
сагыналар, димен.

Олҗас!
Монда синең якын кардәшләрең –
төрки моңнар яши.
Сагына сине – күреп бер яраткан
яки укып белгән җолдастарың:
сагына
карты-яше.

Олҗас!
Аңла, кил Казанга, тагын безгә
җырлар алып кил, дим:
исән синең матур хатирәләр!
Хатирәләр – имин...

* * *

Әй, суынмагыз, хисләрем,
Суынмагыз... Сез түгел,
Көз җиткәч саргаер яфрак...
Җанда да бит көз түгел.
Юк, суынмагыз, дусларым!
Янарга чакырам сезне.
Минем белән ахыргача
Җанымда барасызмы?
Анын күзләренә бергә
Йотылып карарбызмы?
Кабат-кабат кабынуны,
Хисләрем, аңларсызмы?
Саклап булыр бит яшьлекне?
Үз-үзеңне алдалап,
Соң кабат яну түгелме?
Мәхәббәттән армаганмы
Җан – ям чапкан аргамак?

Әй, ярсымагыз, хисләрем,
Шашынмагыз. Сез түгел
Яшел язның яшь яфрагы...

Юк, суынмагыз, яныгыз,
Бу – эссе җәй, көз түгел!

Җәй уртасы тик, хисләрем!

## ТАКТАШ ТАВЫШЫ

Шагыйрь тавышын –
бер кабат та ишетмәгән,
ләкин гүя иң якын танышым –
Такташ тавышын эзлим, эзлим һаман:
нинди җылы тембрларда,
аһәңнәрдә яңгыраган,
нинди моң ул
хәтерләрдә калган?

Грамзапись та юк
Радиофондта, ни үкенеч! Сакланмаган.
Ә бит, бүген һәр «озынчәч» кулындагы
магнитофоннар, сез
ул исәндә булсагыз...
Тавышын шагыйрь һаман яңгыратыр иде!

Бүген тагын бер танышым:
– Такташ тавышы калмаган шул, – диде.
Такташ тавышы?
Ә соң шагыйрь яшәмиме бүгендә?
Ул түгелме безнең җырлар,
симфонияләр
һәм поэмаларда? Бездә?!

Ни уйлыйдыр бу турыда минем «дустым» –
сәер очрак! –
Такташ шигыренең ревизионисты!
Яңгырый, дәвам итә Такташ хәтта анда.

Ул «Киләчәккә хатлар»да.
Сагынычлы тавышы, еллар белән
ачыклана тик, көчәя ләса!
Гел ишетербез,
йөрәкләр саңгырау булмаса.
Мәңге аның тавышын! –
үлмәс шагыйрь тавышын тыңлыйк, дуслар!

* * *

Яндырыгыз күперләрне,
Хыяллар! Алданмагыз, –
Калсын ул җырлар яшьлектә,
Бүгенгә ялгамагыз;
Кырык яшькәчә гомернең
Күңелдә алтын томы:
Ихласлык тарихы итеп,
Хисләрем сайланмасы дип
Калдырам, яшьләр, аны...
Күперләр янсын – узганга,
Хыяллар, ялганмагыз,
Хушлаша белик – яшьлекне
Кабатлап тик янмагыз...
Шат көйләр – кырыкка кадәр,
Калдырдык яшел ярны...
Чакыра хәзер аргы як,
Әмма су салкынрак, – әллә
Кояшның сүрән чагы?..
Инде өлкәннәр ярында,
Аек карап чынлыкка,
Акылга, бәлки, таянып,
Кырыслыгыннан курыкмый,
Җавап бирик тормышка...
Ә беренче алтын томын
Гомернең... нәрсә әйтим,
Сагынсагыз, хыяллар, сез
Күперләр сузып карарсыз...
Ялганмас кабат ләкин!

## ЯШЬТӘШЛӘРЕМӘ – ШАГЫЙРЬЛӘРГӘ

*Ренат Харис, Гәрәй Рәхим,*
*Рәшит Әхмәтҗановка һ.б.*

Кырык беренчеләр, әй, яшьтәшләр!
Күрегез:
җиттек ләса кырык яшькә,
Ераклаша елга башланган җир,
Ярлар бер-берсеннән ераклаша.

Ашмый йолдызларга –
Җыр да
Җиргә төшкән инде –
гадиләшә.

Кырык беренчеләр,
без дә кырык яшьтә!

Ә бит
Әле дә сискәнәләр кебек
кешеләр:
– Без – кырык беренче елгы, – дисәк, –
кырык беренчеләр...

Үсеп җитә инде безнең уллар,
Шундый матур алар туган еллар,
Моңсулыкны белмәс
алар язган җырлар!

Ә без –
Кешелек хәтере өчен
Һаман тере яра төслеләр.
Түгел ләкин бәхетсезләр:

Тормыш шундый матур ласа,
яшьтәшләрем!
Улларыбыз – әтиләләр,
Кырык яшьтә без дә,
кырык беренчеләр!

## ОЗЫН-ОЗАК БАЛАЧАК

*Мостай ага Кәримгә*

Нинди кыска син, Балачак! –
Күз ачып йомган арада
Яктың ялмап алачак,
Аннары китеп барачак...
Юк, мәңгегә калачак!

Шундый озын син, Балачак!
Ил-йортта изге учак,
Туган тел, әнкәң догасы,
Акйолдыз сөюе – барсы
Дөньяга озатып калачак,
Юлдаш булып барачак. –
Утлардан алып чыгачак:
Язмышлардан да узмыш бар,
Тик ташлама, Балачак!

Иң матур ил – син, Балачак!
Шагыйрь булсак, мәңгегә рух
Шушы илдә калачак.
Аңа тугры булса гына,
Хис хыялга юл табачак –
Гамьле дип ат алачак.

... Гомер, гомер! Ахры, син дә –
Дәвамлы шул Балачак, –
Озын-озак балачак!

## СӨН ЯРЫНДА, АВЫЛЫҢДА

*Роберт Миңнуллинга*

Башкортстан туфрагында,
Шәммәттә – авылыңда,
Нигә уйчанландык әле
Йөргәндә Сөн ярында!

Актаныштан дәшеп алды
Илешең – иген иле.
Атаклы Рахманов агай*:
– Күреп китегез, – диде.

Сөнне кичтек. Озатып калды
Теләкәй, Байсар ягы.
Сабантуй белән каршылый
Сарьян, Баяннар яры.

Күптән монда яңгырлар юк,
Кырларда иген көя...
Кешеләрнең күктә күзе!

Без – бер драматург, өч шагыйрь
Һәм тәнкыйтьче – гүя
Җиргә төштек кинәт.

Бер-бер
Вакытсыз уен сыман,
Онытылды «интеллектуальлек»,
(Фәйзуллин үпкәләмәс бит?!)
Жанрыбыз – туфрак, сабан.

– Мамадышта йә Шөгердә,
Сәрмәсән, Агыйделдә
Авылдашлар нишли? – дибез, –
Ни хәл агай-энедә?

Читләшмәдекме нигездән?
Үзгәрмәдеме иман?
Булдыкмы туган җирләргә
Дым сыман, шифа сыман?

Ни ярдәм итик бүген соң,
Туфрак көйгән чагында?
Бишәүләп дога укыйкмы
Картлар күк – яңгыр сорыйкмы
Әллә соң Хан тавында?

...Әдәплеләндек шактый без,
Әйбәтләндек тагын да
Синең туган нигезеңдә,
«Кесәл ярлы сөт елгасы» –
Син сөйгән Сөн ярында,
Шәммәттә – авылыңда.

## МӨҺАҖИР

Пристань,
Яшел дебаркадер,
Ак пароход. Күк төтен...
Төтен күк язмыш юлыннан
Йөз ел элек, яшь бер шагыйрь,
Мөһаҗир!
Син кая, нигә киттең?

Уфылдаган ак пароход
Кузгалган булыр ярдан.
Таш кебек катып киткәнсең,
Күз алмый туган ярдан
Билгесез якка табан.

Ә ярлар күмелә барган,
Ил ерагайган һаман...

Күпме карагансың читтә
Алсу шәфәкъка табан:
– Гомерләр дә шулай байый,
Туган җир күздән югалган,
Буталган дөнья, заман...

Кая йөзәбез, кая без?
Корабка туктар җир һаман
Күренми...
Ил, бул аман!

Кайда соң адашкан җаның,
Кайда ул ялга талган?
...Юк, читләрдә онытылмаган,
Тик якты көнгә омтылган,
Кояшка баккан Казан:
Кайталар томан артыннан,
Күк горизонт аръягыннан
Васыятьләр илгә һаман –
Ачы шәрабтай моң, җырлар...
Язмышы мөһаҗирләрнең
Әй ачы икән, яман...

Кай җирдә соң синең кабер,
Исемең билгесез мөһаҗир! –
Соңгы сәламеңне кем
Алып кайтты гыйбрәт өчен?
Ил, Ватан күңеле иркен;
Соңгы сүз сыя...

Пристань.
Кемнедер монда көтмим.
Уйда әллә бер-бер язмыш,
Әллә күгелҗем төтен...

## ЧИСТАЙ КЫЗЫ

Шигъреми җәйдем аягы астына...
Г.Тукай

Мин – Чистайда... Бүгенгедә, уйда – башка чорлар:
Җитмеш ел элек булганга кайта һаман уйлар...

Ага Чулман, вакыт ага – санап сәгатьләрне,
Көтә яшь кыз. Өмет өчен бармы сәбәпләре?

Пароходлар килә, китә... Юк, пристань моңсу,
Килми Тукай – Зәйтүнәгә ник күңелле булсын!

Авырттыра минутлары җанны, сәгатьләре...
Нигә кысып тора аны мишәр гадәтләре? –

Юкса чыгып китсә иде үзе Казаннарга!
Анда – Тукайлы газетлар, урамнар, заллар да...

Казан гөрли, һаман нурлы, уты уңайлы күк...
Бөтен төше җанга җылы – һәр җир Тукайлы күк!

Фатих агасы Әмирхан хат лабаса яза,
Ә соң Тукай? Юк бер хәбәр, инде ничә яз ла!

Ага Чулман, ага вакыт... Чистай сәгатьләре...
Барып күреп кайтыр өчен юкмы сәбәпләре?!

– Калфагымны ташлар идем дулкын иясенә,
Чистай, пароходта җитеп Тукай килсә сиңа!

...«Сәйяр» килгән... Кари-артист сәлам алып килгән...
Ә соң үзе? Үпкәлиме? Нигә килми икән?

Әнкәем, дим, кызыгызда шундый читен хәл лә...
Ул шагыйрьгә үзе башлап: «Сөям!» – дисен әллә?
Казанда бит таныштылар. Әй кызарды шагыйрь.
Кызык гашыйк... үзен шуңа, бәлки, атагандыр?

Өстенә конфетти сибеп, серпантиным белән
Ураткында, җан бәйләнгән, кем соң аны белгән!

Ә нигә әле чәчләре бәйләнми соң чәчкә? –
Менә хәзер, Чистай кызы, көтеп, янып яшә...

Менә хәзер килер сиңа тетрәндерер хәбәр:
Татар тетрәр, елар мишәр – уянырлык хәлләр!

Халык пәйгамбәре үлгән!.. Ябь-яшь көе киткән...
Зәйтүнәне калдырган ник? Ул соң нишләр икән?

Чулманга карап еларга, уйланырга кала...
Татар кызы, синең язмыш, һай, аяныч, бала!

...Сагыныр ул гомер буе – Тукайны үзенчә:
Татар кызлары исеменнән, хисе – пакь көенчә.

Ул күрсәтми түгәр яшен, эчтә саклар утын,–
Бер генә очратмас юлда «Тукай» пароходын!

Әдипләр килер... үз улы – истәлекләр сорап,
Ул елмаер моңсу гына... үткән – шундый ерак!

Ул шул изге хискә, моңга багышлар гомерне:
Ул Тукайны саклар җанда – бөек яшүсмерне!

...Ә Чистай каласы – башка: ил яшәрә бара.
Шаһит – Чистай сәгатьләре... Вакыт ага. Ярда –

Пристаньда ябь-яшь кызлар кемне каршылыйлар?
Туктар да пароход. Тукай... Юк, егетләр чыгар.
Кочаклашырлар яшеренми кеше алдында ук:
Саф яшьлектә, ихласлыкта гаеп тамчы да юк!

Үзгәргән лә хәзер – яңа мишәр гадәтләре...
Бәхетләрне саный инде, Чистай, сәгатьләрең,

Мин дә Чистайда... Бүгендә, әмма уем – ерак...

Кайта Тукайның бердәнбер сөйгәненә йөрәк...

Аңа һәйкәлме язганым? – Нәни генә ядкарь...
Бөек шагыйрьнең үз җыры, беләм, мәңге яшәр!

## ТАРИХ ӨНЕ

...Аһ, туган каумем газиз!

*Дәрдемәнд*

### 1

Дүрт йөз еллык карт сагышмы,
Каргалган кара язмышмы? –
Төнозын кем иңри?!
Казан, ишетәмсең? Кем өне?
Җанда ни ул тетри?!

Шәһит киткәннәр дәшәме
Яки авыр сулый?!
Асыл угланнар нидасы?!
Әллә кызлар елый?!

Казан, кирмәнеңдә төрбәң...
Кайда хан кабере?!
Сөембикә яше тамган
Туфрак, ил бәгыре
Сызамы һаман, сыктыймы?!
Ханбикәме елый,
Тәхетеннән аерылганда,
Җилкәнен җил кыйный?
Идел ярында гөжлиме –
Халык ярсый, дулый?
– Ил, нишләдең?! Әй, морзалар!

Үткән ничә гасыр...
Сөембикә елый – яше
Таш шикелле авыр.
Каргыймы илен ханбикә?!
(Уятырга тели!)
Һаман фатихасын бирә:
Актык сүзен сөйли.
Ничә дәвер болытында
Сөембикә аһы...
Идел томаны, син булдың
Аның соңгы тәҗы...

– Гүзәллекне сакламаган,
Якламаган илне
Афәт алып, соң чиккәчә
Хәлсезләнер имди...

Халкым, нәрсә булды сиңа,
Нәрсәдә ялгышың? –
Күрәчәгеңне аңла: ул –
Үтәмеш язмышы...
Ханзадә Мәскәү кулында,
Дине – тотык, теле...
Уйлан, халкым!
Соң мәртәбә

Кисәтергә телим!

Уян, яуга туплан: тиздән
Дәһшәт – патша килер...
Ныкмы кирмән? Капка бигең?
Бул бәхил, җан-илем!

Нугай, Әстерхан, Кырым,
Себер нәрсә уйлый?!
Иртәгә – алар...
Ә бүген
Болгар-Казан елый...

Вөждан, синме? Кем авазы? –
Ерак тарих өне?
Ничә гасыр аша җанда
Ни ул сыкрый минем?!
Сагыш, синең өнме?!

**2**

– Халкым! – дисәм, минем моңа
Бармы әле хакым?!
Сагышыңның һәр катрәсен
Татыдыммы, халкым?!

Сөннәрдәнме, кыпчактанмы,
Болгарданмы затым –
Ике мең ел... катлаулы юл...
Мин уздыммы, халкым?

Далалардан, балбаллардан
Юл башыңны байкыйм,
Кыйтгаларның ташларына
Тарих язган халкым!

Грюнвальдта тамган каның;
Куликовода соң?
Шаһгалиләр белән йөргән
Ул да синме, халкым?!

Япанчы кебек ирләрнең
Оныттыкмы атын?
– Вакыт җитте, Ватан өчен
Баш салганнар хакын
Горур яклыйк, халкым!

– Нинди гөнаһ, нинди каһәр
Сине утка атты?! –
Язмыш, нинди хак бирделәр?
Нигә безне саттың?!
(Әй, үлемсез халкым!)

...Нигә синең мирзаларың
Ятка кушты канын?
Канын, данын саткан кавем,
Ул да синме, халкым?!

Идегәйдәй батыр каны
Кемдә генә акмый! –
Руста, ляхта, литвалыда –

Тере дастан, халкым!

Ничә телдә сөйләшә кан,
Ничә дин ул тапты?!
Шуңамы зәгыйфьләндең, гел
Кан өләшкән халкым?!

Кан нәслең Иван патшага
Кол булыпмы калдың?
Аман булырмы ахыры? –
Ниләр көтә, халкым?!

Таралышкан куй көтүен
Кемнәр туплый алсын?
Кайда чабан?
Бүреләргә
Азык булма, халкым! –

...Имамнарың, сәедләрең
Сөйли (Колак салың!),
Биш гасырга якын өнди,
Ишетәмсең, халкым?!

**3**

Мөхәммәдъяр, Кол Шәрифләр
Утлы сүзләр тапты,
Безгә намен калдырырга:
Исән алар, халкым!
Чал язмыш, карт Сагыш өне
Бүгенгедәй якын,
Җанны өтә, шуңа бүген
Йокы качты, халкым!

Аңлыймы әй «газиз каумем»,
Даулыймы үз хакын?!
Мәхәббәтме, нәфрәтме ул
Яшь җаннарда, халкым?!

– Син – үзең турында үзең
Кайгыртмаган халкым!
Ятларга ярап, үзеңә
Хәтәр яман халкым!

– Башкаларга эттәй тугры,
Үтә кызыл атың...
Ятларны баеткангамы
Фәкыйрь калдың, халкым?!

– Чит җирләр кояшын яклап,
Үзең Айсыз калдың.
Дөресме, «акылың» синең
«Төштән соңмы», халкым?
– Йоклыймы ул милли аңың,
Үләргәме якын?
Башкалар бит күтәрелә,
Үсә бүген, халкым!
– Яшәрмәс картмы вөҗүдең,
Мәхлук булып калдың?
Пәйгамбәрдәй улларың да

Уятмыймы, халкым?!

Үлмәс өчен хәйлә әллә
Кәсеп булып калды? –
Һәр тиранга баш ияргә
Өйрәндең дә, ахры,
Турая алмыйсыңмыни? –
Ничек шулай каттың?!
Яңарып бер, тагын горур
Яшәрсеңме, халкым?!

**4**

Кем сине бәйгегә дәшсен,
Йөк тарткан эш атын?!
Ташыйсың, салам ашыйсың,
Талымсыз, пакь халкым!
Дәшмәс, каршы әйтмәс, телсез
Үшән, күндәм затмы
Синең сурәт? Ничек шундый
Хәлгә калдың, халкым?!
Иң асыл ирләрең бүген
Нинди «иман» тапты:
Җылы урын, тамак, дан дип,
Денен, телен сатты?
Сатарга әзер сине дә –
Үз әнкәсен, халкым!
Изге гамь, хыялны алар
Күптән утка атты.
Уйсыз, мәнсез маңкорт бүген
Милли бакчаң таптый,
Оялмый һич, халкым!

Ә мин соң яклый алдыммы
Алардан чын затың?! –
Курка түгелме дәшәргә
Синең улың, халкым?!

...Мөхәммәдъяр җанда инри,
Кол Шәрифне аңлыйм...
Япанчы язмышы – уйда.
Бер гаепсез, ак, дим,
Узганыңны, халкым!
Мин – рухи варисы илнең,
Бабамнарны аклыйм...
Сакларга асыл мирасны
Соңгы ант бу, халкым!
Халык кадәр халык бит без,
Исән тән, сау акыл...
Уянырсың! Ахыр юлың
Биеклеккә, халкым!

*

Сөембикә, манараңа
Ай кунар бит тагын?! –
Кабат кайтыр таҗың...

Авып, син иңрисең җанда!
Узып бара тагын
Битараф бер гасыр... Күк тә
Дәшми бүген, салкын...

Казан күге! Ә бит синдә
Күпме аһ, моң, ялкын...
Уятачак алар безне,
Тетрәтәчәк, халкым!

## АПАЛАР

Әй туган ягым кызлары! –
Сугыш чоры йолдызлары!
Хәтердә – җырларыгыз:
– Кайсы йолдызлар астында
Йөрегән юлларыгыз?

Кичке уенда һаман да
«Күпер башы» яланында
Моңлы шул тавышыгыз
Бәхетләргә чакырдымы:
– Сөегез, кавышыгыз!

Әй сугыштан соңгы еллар –
Сагышны куган җырлар!
...Юлыгыз кая илтмәде,
Кайда, кемнәр ишетмәде
Сезнең ул җырны, кызлар!
Анда – якты өмет, сафлык,
Сүнмәс мәхәббәт моңы...
Тынмас җиз кыңгырау чыңы
Йә ризык тавышымы?
Мәңгелек яшәү җыры?!

Онытылмады, апалар,
Җанда ул моңнарыгыз.
Әйтегез, сезне бәхеткә
Илттеме җырларыгыз?!
Хәзер нинди язмышыгыз? –
Кайсы йолдызлар астында
Бүгенге юлларыгыз?!

## БӘХЕТЛЕЛӘР

*Әмирхан ага Еникигә,*
*Нәкый ага Исәнбәткә*

Бәхетле сез,
Яшьлегенә хыянәтсез,
Тугры кала алганнар! –
Ап-ак канатларны,
Алтын алма үскән бакчаларны,
Су кызлары көткән кыяларны –
Хыялларны югалтмаганнар.

Тормыш, заман
Кызуына һаман алып керсен,
Туган җирләрегездән ерак кителсен –

Җаныгызда барыбер яшьлек уты,
Мәңге тере гөлләр,
Наз, гамь тулы сүзләр...

...Аргамаклар очып үткән юлда
Нидән әле күтәрелгән тузан?
Кем яшьлеге бүген юлда узган?
Кемгә дәшә җилләр:
– Мең яшәгез, яшьлегенә тугры ирләр!
(Шундыйлар кем?
Янып-янып сүрелмәгән җаннар
Нинди алар?!)

Уйланам да гүя Агыйделгә,
Гүя болын, урманнарга
Юлга чыкмакчы мин... узганнарга.
Үткәннәргә юл юк. Төшкә генә
Керә һаман матур бер манзара:
Көмеш инеш башы. Ташлар... ташлар.
Шул ташлар соң хәзер нинди төстә?
Әүвәлгечә кайнар микән алар?
...Шуңа түгелме икән – бар бит әле
Шик белдергән җаннар:
– Кайда ул – андыйлар?

Ә сез бәхетлесез,
Яшьлегенә –
Үз-үзенә тугры кала алганнар!

## КЫРЛАЙ ЮЛЫНДА

Авыл – Түбән Аты, Югары Аты...
Кайда аның аты?!
Тояк тавышын ишетәм еллар аша, –
Тыңлыйм җиргә ятып.

Кырлай, сиңа юлым. Авыллардан,
Кырдан җәяү атлыйм.
Артка карыйм: куып җитәр кебек
Бик таныш бер атлың.

Мин кычкырам аңа:
– Сәгъди абзый!
Алып бар Кырлайга.
Мин дә нәни Апуш кебек гаҗиз
Бу якты кырларда.
Ал мине дә уллыкка син. Күрсәт
Сихри Казан артын.
...Арбаң инде татар шагыйрьләрен
Сыйдырса да барсын,
Иркен әле анда. Күңелең киң,
Арымаган атың.

Сәгъди абзый, алып бар! Кырлайда
Алтын бер кыңгырау
Һаман чакыра күк. Шунда бәхетем,
Булса да юл урау;
Әй, тынма, кыңгырау!

Сәгъди абзый, күрен... Көтәм күкрәп
Арыш үскән кырда,
Еламамын, биткә тисен уйнап
Сүс чыбыркың кулда.
(Миңа тансык ул да!)
Арбаңа ал мине! Синең белән
Ятим булмам ил җанына –
моңга
Тукай килгән юлда!
Сәгъди абзый, арбаңа ал, көтәм...

## ҖИДЕ БАҖАНЫ ЯКЛАП

Кем сөйләде әле бүген аны –
онытылган иске риваятьне?
– Бүре ашаган, бер бүре –
җиде баҗаны...

Уйлыйм:
ашатмаска,
харап иттермәскә иде бит аларны!
Бүген –
борынгыдан үзгә дөнья,
ул – яңарды.
Саклыйсы иде,
саклыйсы иде ул баҗаларны –
шагыйрьдәй беркатлы, бәлки,
садәләрне!
Ә бүреләр,
ә бүреләр көчәйгәннәр, бәлки, тагы?
Әй, дуслаштырыйк тизрәк,
бердәмлеккә чакырыйк баҗаларны!
Олы максатларга,
уртак изге юлга юнәлтик аларны.
Бетсен элеккедән калган эгоизм!
Теләгем:
какмагыз, кешеләр, илдәшләр –
баҗалар, яклагыз бер-берегезне!
Күрегез,
дөнья бүген әллә бүресезме?
Юк, яши ул Бүре, көчле, таза –
беләбез аны...

Бүген
гүя җиде җырны,
җиде дастан, җиде поэманы,
яклыйк,
ашатмыйк бүредән без
җиде баҗаны!

## УЯНГАЧ

«Уянгач беренче эшем...» –
Васыятеңдәй соңгы сүзең
Яктыртып «Кояш»ның йөзен*,
Тукай, уяндың «мәңгегә,
Инде кабат йокламаска!»
Син үлемсезлек өчен.

Мин – гасыр ахыры шагыйре,
Уятса бер таң сәгатем,
Уянгач беренче эшем
Нәрсә булачак, ни соң?

Юынып, чистарып, садә
Җанымны ачсам мин көнгә
Бары тик аклык өчен,
Заманым булса әйдәүчем,
Иманым – хаклык хисем,
Булырмынмы мин дәвамчың?
Әй, халкым, сиңа бу, сиңа
Уянгач минем эшем!

Күптер, бәлки, ялгышларым,
Тик шул ук – киләчәк өчен
Яну, омтылышларым,
Максатны, юлны Тукайлар
Эшенә багышлавым –
Беренче, намус эшем!

Әй, дөрләп ян, шигъри хисем,
Тик дуслар эшем хуп күрсен;
Замандашым, Тукайдашым,
Мин яратам сине, Кешем –
Туганым, сиңа бу җырым –
Уянгач беренче эшем!

## БАБИЧ

Әй, күңел!
Синең дә
Бар күгең, ул бар ич?!
Ә күгең йолдызлар
Тулы ич, ул бай ич...

Ах, Бабич, йөрәктә
Йөртәм ак исемеңне!
Дөньямны тагын да
Саф итәр өченме? –
Сагынып мин сине,
Кабатлыйм исемеңне!

Кошлар күп һавада –
Лачыннар, күр, аз ич!
Син – биек очалган
Горур кош, әй, Бабич.
(Хыял дус, ул кошның
Канатына ябыш.
Каурыен булса да
Калдырыр...) Әй, Бабич,
Исемеңнән ничә ел
Шигъри күк балкый ич.

Күпләргә ут бирдең,
Шигъри ут син, Бабич!
Исемеңә җыр язам –
Багышлау – ул бар эш!
Син көч бир, туган тел,
Илһам бир, әй, Бабич!

*

Гүяки сабантуй!
Гүяки зур ярыш.
Шигырьдә ярышу,
Сүз атында чабыш...
Син кайда, әй, Бабич!
Җиңәрсең син барсын,
Канатың, көч-атың,
Талантың – ул бар ич!
Казакъта – далада,
Башкортта, татарда,
Күр, хикмәт күп сүздә:
Чәчәннәр ярыша,
Гүя бил алыша –
Җиңдерми берсе дә...
Әй, мәшһүр шагыйрь, син –
Моң кошы, сүз кошы,
Кайт бүген – шигырьдә
Бер генә сүз кушчы!
Ал һушны!
Көтәбез сагынып,
Бәйрәмнәр, күр, күп ич.
Сабантуй – мәңгелек! –
Әй, кайт син! Биек оч!
Лачын кош, җырчы кош!

*

Иң башта далада,
Аннары Уфада
Йолдызлар күргәндер
Синең шат күзеңне,
Алчак ак йөзеңне!
Аннары дусларың! –
Сокланган – күп кордаш:
Сагынсын һаман да
Шул чакны чал Кудаш...
(Зур юлын узганда
Сагынды Туфан да!)
Гасырның башыннан
Ахырына җиткәннәр,
Сине бер күргәннәр –
Могҗиза дигәннәр
Алар күп, исәннәр...
(Күр: Нәкый Исәнбәт!)
Гомергә сине алар
Остазы исәпләр!
Әй, яңгырат, кайт та бер,
Өфенең залларын.
Уйна, айга ашып,
Атаклы мандолин!
...Йә мәшһүр көлдергеч
Сөйләсен мәзәкләр,
Һөҗүе* утында
Сәүдәгәр – «мәләк»ләр
Канатын көйдерсен!
Көлдерсен, көлдерсен! –
«Гаебен аңлар»лык
Халәткә китерсен!

Кайтып бер бизәкле
Капкасын ачса соң –
Бер күрер идек ич
«Исемнәр бакчасы»н!
Шигърият кырларын
Гөл иле ясар гел –
Булышмас дисеңме
Аңа соң «Газазил»?

Дошманнар күп булыр –
Ә син яз анда да:
Усалрак бит «Шөпшә»,
Көчсез ул «Кандала»...
Өлкәннәр үз итә,
Өзелми яныңнан:
Бүген, күр – Гафури,
Иртәгә – Галимҗан.
«Галия»* әй гөрли,
Гыйлемме ул җыя?
Бал корты – шәкертләр –
Тузгыган күч гүя:
Тәртипкә чакырыр
«Ректор»ыгыз – Зыя
Камали – син язган
Тырыш «корт анасы»...
Казакътан, үзбәктән,
Дагстан, чиркәстән –
Җыелган әй күпме
Юксыллар баласы!
Бирегез аң-белем.
Зур үссен рухият.
...Унҗиденче елда
Килде ул – хөррият!

Әй, барлык тавышыңа
Җырла, Шәехзадә!
Моңарчы үтелгән
Гомерләр, их, зая!
Тик дөнья катлаулы –
Таякны кем алыр?
Байраклар күптөрле –
«Юл авыр, болгавыр».
Галимҗан – Мәскәүдә,
Мәскәүдә – Мулланур...
Кай якка ул барыр?
Аптырап йөргәндә
Чакыра Оренбур...
«Кармак»ка – һөҗүгә
Мәйдан бар, урын зур,
Барам, көт, Оренбур!

...Тик каян калка соң
Тагын бу фетнәләр?
Тәҗрибәсез җанны,
Яшь башны алар соң
Кайларга илтәләр?
«Халкым!» дип йөргәннәр
Халыкка каршы ник?
– Әй, дуслар, кардәшләр,

Хаклыкны саттык бит!
Нигә син дәшмисең,
Битараф ярты ай?
Хаклык штабымы
Син соң, Кәрвансарай?!
Синме соң, Гөлстан,
Җирстан, Нурстан –
Юлың, әй, дөресме
Синең, әйт, Илстан?!
Аңга кил – хаталар
Күбәя, сузыла...

Без сезгә кушылдык!
Кабул ит, кызыллар!
Сез – хаклык дуслары,
Сез – Колчак дошманы...
Таныды бит Ленин
Яшь Башкортстанны!
Мин язам, әй, халкым! –
Сөйлимен бу хакта
Башкортка – халкыма
«Көйле бер хитап»та!
Халкымны чакырам
Иң дөрес юлга мин...
...Ә үзең кайда соң?
Югалдың ни өчен?!
Яктыга чыккачтын
Сүндеңме, Бабичым?!

*

Мәңгелеккә калды
Җырыңда күңелең –
Ак җаның... Инде оч,
Иңлә син ил күген.
Син, димәк, мәңгелек
Җыр өчен туган көч,
Син – лачын, җырчы кош.
...Кошлар күп. Күңел дә
Йолдызга ул бай ич...
Яктырта йолдызың,
Ул якты, гел нурлы,
Исме дә горур ич:
– Шәехзадә Бабич!
Ба-би-ич!

## ЙӨЗҮЧЕЛӘР

*(Диңгез поэмасы)*

Диңгездә шторм бүген, давыл.
Алты баллдан
Һич ким түгел! Үзем сорап
белдем дулкыннардан.
Диңгездә көчле шторм.
Ә кем анда, йөзә
Бик еракта? Куркынычтыр?
Ул – эчтә, диңгездә.
...Кара диңгез, сиңа килдек –
иң зәңгәр диңгезгә,

Нинди гыйбрәтләр бирерсең
бу юлы син безгә?
Дулкыннарың бер-бер артлы
ярны коча торсын,
Бәлки, яңа җыр китерер
тугызынчы дулкын?
Ярдан эчкә кермик, улым,
юк, ярамый безгә;
Йөзеп күнекмәгән...
Кем соң анда –
һаман йөзә?
Дулкыннар белән көрәшә?
Дәрт, дәрманы зурмы?
Яшьтән диңгездә үскәнме?
Бер романтиктырмы?
Без дә коендык, уйнадык
күмелеп дулкында;
Ардык бик тиз, ярга чыгып
ятабыз без комда.
Ә йөзүче... чын диңгезче!
Ул шашкан җан, йөзә...
Ник шундый көч, дәрт, кыюлык
бирелмәгән безгә?
Хәер, син яшь әле, улым,
син йөзәрсең алда;
Син тик сөенеп карыйсың
көчле дулкыннарга.
Кайсы ир җанын соң диңгез
ашкындырмас икән?
Ир җанында – иярле ат
яки кораб, җилкән...
(Әллә җилкән ул хыялның
ак яулыгы микән?)
Корабларда түгел, ләкин
син диңгездә арма:
Колач салып йөзеп,
ышан, күмел дулкыннарга.
Үзеңне киңлек, чиксезлек
хуҗасы исәплә.
– Улым, йөзәрсең зур үскәч
шулай, киләчәктә.
Әй, йөзегез, батыр җаннар,
йөзегез диңгездә!
Мин җыр язам – рухланудан,
сокланудан сезгә.
Бүген уем шаһлары сез
һәм Геллеспонт* – уйда.
...Борынгыдан калган, яши
шундый бер легенда.

*

...Грециядә яшь бер егет –
Леандр** Герога –
Яшь бер кызга гашыйк,
ә кыз яши каршы ярда.
Мәхәббәте ташлый аны
һәр көн дулкыннарга:
Һәр кичтә дәрьяны йөзеп
тиеш ул чыгарга.

Аларны, әйе, Геллеспонт –
бугаз аерып торган,
Бер ярны икенчесеннән,
ә егетне – кыздан.
Леандр ул Азиядә,
Геро Европада.
Килешкәннәр – кыз һәр көнне
ярга учак яга:
Төнен диңгездәге яры
утны күреп йөзсен,
Һәм яшь егет күрә, йөзә
ярга таба кичен...
Тау-тау дулкын булганда да,
давылда, салкында,
Ул – диңгез иркендә, һаман
сөйгәне янына
Ул шул бугаз аша йөзә.
Аннан үз ярына...
Ул ярларны ялгый көн дә,
тоташтыра гүя:
Азиядән Европага
илче булып йөзә.
Гүя күпер ул диңгездә –
ялгасын мәхәббәт! –
Сөю хакына диңгезне
кичә – ничә кабат!
Шаһит булгансың, Геллеспонт,
бөек мәхәббәткә!
Ничек бирдең аны ләкин
беркөн һәлакәткә!
Ачуландың ник, Посейдон,
син, диңгез алласы?
...Сөйгәненә йөзә чын ир –
көч һәм хис баласы.
Ярда ут күренми беркөн...
Дошманмы сүндергән?
Йөзгән Леандр ул төндә,
соң чиккәчә йөзгән...
Кайда Геро? Яр күренми...
Давыл тик диңгездә...
Баткан Леандр...
Ә җаны – һаман исән,
йөзә.

Легендалар исән һаман,
белә йөзүчеләр,
Батырлыкта Леандрны
үрнәк күрүчеләр.
Көнчыгыштан Көнбатышка,
илләрдән илләргә
Илчеме син? Хәбәрчеме?
Тиешсең йөзәргә.
Кабатлаган күпләр шулай
Леандрның юлын,
Бер кыйтгадан икенчегә
тере күпер булып.
Ә дөньядан үткән күпме
яулар, яулар... утлар.
Күп Леандрларны көткән
яңа Геллеспонтлар, –

Куркынычлар... Сынау аша
йөзгән, һәлак булган
Күпләр шулай: батыр булган,
әмма харап булган.
Байрон – йөзүче бөек ир,
ул да баскан ярга –
Геллеспонтны йөзеп узгач*,
охшап Леандрга.
Элладага гашыйк җанын
суыткан дулкында,
Азатлык факелын тотып,
килгән Элладага.
Һәлак булган ул шул юлда...
Мәңгелек дан аңа!

Кыйтгаларны кыен хәтта
уйда гына ялгау...
Әй, Геллеспонт, синең исемең
әйди һаман алга.
Йөзүчегә һәрчак кыен,
төн кара, айсыз күк,
Ярда ут яккан дус булса,
сүндерүче дә күп.
Арада – гел караңгылык,
арада – төн, томан...
Ничә гасыр, әй, Геллеспонт,
синдә шулай булган?
Азиядән Европага,
Европадан тагын
Азиягә меңнәрнең син
ирек сөйгән җанын
Юнәлткәнсең... Хәзер инде
ул чор ерак, узган –
Тоташтырып кыйтгаларны,
илләр күпер сузган.
Дарданелл дип аталгансың
син, Геллеспонт, үзең.
Тик шагыйрьләр өчен яши борынгы
чын исемең!
...Әй, тәбриклим, бүгенге яшь
Леандрлар, сезне!
Кыйтгаларны тигез сөйгән
чын шагыйрьләр, сезне!
Ялгагыз сез йөрәкләрне
нык бердәмлек өчен.
Телләр, фикерләр үз итсен
тизрәк бер-берсен.
Йөзүчеләр әнә күпме –
кара син диңгезгә!
Нинди максат белән алар,
кая бүген йөзә?
Нинди көрәш, идеаллар
чакыра соң аларны?
Бармы, яшиме аларда
Байроннарның җаны?

*

Әй күрәсе иде шундый

батыр егетләрне!
Якташларым, әллә алар
безнең кебекләрме?
Бездә – җырда, монда – диңгез
каян килә димсез?
Диңгез яраткан дусларым,
бәлки, сез әйтерсез?
Бәлки, шушы минутларда
Мәрмәр диңгездәнме
Йә Босфордан узасыздыр,
илем егетләре!
Максатлар – зур... Бар кыюлар,
йөзүчеләр бездә.
Кемнедер мин көтәм бүген
күз алмый диңгездән.
Ә кайда минем Геллеспонт!
Ярым яккан учак?
Минус җиделе күзлегем
зәңгәрлекне коча.
Йөзәргәме? Кычкырырга:
– Таласса, Таласса!
(Диңгез дигән сүз икән ул
борынгы грекча.)
– Кочагыңа ал мине! – дип
әйтимме татарча?
Юк, йөзәргә тиеш мин дә,
соң түгелдер, түгел...
Юккамыни, улым, монда
тартты безне күңел.
Әй, йөзәргә кирәк ерак,
йөзәргә диңгездә,
Ярдан еракта... Армаска!
Хыял күптән йөзә,
Гизә, дәрьяларны урый...
Җанымда хыял – ут.
Китмә миннән, романтика!
Көт мине, Геллеспонт!

# *III. Гомер уртасыннан хатлар*

***(1981–1986)***

### ЯШЬЛЕГЕМӘ ХАТ

Мин күрергә телим сине –
мине аңламаганнарның беренчесен! –
Аңламаганын да яшермичә,
алдамаганнарның беренчесен!

Ә ни өчен?
Җанда яра булып калгансыңмы?
Сызлап,
һаман сагындырасыңмы?
Күңел моңнарымны тик син
сабый йокысыннан уяталгангамы?
Әллә
үзең шул моңнарда калгангамы?

Минем ялгышларны,
кыен язмышымны
әллә каян,
алдан күрә алгангамы?
Шуңа, качып,
юл башында калгангамы?

Мин күрергә телим –
мине,
ахры, аңлый алганнарның
беренчесен:
тыныч бәхетеңә кагылмыйча,
сиңа рәхмәт әйтеп бары,
кире китү өчен! –
Мин күрергә телим сине...

## БӘХЕТ ТУРЫНДА ХАТ

Ахры, кызыгасың булыр:
«Янып үтә һәрбер көнең,
нинди бәхетле син!» – дисең,
дустым минем.
Әй, ул бәхетем –
пәрдә япкан тәрәзәле
серле күңел йортым минем!
Беләсеңме, шул бәхетне –
җанны баскан уйлар,
мәшәкатьләр йөген,
бәгырь өзеп туган җырның үзен –
кызыгам кайчак! –
кемгәдер мин бирер идем.
Иңенә салыр идем берәрсенең, –
качар идем,
әкияттәге кебек:
«Хәзер алма алып киләм, көт», –
дип китеп:
әй, торса иде
тирләп, арып, сабыры бетеп.
Мөмкин түгел бу эш!
Өлешемә тигән көмеш –
Ул –
Мономах бүрке кебек булсын –
зарланмый мин күтәрергә тиеш!
Бары да монда: шатлык, газап,
көлү, яшем –
белми тудым, инде барысын күреп яшим.

Әмма кайчак уйлап куям:
бәхетемне мин
көнләүчегә тик беразга,
күтәреп карарга гына
бирер идем.
Ә югыйсә гомер әлегә матур уза:
мин язмыштан, бәхетемнән –
үз җиремә үзем үк утырткан,
әйе, исән чакта үзем куйган
көмеш баганамнан риза...

## МАРС АВЫЛЫ МАЛАЙЛАРЫНА

Сагынам сезне, Марс малайлары,
яшьтәшләрем, димен,
үстек тә без таралдыкмы төрле
тарафына илнең?
Авыл – сабыр, каргамый ул
үзен
ташлап киткәннәрне.
Тик каены төштә – кара, моңсу...
үпкәләгәнгәме?
Ә имәннәр?
Безнең «ахирәтләр»
алар исәннәрме?
Шаулап үсәләрме?

Балачакның авыр истәлеге:
давыл узган төштә,
яу ирләре кебек, нык имәннәр
егылганы истә...
Гаҗәпләндек: шул урында азак
яшь имәннәр үсте!
Орлыктанмы алар? Үсентеләр
тамырданмы китте?!
Яңа урман үсте!
Яшь имәннәрне мин искә алам
сагынганда сезне;
әтиләргә алмашка без үстек! –
Тамыр – җирдән безнең!
Күптән ирләр булдык... «Ахирәт»ләр –
имәннәр дә – ирдәй!
Яңа буын – җиргә!
Урман – ныклы терәк, ышык безгә,
ә без терәк – илгә!
Шушы чагыштыру (яңа димим!)
егерме ел уйда минем:
күңелемә килә...
Ул, үзенә бер поэма сорап,
шакый күңелемә...
Ни язсам да, тәнкыйтьче дус, аңла:
каләмемә тимә!
Яшь имәннәр тамыр җибәргәндәй,
җырлар туа килә...
Алар үсәр... Каты салкында тик
нык имән дә үлә!
Имән кебек нык дусларым минем!
Инде арада юк яшьтәшләр бар...
Ә яшәрбез димен!
Төрле тарафларда үтибез без
вазифасын илнең!
Нинди уйлар, нинди гамьнәр сездә?
Йә, сөйлә әле, Рәис, сөйлә, Илфир?
Сез соң, Илмар, Вилмир?!
(Сагынуым, бу исемнәргә син
үзең шигърилек бир!)
Хыялларны, куркып кына, яшьтән
сезгә ача идем...
Сез һәрвакыт хупладыгыз мине,
яшьтәшләрем минем!
Беркөн, кайтып Марс урамына,

җырлап йөрсәк имәннәр янында
чал чәчле биш егет –
яшьтәшләрем,
акларсызмы мине?
Аңларсызмы бу хат-шигыремне?
Тик сезгә баш иеп,
бары сезнең сүзгә,
хак тәнкыйтькә
ышанырмын кебек!

Сагынам сезне, Марс малайлары...

## ОСТАЗГА ГИМН-ХАТ

«Минем остаз» дию ул – аз!
Һәммәбезгә остаз ла син,
Җитмеш яшьлек япь-яшь хәким,
Уйчан хәким, сабыр хәким!
Хөкемеңә риза синең
минем буын... Нинди хөкем
чыгарырсың? Бүгенгедә –
шигърияттә, йә, әйт, без кем?

Аксакалга инануны –
мин кычкырып әйтәм аны!
Синнән узып безнең җанны
кем тыңлар соң? Кемгә дәшим?!

Тукайлардан – ил җаныннан
мирас сиңа сабыр, рәхим-
шәфкатьлелек, таләпчәнлек
(усаллык дип ничек әйтим?!),
олылык, чын әдәплелек,
кешеләргә мәхәббәт, моң!

Нәвоидан соң нәкъ биш йөз,
Лермонтовтан йөз елга соң
һәм кырык ел Такташтан соң
туган буын синең алда,
остаз, йә, әйт?! Ни кушасың?
Арабызда иң өлкән – син,
үги итмә... Туфаннан соң! –
Ешрак бир киңәшләрең,
утлы тәнкыйть сүзләр әйт син:
кырыкта да шагыйрь – бала,
кырыкта да була ятим, –
бул син безгә сабыр эти...
Синең белән замандаш без,
хәтта әле... «каләмдәш» дим.
Безнең чордаш булуыңа
язмышыма мең-мең рәхмәт!
Рәхмәт дими нәрсә әйтим?!

## АТЛАР ТУРЫНДА УЙЛАНУ-ХАТ

Яшьтәшләрем!
Кайда икән безнең
балачакта менгән очкын-атлар?
Болыннардан эзлим, кайтсам,

күренмиләр.
Кайда алар?
Адреслары бармы,
язсам хатлар?
Әй, кайда сез, Сандугачлар,
Буян,
Красавецлар?!
Кай тарафта аерылдык без
сездән, атлар?
Котылгысыз: сез китәсез,
юк, бетәсез... Кемнәр яклар?
Безнең буынгамы кала
«Гамьсез» дигән яманатлар?
Ә бит бездә исән –
яши атка мәхәббәтләр!
Улларыбыз менә нишләр? –
Атсыз нинди ир булыр соң,
нинди батыр булыр Салаватлар?
Ир канаты булган тугры юлдаш –
атлар! –
Шигърияткә дә бит
алып килде безне шул «канатлар»...
Әкияткә әллә күчеп бетәрсезме?
Без канатсыз
гомер итәрбезме?
«Соңгы мамонт» урынына –
бәлки, хәзер «соңгы ат»лар?!

Сезне алып киткән көчләр
суймасмы соң Пегасны да?!
Аны
роботлардан кемнәр яклар?
Шигырьдә дә сирәк хәзер
атлар –
әйе, азлар...
Корыч атлар анда –
«МАЗ», «КамАЗ»лар...
Кичер мине, балачакның тугры аты,
ир канаты,
тагын бер кат!
Бүген
тагын мин хат язсам –
сиңа түгел инде ансы:
– КамАЗга хат!

## ИГЕНЧЕЛӘР ИЛЕНӘ ХАТ

Кичерегез мине,
яшьлегемдә калган яшьтәшләрем! –
Мәктәп белән саубуллашкан көнне,
елап, миңа
олы юл теләгән классташларым!
Сез күрергә теләгәнчә,
яңа Такташ – бунтарь Гаташ була алмадым.
Кичерегез,
юл башында озатып калган
якты күзле кызлар –
сүнмәс йолдызларым!
Ахры,
ул чактагы садәлекне

бүгенгәчә сакламадым.
Гафу итегез,
миңа зур өметләр
баглаганнар!
Ышанычның күбесен,
беләм, акламадым.
Мин – җырымда Мәҗнүн тарафдары –
тулы көчкә мәхәббәтне,
бәлки, якламадым?!
Дөньяны да, башта вәгъдә
биргәнемчә,
тәмам камил,
матур итә алмамдыр...
Кичерегез, авылымдагы
аксакаллар! –
үз авылымда «пәйгамбәр» мин
булалмадым,
сез уйлаган «зур бер кеше»
булып та тиз кайталмамын.
Бөек гаебем сезнең алда,
якташларым:
мин әлегә авылым – Марс данын
Кырлай, Сыркыдылар,
Кармәт, Күлле Кимеләр,
Келәш, Минештеләр
биеклегенә илтә алмадым!
Ләкин ышаныгыз, яшьтәшләрем! –
Марс – сугыш алласына
баш июче булмадым мин,
Кешелеккә каршы коралга
дан җырламадым!
Зевсның һәр әмеренә
буйсынып, юк,
намус мин җуймадым.
Яңа Геростратларга
кушылмадым –
мин һәлакәт теләмәдем
җиремә.
Прометейга табындым
мин һәрчак!
Кешелексез фикер
юк шигыремдә!
Әнкәй чәчкән,
ил фатихасы белән үскән
яхшылык булды
күңелемдә!
Кояш исе, тир, тоз тәме
җырда-икмәгемдә!
Әле язылмаган иң шәп җырым –
ул, авылдашларым, сезгә!
Әле әйтелмәгән матур мәдхияләр,
якташларым, сезгә!
Сезгә, игенчеләр,
аңлашылсын бар иҗатым...
Игенчеләр иленә –
Ватаныма булсын
Соңгы шигырем минем –
соңгы хатым!

**ЭПИЛОГ-ХАТ**

Ишетәсезме безне,
әй, лириклар!
Бездән элгәреләр – ерак тарихлардан
бүгенгегә дәшкән йөрәкләр –
бөекләр!
Бездә бүген – сезнең мирасыгыз,
гасырлардан килгән хатлар,
ялкыннардан чыккан утлы китаплар,
«пәйгамбәр сүзедәй» хак хитаплар –
үлемнәрдән көчле
«аять»ләр!
Беләбез, сез –
тиңсез ораторлар,
Такташ кебекләр...
Ишетелде безгә сезнең сүзләр!
Яд ителә җанда сезнең хатлар,
сезнең мөрәҗәгатьләр, –
Түгел анонимнар,
донос, шикаятьләр! –
сездән килде бөек әманәтләр!
Безгә ирешге
сезнең антлар,
мәхәббәтләр!
Сүзләрегез – тарих кайтавазы,
алар – бездә!
«Син кайтавазыңда яшисең!» –
бездә сез яшисез кабатланып,
дәвамыгыз – бүгенгедә!
Сезне дәвам иткән минем хатлар
сезгә булсын безнең буыннан
җавап,
киләчәккә – яңа мөрәҗәгатьләр!
Үз чорыбыз – үз җырыбыз,
сөйләсеннәр алар:
кырык елга якын тынычта без,
шундый бәхет бирде илебез! –
Килер буыннарга
илтсен алар безнең горурлыкны –
тәҗрибәләр сүзен
илтсен хатлар!
Барсын хатларымда
яуда үлгәннәрдән ядкарь,
исәннәргә бездән хөрмәт һәм дан,
рәхмәтләр!
Омтылышлар,
безнең мәхәббәтләр.
Егерменче гасыр ахырыннан
яңа йөзгә
Җирнең имин баруына
ышаныч, антлар!
Алар –
бары безнең заман яза алган
хатлар!
Шул ук адрес:
йөрәкләргә йөрәк сүзе барсын,
юлда югалмасын!
Дошман угы алмасын!
Хәере белән,
өмет тулы җырлар, –
төш җиткәндә

аяз күккә без очырган кошлар!
Ышанам:
кешеләргә кирәк сүзегез бар,
ак юл сезгә,
гомер уртасыннан хатлар!

## АВЫЛ СӘХИФӘЛӘРЕ

### Әнкәй белән мәңгелек сөйләшү

Юл башында –
гомер чишмәсендә юган шигырем!
Син түгелме эндәшүче:
– Әнкәй, җибәр мине сәяхәткә!
Дөнья күрим...
Унсигездә идем...
Егерме биш ел узды менә – һаман йөрим...
– Әнкәй, кайтар мине яшь чагыма,
            беразга гына?!
Гаҗәпмени, шулай дәшсә
        хәзер җырым минем?
Илләр буйлап йөрим,
дөнья гизә улың синең.
Күпме җирләр күрдем, – рәнҗемә, әнкәй,
әткәй каберен таба алмадым мин.
Ләкин
билгесез һәр солдат каберенә
чәчәк куеп уздым, башым идем...
Дөнья күрдем...
Байлык, хәзинәләр эзләмәдем.
Сиңа бүләккә дә, хәтереңдәдер,
яфрак-яфрак китаплар җибәрдем. –
Хыял яфракларын! – Сөенден син,
чәчәкләрен инде күралмассың...
Төшкә керде бик еш туган йортым,
Төштә никтер һаман боек,
             тузган йортым...
Сипләттек лә юкса аны...
Әллә нигез хәтерен калдырдыммы?
Балачакта үртәдем еш әбине мин –
                 нәнәемне,
куркам хәзер, каргадымы?
Илләр күреп йөрдем.
Гомер күпме читтә узган,
әллә туган җир җылысы онытылган –
җан да, бәлки, катыланган?!
Таш булмасын – кайтар мине, әнкәй,
            ул балавыз чакка,
                 туган якка...
Капкабыздан ашыгып килеп керим.
Дөньяга мин шуннан
          чыгып йөгердем.
Шуннан бирле артты, әнкәй,
          синең йөздә бuразналар –
бәлки, мин чәчмәгән, мин икмәгән еллар өчен
                 әрнү булган алар?!
Илләр күреп йөрдем...
Әнкәй, хәзер син юк...
Әмма чакыр мине,

Һаман чакыр Моңга,
һаман кайта алыйм авылыма:
гомерем төшлегеннән,
хәтта ахырыннан – кайта белим...
Кайтып буламы икән узганнарга?!
Инде синсез йортка, туган якка?! –
Сынап, күрим...
Чакыр мине төшләремдә,
уят гамьсез көннәремдә,
нигез уен, бәхиллеген белим.
– Әнкәй, мәңге чакыр мине авылыма:
туфрагымнан аерылмаса идем, –
мәңге сине ишетә алса идем!
Әнкәй, чакыр мине...
Кайтар һаман асылыма!

## МОҢДАШЛАРЫМ, ЧОРДАШЛАРЫМ

Әй, Арча... Балтач, син,
сез, Сарман, Зәй, Мөслим,
Актаныш, Мамадыш,
Буа, Апаслар, дим, –
Данырыз кемнән ким?!

Булыгыз тик имин,
ә халкымнан минем
чыгар алар, чыгар
яңа Мәрҗаниләр,
яңа Урманчелар,
Такташ йә Туфаннар,
Хәкимнәр, Илһамнар...

Алар бар, булырлар:
буразнадан шытып
калыккан йолдыздай,
ил бәгыреннән туар
моңлылар, ул-кызлар.
Дәвам килер сиңа,
халкым, сәнгатеңә:
азмы Апуш әнә
Кырлай тирәсендә, –
яңа Тукай үссә?!
Әле мәктәбеңдә
укымастыр димә
Курсавилар – гүя
Әбугалисина!
Казан арты иркен...
Ә соң Урал ягы?!
Агыйдел буйлары?!
Дим дә бит – шул Дим –
бәрәкәтле зәмин! –
Халык җаны – ул киң!
Себер, Оренбурлар,
бай, икмәкле җирләр
җыр да үстерер дим.
Алар да бит имин,
их, җырыма минем
әле иркен, илем!

Зур уй белән яныйк,
моңнарны югалтмыйк,
олы гамьне саклыйк –
Тел кальгасын ватмыйк!
Рух тарихын сатмыйк!

Җырга, дусларым, дим,
күпме эшләр безнең! –
Көрәш урыны – җирем...
Ә без соң кемнән ким?!
Кимме горур халкым?
Янсак иде ләкин,
сүрелмәсәк иде, –
туып бәгырьләрдә,
авылларда, җирдә –
ерак чорлар кичкән
моңны, җырны һаман
биек йөртсәк иде,
чордашларым минем,
моңдашларым минем!

## ҖАВАП

Синең ялгашыңа юк тиясем,
«Чәбә!» – дигәнем юк, ник өрәсең?

*Дәрдемәнд*

Мөтәһади ул шәп... Шәп, уйласаң,
«Талантлы укучы-малай» да...

Оят җуеп, шөһрәт яулар өчен
Керми Иблис белән ул пайга.

Ул хыянәт итми мәхәббәткә,
Ул баш ими – файда эзләп! – потка:
Алмаштырмый чынны ялганга!

Алыш-биреше юк мәкер белән,
Әшнә түгел һәр ялагайга.

«Көрәшче мин» диеп, делецлыкны
Тәкъдим итми ул ил-базарга.

Макиавелли тәгълиматын белми,
Карьеризм чит, ят аңарга!

Тартмый аны кемдер иман сатып
Алган дан да – шикле «калай» да...

Алай да –
Мин баш иям шигърияттә шундый
Үзе булып калган малайга!

## МАҢКОРТЛАР

Сөйләшәләр икәү:
– Кемгә хаҗәт
Җыры-моңы ата-бабаның?
– Галәмнәрдә сәфәр кылган чорда
Кирәге бар кемгә аларның?

– Борынгы таш, иске китапларга
Багынучы үзе юләрдер!
– Безнең «диско» чорларында аны
Юләр генә бары өйрәнер!
– Языласы сүзләр язылганнар...
Әйтеләсе сүзләр әйтелгән.
– Барысы да ачык! Һәр датаны
Мәктәпләрдә инде үтелгән...
– Һәммәсендә инде аңлыйбыз без,
Аңламаган нәрсә бик сирәк.
– Баш ватмастай уйлар кирәк безгә,
Уйламастай уйлар бик кирәк!

...Сөйләшәләр икәү,
Сөйләшәләр,
Алар өчен, бәлки, кызарып,
Гүя аксакал бер, Бөек Ата –
Кояш чыга... Бата...
Шул маңкортлар өчен... оялып!

## «ҖӘЙ БӘХЕТЕ» БӘЙЛӘМЕННӘН

### Сагынганда. Алтын яфрак

Хатыңа салып җибәргән
Казан яфрагы исән.
Сагынган дип аңла, аны
Күрешергә сузган кулдай
Сак кына алдым, дисәм,
Сагынганда хисләр дә бит
Яктырак, сафрак кебек...
Моң да бер яфрак, гүяки –
Көз кочагында тибрәлгән
Алтын бер яфрак кебек...
Ә кичен синең яфракны
Мин баш астыма куям.
Төшлеге матур: гел яшел
Туган җир рухын тоям.
Аңларсың, Казанга кайтып,
Синең кулларга сак кына
Кагылдым бүген, дисәм:
Соңгы хатыңдагы саф моң
Һәм яфрак – миндә, исән!

### Статуэткага

Әй, уйга талган матурлык,
Тын омтылыш һәйкәле!
Син соң бер хыял кызымы,
Сусылумы? Әйт әле?
Нинди ярсу уйлар синдә,
Нинди уттан тетрәнеп
Ай, йолдызларга җан ачты
Синең калку күкрәгең?
Нинди сер синең күзләрдә?
Без белмәгән чит гамьме?
Сыйганмы аңа диңгезләр,
Җир рухы? Йә галәмме? –
Әллә син яшьлек сынымы?

Мәхәббәтнең пакь төсе?!
Горурлыкның бер китабы
Йә тугрылык сакчысы? –
Әй, мәңгелек хыял кызы,
Сусылуы һәйкәле! –
Син – Кыз язы, моң, хәтере,
Син – назның бөре күк сере,
Син – бәхетме, әйт әле?!

* * *

Ак сафари...
Онытмадыңмы тик
Актан киенеп мине көткәнең?!
Ак күлмәгең, йөгереп мин керүгә,
Дулкынланып, тетрәп китә иде...
Таң-сәхәрдә бәхет эзләп киттем,
Алып китте хыял-җилкәнме? –
Дәрьяларга салды... бүлмәң калды,
Калды ак сафари – үткәнем...
Еллар узган саен, уй-дулкында
Нәни көймә, гүя хәтергә
Сугыла шул бүлмәң:
Кемнәр анда?
Ак хыялмы тетри хәзер дә?!
Ә без тормыш дигән җай агымга
Алмаштырдык язгы хисләрне, –
Аерылганда, истә, ак сафари
Элеккечә тетрәп китмәде –
Тыныч идең...
Каралтмадыңмы соң
Еллар белән син ак җилкәнне?!
Әллә төсе аның бүтәнме?
Искә аласыңмы
Ак сафари –
Ак күлмәктән мине көткәнне?!

* * *

– Ахры, бераз «сәеррәк» мин... – дидең,
– Пар икәнбез... Мин дә шундый зат:
«Җиңелрәк» мин... азрак... –
Шаярдык та
Якынайдык чынлап без азак:
Әверелдең минем аңлаучыма,
Нәни, көчле таянычыма...
(Үзем кем булалдым икән сиңа? –
Ни биралдым синең җаныңа?!)
Үпкә-шиксез, таләп-шартсыз,
Мине
Якын иттең, шулай тиеш күк,
Сүздән өстен булып, батыр булып...
Барлыгымны аңлап, килешеп;
Бәхет йолдызымны күп вакытта
Каргадым мин – ә син ышандың;
Булды ихтыярым йомшарганы,
Синең ышанычтан көч алдым.
Ә шулай да

Кем булдым мин сиңа?
Хыялыңа сынау бер, газап?!
Шаярмыйча, чынлап әйтә калсаң,
Исеңә син килеп бер, азак:
– Сәер идем... Синең хыял белән
Җиңелрәк тә бугай мин азрак...
Юатырмын: – Һаман пар без, димәк:
Җиңел генә түгел, сәер – мин дә...
Без мәңгегә, бәлки, охшаш зат?!

**Язмыш-каләм**

Әллә саба җиле,
Әллә сәлам иде –
Синнән килде иртән;
Боекмаска кушкан,
Онытмаска кушкан
Сүзең килеп җиткән!

Илһам теләүче хат,
Азрак көнләүче хат,
Ялкын тулы мәгәр,
Гади генә сүзләр,
Әмма синең хисләр –
Күңелеңнән хәбәр!

Җырда кылларымның
Ерак яңгыравын
Күптән көтәсең, яр!
– Язмыш каләмнәре, –
Дисең, – безгә дә әле
Тиңсез бәхет язар!

Сагынудан безнең
Уртак бәхетебезнең
Моңы шундый яңгырар! –
Язмыш-каләм үзе
Безгә язар сүзен
Шул моңнарда табар...

И, яр, теләктә кал!

* * *

Юк, чакырма мине үзеңә, әй, Актаныш!
Якты кырлар, синең урман, гөлләр –
миңа таныш...
Һәр карыш җир – бәхет,
шатлык, сагыш катыш –
таныш!

Тик табалмам синдә бер чәчәкне –
бер дусымны...
Киткән чакта әйткән иде: – Йә, хуш!
Колагымда һаман назлы тавыш.
Туфрагы да, бәлки, суынмаган...
Гөлләр чакырмасын, әйт, Актаныш!

Килә алмам әле сиңа мин тиз генә:
Авыр уйлар кабат кайтыр кебек...
Үткәннәрем кире калкыр кебек!
Тирәнрәк яшерәсе иде кыен моңны!

Күмсә иде аны вакыт, еллар комы...

Юк, чакырма мине, әй, Актаныш!
Кешеләрең юкса якын, таныш.
Син нур белән өретеп ачкан күзләр,
– Бездә Кояш, шатлыклар, кил, –
дигән сүзләр –
барсы таныш.

Ләкин килсәм,
Агыйделдән ишетелер тавыш:
– Бер генә кат чәчәк ата күңел,
Ике кабат бәхет көтүең, бел, ялгыш!

Их, Актаныш!..

**Якында**

Без булганбыз шундый якын ла:
Бер поездда, төрле вагонда!.. –
Бер тарафка киткән юлыбыз,
Бер сагышны йоткан моңыбыз.

Төн йокламый уйда килгәнбез,
Уяу килештер – төш күргәнбез.
...Булгансың син күрше вагонда,
Тик перронга чыккан чагымда,
Вокзалда син күземә чагылдың.
Каршылаучыңны да таныдым.
Төш бүленде минем – уяндым,
Күздән җуйгач сине, уйландым...

Гомер юлыбыз да – бер тараф! –
Барабызмы читкә без карап?
Бер-беребезне уйлап яшәп тә
Очрашмыйбыз, үзебез – янәшә:
Бер поездда... Төрле вагонда!
Бергә түгел, әмма – якында...

**Гәрәбә турында синең җыр**

Казаннарда табылыр микән
Чын гәрәбә тезүче?
Булмас инде синең кебек
Үзәгемне өзүче...

*Халык җыры*

– Матур, – диләр, – бик килешә
Чын гәрәбә муенсаң... –
Мин гәрәбә муенсамны
Тагам, сине юксынсам...
Гаҗәпләнмә, хыялыңда
Әгәр моңсу тоелсам:
Гәрәбә – сагыш, диңгездә
Наратларның мең еллардан
Безгә кайткан күз яше...
Минем дә яшемне кемдер
Беркөн шулай тезмәсме? –

Казаннарда әллә синсез
Җанны һичкем өзмәсме?!

Синең өчен күз яшьләрем, –
Алар бит чын гәрәбә;
Уртак шатлык, моң, сагышлар,
Үпкә, үкенечләр – барсы,
Юк, китмәстер әрәмгә, –
Әгәр, җыелып, беркөнне
Күз яше булып тамса?..
Без ул яшьне танырбыз бит
Гәрәбә була калса?!
Гаҗәпме: синең уйларың,
Минем матур бу муенсам
Саф яшьләрдән җыелса?!

Матур, диләр, килешә, диләр...
Бик сагынган дип уйларсың,
Җырым моңсу тоелса!

* * *

Хатларың күптән имзасыз:
Ахырда – «Сагынып, Мин...»
Болай да онытылмас димсең
Кадерле синең исем?!

Ә мин белми торсам: кем син?
Убылып гүя хәтер,
Кемнән хат?
Шул хакта озак
Уйланып йөрсәм хәзер?!

«Хәтерләтә кемнедер бик,
Язуы шундый таныш»...
Һәм азак юрап кемгәдер
Мин җавап язсам ялгыш?!

Аңардан ләкин хат килмәс!
Очрашкач үзе белән,
Яшерен ым, мәгънәләр көтсәм?!
Ул узса сүзсез генә?!

Хатыңны укыйм һаман да,
Язгансың: «Сагынып, Мин...»
Исемдә исемең! Көнозын
Кабатлыйм кабынып мин.
(Ә, бәлки, табынып дим.)

...Бу җыр-җавап кемгә?! –
Тик син
Аңларсың...
Сагынып,
        Мин.

**Тагын... болан баласы**

Йөрәге яна микәнни?
Шунда әллә дәвасы? –
Кар ярып аккан елгадан,
Сузылып, су эчә урманда, –

Күрдем болан баласын!

Салкын тимәсә иде бит
Сиңа, урман баласы...
Сеңлем, билгелеме юлың?
Таулар аша барасы –
Тирләп кая чабасың?!

Минем дә, болан балакай,
Әрни җанаш ярасы.
Җанда – кар суы да басмый,–
Кайда аның дәвасы ла,
Ничек кенә табасы?!

Язгы суларга текәлеп,
Тагын күпме барасы?!
...Бәлки, ярын эзләп арган? –
Муенын сузып су эчкәндә
Күрдем болан баласын...

## Яшәү җыры

Бөтен гәүдәң рәхәтлеккә талган –
Оеп калган...
Чәчләр таралган.
Тузгып, тетрәнүле күкрәкләргә –
Алар хәлсез, читкә караган.
Оялгандай...
Каян яралган
Бу халәтең? Ләззәт булып синнән
Дулкынмы узган? – Әллә нур яуган:
Авырайткан бөтен вөҗүдеңне –
Бәхет мизгелеңнән ни калган?!

Бу хәлеңдә син тәхеттә кебек,
Куллар әнә төшеп салынган...
Аякларың көчсез: хәрәкәтсез...
Тик елмаю йөздә язылган.

Җиңелү, юк, татлы җиңү төсе!
Сүзләр кая китеп югалган.
Наз кичерешендә? – ...Күзләр исә
Ярым йомык... Рухың юл алган
Гүя күккә!
Теләкләрдән азат
Тәнең, арган...
әллә армаган?!
...Хавабыздан мирас халәт, бәлки,
Мәгълүм Данаядай – сурәт, бәлки? –
Алтын яңгырдан соң хәл алган...
Хава-әнкә! Чынлап та син Адәм
Кабыргасыннанмы яралган?! –
Без бит – синнән... Синнән – матурлыктан
Яратылган! Яшәү, җан алган!
Син һәр гүзәл женес – оныгында
Кабатланасыңдыр яңадан?!

Бөек мизгел! Әлмисактан күпме
Җаннар синнән бәхет табалган.

Син һаман шул: гади һәм илаһи! –

Яшәү җыры... Ә кем язалган
Сиңа – мәхәббәткә лаек сүзләр?
Мин дә – гаҗиз...
Мин дә – табалмам.

## МӘРХӘМӘТ

Ник дәшәм бүген дөньяга?
– Мәрхәмәт, дим, мәрхәмәт:
Тагын хәкарәттә анда
Төнге Мадрид урамында
Түбән төшкән мәхәббәт, –
Тапталмасын ялгыш, әкрен!
Юкса ул янмас кабат...
Диварга сыенган – туңган,
«Эштән чыгарылган кыздай»
Тузган чәчле Мәхәббәт,
(Тукталдык Фәйзуллин белән...)
Мәрхәмәт, әй, мәрхәмәт!

Парижда күреп янды җан,
Аннан Лондонда – Сохода,
Инде менә Мадридта –
Суык апрель төнендә ул,
Ярым ялангач фәрештә
Җиргә төшкән – яр көтә,
Ул чакыра мәгълүм йортка!

Хәкарәттә мәхәббәт...
Мин, аның рыцарь-шагыйре,
Бу хәлендә күреп әле
Нишли алам?! Мең кабат,
Дон Кихотча... юк, Тукайча
Кычкырам бары дөньяга...
– Кит моннан, булма харап,
Кайт, сөю, изге исемеңә...
Беләм, егерменче йөздә
Кемнәр сине, Мәхәббәт,
Бу хәлгә төшерә... Җиркүләм
Нәфрәт аларга, нәләт!
...Җылын шагыйрьләр җанында,
Тузган чәчле, туңган ач зат!
Мәхәббәткә – Мәрхәмәт!

* * *

Шагыйрьләргә тик илһамчымы син,
Татар кызы?! Күпме ярасын
Бәйләдең бит илнең! Әле озак
Безгә бергә-бергә барасы,
Сине, ак калфаклы Алиһәбез,
Сынауларның көтә яңасы...

Борынгының Афродитасымы? –
Син Тукайның, бәлки, Зәйтүнәсе –
Әрнүләрнең горур Музасы.
Тарих аша синең йөрәктә ул
Килә назның сабыр туташы –
Язмышларның тугры юлдашы!

Күпме шагыйрьне син алып килдең
Татар Парнасының тәхетенә.
«Зәүкың» өчен түгел, хисең һаман
Тоташ ил җанына, бәхетенә:
Безнең тулпарда син таккан чуклар
Бәйгеләрдә барган чагында.
Гамь дибез еш – җәрәхәтле хәтер
Гасырлардан кайтып чагыла,
Ул синең дә тере – җаныңда...

Татар кызы, Муза, Алиһәбез,
Әле озак бергә барасы,
Ахыргача бул син моң туташы,
Ахыргача ил, җыр ярасын
Син ябарсың наз-яулыгың белән...
Чор, җир тетри...
Безгә – барасы!

# *IV. Йокы юк шагыйрьгә*

***(1986–1990)***

## ЙОКЫ ЮК ШАГЫЙРЬГӘ

– Нишлиләр алар?..
– Татарны строй аша куалар.
Качкан өчен...

*Л.Н.Толстой. «Балдан соң»*

Китап. Мин... Мин. Китап...
Толстой. «Балдан соң»...
Төн, синме озын? Ник йокы качкан соң?!
Белмим мин, бүген таң атармы?
Бик сәер төш кебек – бер аваз:
– Татарны... татарны!

Уемнан кичәме үткәннәр ачысы?
Халкымның түккән яшь, гамь, моңы, сагышы?
Бетәргә боерган патшалар әмере?
Тел, дин, җан коллыгы –
Тарихның җәбере?
«Татарга һәм эткә рөхсәт юк!» –
Авыздан китмиме шул чорлар әреме?
Юк! Халкым ирекле, ул азат, Ватанлы,
Артта ул канлы юл, еракта ул калды!
Тату, дус гаилә без илдә – Татарстанлы!
...Тик җирдә, дөньяда,
Бүгенге заманда
Кемнәрдер кемнедер кыйныйлар һаман да.
Ак тәнле, сарымы, карамы –
Кемнәрдер бүген дә яралы,
Таяклар, чыбыклар сызгыра – кара әле!
Кыйныйлар негрны, индеец, ирландны...
Димәк ки, мине дә, димәк ки, татарны...
Дөньяның азмы әле царизмы, Цезаре?
Кыйный ул һаман да, кыйната,
Аркада чыбыркы уйната...
Юк, җанны ул кыйный, намусны яралый.
Пакь рухка, исемгә яга тап, яла ул!

Бүгенге «шпицрутен» – камил ул, яңа ул,
Строй үтәли кемнәрдер уза гел,
Сүз, гайбәт кыйный, күр, суга тел:
Яшереп кемнеңдер тарихын, үткәнен,
Үч ала кемнәрдер!
Таяклап үткәрә илне ил!

Кем кабат ташлар соң бер набат, кем бүген?
Дөньяга дәшәр кем?
(Кайда сез:
Каласны яклаган Вольтер, кил?!
«Эндәшми калалмыйм» диюче Толстой?!
«Гаеплим!» дип язган Золя, син?
Нәфрәтен әйталган зыялы – Чехов? Кем?
Эзлим мин.
Яклыймсыз хаклыкны?
Кем белән сез бүген?)

Халыклар – дөньяда бер, игез,
Тумыштан ирекле, дус, тигез –
Мин шуңа ышанам.
Шуңа мин йокысыз, Толстой, «Балдан соң»!
Абсолют чынлыкка җитмичә,
Дөньяда шундый чор килмичә,
Йокы юк шагыйрьгә, тынгы юк.
Җиңгәчме,
Фидельдәй, гамь төсе – сакалны без кырмыйк.
Таң аткач, көн килгәч?
Күз күрер аннан соң.

Хәзергә – Толстой. «Балдан соң»!

### ТУГАННАР

Әнкәй, син моңаеп әйтә идең:
– Туганнардан да бар туйганнар...
Туймас иделәр дә, алар шул, – дип, –
Әзрәк кенә... баеган булганнар.

Мин дә уйлыйм бүген: кемнәр алар
Туганын чит күргән туганнар?

Яңа Кабил белән Һабил әллә?
Гаиләдә? Илдә, җирдәме?
Нигә туйган? Баеганга булса,
Байлык әллә хокук бирәме
Туганыңны хәтта онытырга?!
Андыйларга тагын ни кирәк?
Ни бар юкса туганыңнан газиз,
Җирдә туганлыктан изгерәк?

Кем алданрак туган, әлифбасын
Кем укыган башлап, яшәүнең,
Җыр-дастаннар язган иң беренче,
Кем кабызган әүвәл фән шәмен,
Әдәбият нигезләрен салган? –
Кемнең күпме өлеше хакында
Бертуганнар – халыкларда әллә
Бәхәс бара?
        Ә бит барсында

Бүлешергә күпме байлыгы бар:
Матдиме ул, рухи, мәгънәви...
Туганнан, юк, туймас баеганга –
Уртак бар шатлыгы, бар гаме...

Әнкәй, ник моңаеп әйттең икән:
«Туганнар, – дип, – баеган булганнар»...
Баемаган, ярлыланган булыр,
Туганнарын җуйса туганнар –
Баемаган...

* * *

Бар ул мөтәдаһи!
Юккамыни
Зәүкы «сусап китсә» берәүләр:
– Әнә, – диләр, – тавышын ишетәбез,
Хәбәр бирә яңа пәйгамбәр,
Күренәчәк тиздән...
Әл-сәламе
Белән килә: горур, дәгъвалы...
Яңа Тукай, шиксез!
Көр тавышы
Ничек яңгырый!
Бөтен галәмне
Шаккатырыр тагын татар җыры...
Тукайдандыр мирас каләме...
Күреп калыйк!..
– Тукта! – дип кем әйтер
Тукай исеме белән уйнаган
Бәгъзеләргә?! – Тукай үзе булып
Килгән ләса? Кемдер булмаган...
Аның рухы белән тиңлик, дисәк,
Мохитенә аның куярга
Кирәкмиме яңа дәгъвачыны
Кыл күперләр белән сынарга?..
Рухта, бәлки, кабат туу кирәк,
Табу өчен дөрес кәгъбәне...
Булды алар – үзен Тукай итеп
Санаганнар – ялган вәгъдәле...
– Мин Тукайдан соңгы җыр рәсүле, –
Дип белдерде азмы килгәннәр –
Чордан «вәхи ала» белгәннәр...

...Ә булганмы пәйгамбәр, «Мин» дигән?
Ялганнары булган, йөргәннәр...

Пәйгамбәр дип алдап танытканны
Беләм, элек... Иблис дигәннәр...
Элек тә, ахры, таный белгәннәр!

* * *

«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!..»*
Рухым,
Кайтчы син дә тизрәк –
        чынлыкка –
            төп «тәңре»гә!
Кире кайткан кебек
Шау-шудан соң гамьле тынлыкка –
Бабайларның туфрагына кайт син:
Гөнаһ сарган тәнне,

тезләнеп,
Өр-яңадан яңарырга кайтар,
Ачылырга, соң кат үзгәреп...

Кайт чынлыкка!
Туфрагыннан башка
Кем соң уңган, булган канәгать?!
Зур бәхеттер – китсәң, кайта алу,
Кайтыр урының булу – сәгадәт...
Бөек шагыйрь васыятеннән чынлык,
Бәлки, шулдыр? – Туфрак – тәңресе
Яңарышка гүя чакыра җанны,
Ишеталсаң аның әмерен син:
Чакыра ул гомер чишмәсенә,
Артта – диңгез, давыл, сәясәт,
Болганган хис... Әмма алда – пакьлек.
Изге, таза, рухи сәяхәт!
...Соң булганчы, аңла хакыйкатьне,
Рухым!
«Тәңре»ң –
Олы гамьгә кайт!

## АК ҺӘМ КАРА. 1911 ЕЛ

Әллә нигә йөзе балкый – ахры,
Бер тантана кичерә уенда:
Күз карашы майлы... чыгып килә
Шыпырт кына серле урыннан
Һәм доносчы шундый да шат бүген,
Алан-йолан карый як-ягын...

Ә «Болгар»да Тукай шигырь яза,
Белми кемнең кайдан кайтканын:
Ул халкына өндәү-шигырь яза,
Алда күреп бәхетен, ак таңын...

* * *

Югары ул – Тукай биеклеге!..
Кайсы тауга исемен бирәсе? –
Таулар юк шул бездә.
Үрләр генә...

Ә рухта – тау биек...
Күрәмсең:
Илаһи тау анда!
Биеклеген
Үлчи, әйтә алган юк әле...
Кем колачлый, иңли алган аны?! –
Ул бит Тукай тавы – югары...

Күренерме безгә түбәтәе,
Башка таулар белән сөйләшсә?!
Тик нигезе җирдә,
Тиңнәренә
Биеклектән таулар эндәшә...
Безгә – кул җитмәслек!
Сүз кузгата

Кем аңа тиң булу турында?!

Тукай!
Ахыргача бөеклеген аңлау –
Бу да, бәлки, хыял-уй гына?!
Ә омтылсак һәм аңласак икән!
Акыл аек, йөрәк сау булып...

Таулар юк шул исемен бирү өчен,
Туган җирем тиңсез бай булып...
Чын горурлык рухта, бәлки:
Кала
Иң биеге –
Тукай-тау булып!

* * *

«Кара да гынай урман уртасында
Төлке уйный торган орлар бар...»
Әй, халкымның тиңсез күңел фонды,
Синдә күпме алтын җырлар бар!
Тыңлыйм да мин, елыйм: яшьләремдә
Бик ерактан килгән моңнар бар...

Мин дә, мин дә эзлим алтын җырлар,
Табармынмы?
            Сызган юллар бар.
Ләкин сизәм, һаман җыр алтыны
Табылмаган...
Бакыр сырлар бар
Маңгаемда,
          чәчтә көмешләр бар,
Өметләрем – сизгер кыллар бар...

Уйга калып йөрим чит җирләрдә.
Урманнар бар, алан, орлар бар.
Тынлык белән ялгыз калсам, тоям:
Туган җирдән агыла – моңнар бар, –
Алтын җырлар шулар белән килер,
Килсә миңа – беләм, юлда алар.

Ә хәзергә елыйм, оялмыйча:
Ил күңеленнән мирас җырлар бар!

* * *

Ничек уйланмыйсың?
Тере затың,
Кеше дигән атың булсын да –
Һәр күзәнәгең уй, ә ул уйда
Дөнья булып атом тулсын да?!

Тамырыңда һәр тибешең сорый:
– Яшәү асылын син таптыңмы?
Әйләнә Җир – һәм һәр әйләнеше
Үлчи, саный синең вакытыңны...

Уза гомер... Галәм белән тоташ
Һәрбер көне, хәтта мизгеле...
Ничек уйланмыйсың?

Шул киңлектән
Эзләрләрме синең эзеңне?

Нәтиҗәләр кирәк...
(Тәҗрибәләр
Чоры үткән...) Кайда ахыры?!
Лампада май кебек кими мәллә
Йә артамы кеше акылы?..

Акыл арта микән? Хәвеф арта,
Кыл өстендә бу Җир язмышы...
Ничек уйланмыйсың? Афәт килеп,
Харап итсәк аны ялгышып?..

Без Галәмдә – бөртек.
Ләкин нинди?
Гади тузанмы йә алтынмы?
Барыбер син алтын яшәү өчен
Җаваплы бит, Адәм акылы...
Уйный торган түгел, уйлый торган
Атом белән җаның тулсын да,
Уйланмассыңмыни?
Тере затың,
Кеше дигән атың булсын да!

* * *

«Үпкәнеңнән бирле...» – Тукай сүзе
Күңелемдә иде...

Сагынганда сине, әнкәй, хәзер
Мин дә шулай димме?!
Ә бит үбалмадым, соңгы юлга
Озатканда сине,
Тартындым мин – кырык яшьлек улың!
Инде кабатлыймын:
– Киткәнеңнән бирле...

Синең җаның күккә ашкан сәгать
Гомеремне дә кыл урталай бүлде,
Элеккечә була алмам хәзер:
Үзгәртте ул мине!
Элеккечә ярата алмам кебек
Кешеләрне:
Нидер ирек бирми
Киткәнеңнән бирле!

Әнкәй!
Дөнья иминлеге гомер буе
Күңелеңдә иде.
Иң изге ул догаң миндә бүген –
Гүяки син васыять итеп бирдең:
– Сакла! – дидең, – Җирне!
...Киләчәккә алып барыр –
Хәзер
Шул яшәтер мине:
Дәвам итәр йөрәк синең уйны,
Киткәнеңнән бирле.

Беләм:

Җир хәстәре күчкән маңгаема
Беренче кат мине
Үпкәнеңнән бирле!

* * *

Әтисезлек... Юк, ятимлек димим:
Безне кеше иткән әнкәмнең
Рәнҗер рухы...
Читләмәде Бәхет –
Язмышыма рәхмәт әйтәмен...

Ләкин бүген сәер бер хис миндә:
Ятим хыял һәм моң бар бугай...
Көчле, матур, бәлки,
Ләкин боек:
Түрдә түгел урыны,
Тар бугай...
Бәргәләнә очар өчен, гүя
Тели биеклеккә ашарга,
«Син үксез бит...» дигән тойгы
Бирми
Горур булып, күкрәп яшәргә...
Нидер югалткан да, читләтелгән,
Аерганнар Бәхет-әнкәсеннән,
Тумыштан ук гүя ятимә,
Төшенке бер рух яшеренгән аңа,
Кимсенүле хис бер, хатирә...
Башкалардан, юк, ким түгел –
Тигез
Яратылышында...
Тормышта
Бер каһәрме килеп, арыналмый
Гүяки бер фаталь каргыштан.
Сәбәп нидә? Кайчан ялгышкан?!

...Тарих! Дәвамында – бер сынса да,
Югалса да – терәк-Ватанын
Кабат табып күтәрелә алган
Хыял, моңнар азмы?
Көн саен
Калка алар барлык кыйтгаларда
Язмышына каршы, мөгаен?! –

Тулы хокук даулый алар үзенә.
Бәхет яулый һаман...
Әнкәем,
Ятим моңлы түгел җырым, рәхмәт!
Бар дөньяга хасмы бу мәрхәмәт?!
Юкка мәллә уем, әйткәнем?!

* * *

*Н.Н-гә*

Их, ичмасам... сез калсагыз икән
Ваклыклардан өстен, югары...
Күпме җаннар юкса (мохит тармы?!)
Кичерәйтте үзен, югалды...
Ичмасам, сез ерак торсагыз соң
Гайбәтләрдән, дөнья чүбеннән...

Алтын булсаң буялмыйсың – хаклык
Калка хәтта чорлар төбеннән.
Кала алган бар бит һаман да пакь,
Тидермәгән һич кер-тузанны.
«Өстен вә кул җитмәс...» Тукай кебек!
Җиңел кичкәнме ул дөньяны?!
Сез табынган Лермонтов бит яза:
«Бер давылсыз диңгез буламы?!»
Якты көн күзеннән кем яшеренгән,
Олы җаннар даусыз торганмы?!
Арсагыз соң – биеклеккә китеп
Мөмкин ләса «вәхи алырга».
Ят эшме ул Минә, Арафаттан,
Юк, Машуктан кайткан «хаҗи»га?!
Хәсән Туфан сезгә үрнәк шәхес:
Бөек җан ул – ниләр күрмәгән:
Хәтәр чорлар...
Нинди якты җырлар –
Кешеләргә хисе сүнмәгән...
Юк, шагыйрьгә килешмидер һәр шик,
Ачу, уйны җырда калкыту –
Каршылыклы рухны фаш итү?!
Җирдән, тузаннан без яратылган,
Юк үзеңнән качу, югалу...
Ләкин рухың оча алса икән
Хәтта Җирдән биек юл алып:
Их, чын шагыйрь өстен калса икән,
Горур булып җырда, югары...

* * *

Җир – гаҗәеп...
Балкый кеше аңы,
Йолдызларга хәтта юл алып;
Якты нурга охшаш гомерләр бар,
Кешеләргә үрелә хыялы...
Гомерләр бар – җирне шашып сөйгән,
Һәр карышын – туфрак, чирәмен –
Сөю тылсымында яшәртүче,
Илһам итеп хезмәт, тир тәмен.
Күпме гомер – кешеләргә шатлык,
Үкенечле түгел үтсә дә:
Ул җыр булып һәм нур булып калган,
Җыр, нурны чор биек күтәрә –
Чын мәхәббәт белән сугара ил...
Дөнья әнә шулай бара күк...
Матур кебек – ә каян соң анда
Яман таплар?
    Каян каралык?
Бар бит шундый җаннар:
Бар шөгыле –
Кара ягу аклык, сафлыкка.
Үч һәм мәкер белән сузылалар,
Дошман күреп, кемгә? – шатлыкка.
Акылыма барып җитми – күрәм:
Агу җыя алар гөлдән дә...
Югарылык өчен
Дошман күреп
Өстериләр җырны түбәнгә,
Яла, мәкер белән аулап аны...
Балга дегет сала – болгата,

Матурлыкка кушыла алмый, шуңа
Ачуыннан яши ырлап ла.
Нинди ялгыш белән яралган ул,
Нинди ләгънәт узган каныннан? –
Туганда ук гүя әмер булып,
Изгелеккә ишек ябылган!
Тик каралык, явызлыктан әгәр
Гөлләр үссә? Алар кем өчен?!
...Дөнья камил кебек...
Тик кешеләр
Аңлый белсен, дибез, бер-берсен!
Уртак максат өчен яши белсен,
Балкыр сөю – уртак бәрәкәт...
Тик ул кояш түгел мәллә,
Нурын
Тигез сипми мәллә мәхәббәт?!
Яхшылыктан мәхрүм, без белмәгән
Ниндидер көч җирдә бар төсле –
Каралыкны сөйгән явыз бер көч,
Кара күралмыйдыр ак төсне...
Кем гаепле моңа?
Синме, акыл?!
Нидән сәбәп? –
Ә ул – бар төсле...

* * *

Тукта, поезд, тукта, поезд,
Фазылҗаным утырсын!
Еракта килгән хатларым
Сагынганда укырсың.

*Сугыш чоры җыры*

Җырларыңның һаман искә алам,
Әнкәй, сагыш катыш булганын:
Син аларны артык моңайганда,
Утырып уйлаганда җырладың.
– Бу – Закирә җыры, бу – Бәһия
Җырлый торган...
Моңы синеке!
Үзең кичергән тик... Ә сүзләре
Халыкныкы, бөтен илнеке –
Алар
Сугыш,
китеп югалганнар,
Гомер буе көтү турында...
Син утауда йә уракта чакта
Мин дә үстем – басуларда түгел,
Бәлки, моңнар, җырлар кырында?!

...Әй, «туктама, поезд», мин уйланыйм, –
Күңел үз урынына утырсын,
Әнкәемә бүген хат язам мин –
Күземдә яшь... Кемнәр укыр соң?!
Ул исәндә яздым – озайтмадың
Гомерен ник, йөрәк утым, син?!
Ахырдан бит килә тетрәнүләр,
Үкенүләр кайта – үртәргә.
Җир астына юл юк хат өчен дә,

Күрешергә дә – кайтсаң үткәнгә.

Җырларыңны искә төшереп барлыйм,
Сүзләр – халыкныкы... Ә моңы?
Тик синеке, үзгә, кабатланмас...
Шулар аша тыңлыйм җаныңны!
Сагыш һәм авырлык тулы еллар
Ул җырларны җаныңа чорнады...
Саф, эчкерсез күңел назың белән
Керсез кичтең, әнкәй, дөньяны,
Безгә мирас иттең моңнарны!..

Җырдай гомрең уйлап, хатлар язам,
Яшемә буылып...
Кемнәр укыр соң?!
«Юк, туктама, поезд...»
Тетрәнүдән
Урынына күңел утырсын.
Күпме хатым, әнкәй...
Янып язам.
Һаман янсам,
тере утым – СИН!

* * *

Кабул итәр микән килер гасыр?! –
Егерменче! Синең – азагың... –
Тетрәнеп мин шундый сорау бирәм,
Киләчәкнең көтәм җавабын.

Еллар, сезгә төбәп язам мин:
Зур ялкында микән янам мин?!

Юкса җырда үз дөньям бар кебек,
Ул – бүгенге, Җирдән түгелме?!
Мин дә заман улы, юлларыннан
Читкә җибәрмәде чор мине...
Шатлыгым да, әрнүләр дә – аннан,
Хыялларда аның алсуы:
Егерме биш елым янып үтте,
Ялгышларым, бәлки, үземнеке,
Табышларның бирде барсын ул.

Килер гасыр!
Сиңа җитә алмасам
Яки
Синдә һичкем мине аңламаса?!
Шуннан да зур нинди җәза бар?
Гомере буе болай да бит үзен
Гел җәзалап яши язганнар!

Ул җәзамы?
Ул – ут, янам мин...
Яңа гасыр! Нинди җавабың?
Сорау бер, ут, –
Сиңа барам мин.

* * *

Яшерен яну диләр...
Яшерен микән?
Буламы икән янып яшерен:
Эчем-тышым бер ут, күренеп янам,
Янам икән – җаным яшь минем...
Утның серен, сәбәпләрен белмим,
Миңа кыйммәт, бәлки, халәтем?!
Үземнеке, тик үземә тигән
Язмыш утым,
яну сәләтем.
Гомер әгәр янып уза икән,
Сизелми дә үтәр – бер минут,
Бер мизгелдәй вакыт...
Димәк, гомер
Дөрләп янган тоташ ялкын-ут?!

Янып сөйгән, янып яшәгәнне
Иң бәхетле гомер дигәннәр.
Шул хакта бер уйлау өчен кайчан,
Кемнәр вакыт-утны бүлгәннәр?! –
Ялкын һәм боз, ахры, гел янәшә:
Хискә акыл куша белгәннәр!
Яшерен яну диләр...

## ХАТЫН-КЫЗЛАРГА ҖЫР

Яратабыз, дибез... Шулай микән?
Сүздә һаман әйтеп без аны,
Ә гамәлдә сезнең иңгә инде
Салмадыкмы... хәтта дөньяны?! –
Хатын-кызлар!
Әни һәм әбиләр,
Апалар, әй, ярлар, сеңелләр...
Сезгә һаман җыр без багышладык,
Бәлки, алар ихлас түгелләр?!
Җиңел генә мактыйбыз да һаман,
Фәрештә, дип күккә чөябез.
Ә чынлыкта нигә Адәм эшен
Сөйгән Хавабызга өябез?
...Көрәк һәм лом тота безнең Муза,
Гөлләр, сездә таудай мәшәкать –
Вазифалар йөге... Ә нәфислек?
Каян вакыт сиңа, мәхәббәт?!
Заманалар гаме җаныгызда!
Айыйбызмы наз, ямь иясен?!
Сакланамы Зөләйхалар? Матур –
Ул батыр да бүген, күрәсең...
Юккамы ир, ата була белмәс, –
Җәмгыятьтә гамьсез кеше өчен
Сез янасыз! Нык гаилә, нигез,
Җир бәхете, илнең эше өчен
Җаваплылык, зур горурлык сездә!
Күпләрегез җыр да язалар –
Зарланусыз, якты... Кырыс бары!
Сез шул – атом чоры музалары,
Вазифалар гөле – розалар...
Беләбезме кадерегезне сезнең?

Күрсәтәбезме чын хөрмәтне?
Матурлыкны мактау булды, әмма
Онытмадыкмы зур хезмәтне
Сезнең, бөек гасыр Хавалары,
Илнең чын каһарман кызлары?!

Яратабыз, дидек. Изге сүзне
Арзанайттык, ирләр, без аны!
Их, ичмасам, саклый белсәк икән,
Аңлый, яклый белсәк икән –
Инде
Сезнең иңдә барган дөньяны!

* * *

Борынгылар илаһ-Венераны
Ни өчендер икегә аерган:
Күкнеке һәм җирнеке дип аны
Һәр икесенә дә табынган.
Әйе, табынучы табылган!

Идеал мәхәббәт ул – күк илаһы
Венерага табыну, инану,
Бер гөнаһсыз калып сөя белү,
Уй һәм рухта биек юл алу...
Җир Венерасына табынсаң син,
Егылып тән-илаһ алдында, –
Ялангач җир кызына баш иеп
Яшәү гөнаһ, ләззәт багында!

Ике илаһ...
Бер-берсенә дошман,
Каршы яклар – тән һәм җан көче...
Шагыйрь, барыннан да бигрәк синдә,
Имеш, шушы көчләр тартышы!
Идеал син эзләп яшьтән һаман
Омтылсаң да рухта хыялга,
Тәнең синең ихтыярсыз беркөн
Гөнаһ тузанына буяла...
Аңа баш иясең, онытып күкне!
Үче аның килеп тапканчы.
Никадәрле хыял көчле булса,
Шундый ук зур чынлык җәзасы...
Җиргә артык якынайсаң – күкләр
Үчен ала... Шулай барасың.
Тетрәнәсең гомер буе шулай...
Ә соң килештерү икесен –
Ике Венераны – мөмкинме икән? –
Куша алсаң ике көчне син?!
Көнен Күк-илаһка, ә төннәрен
Җирнекенә, хыял, табынсаң?!

...Борынгылар моны белмәгәнме? –
Белсә, нигә әле аерган?

Ә бүген соң, кемгә табыныйм, дип
Киңәш сорыйлармы шагыйрьдән?

## ЧИШМӘ БАШЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Без бөгеп уйнаган таллар,
Кара!
Нинди биек үскән!
Без сыймый йөргән урамнар
Бүген
Ник бушанган икән?

Тәрәзләрең, авыл, яшьләр азга
Моңсуланганмы соң?
Күкне дә тик иңнәрендә картлар
Терәп торамы соң?

Нинди гамь ул, нинди сыйфат киткән
Авыл кешесеннән?
Туган туганына кырын карый,
Күрше – күршесенә...

Исереклек, әдәпсезлек, буш сүз
Каян әле арткан?
Иман качып бик тиз, ни ул шулай
Үз юлына тарткан?!

...Шуны күрмәскәме
Безнең таллар
Күккә карап үскән?!

Яшьлегемдә түгел, бу авылда
Бүген сине күрсәм,
Матурлыкны,
Мәхәббәтнең үзен
Табар идем микән?!

...Ярый очрашканбыз вакытында,
Вакытында, ахры, туганбыз да.
Бәхетлебез икән!

## ТАЛБАЗЫ АВЫЛЫНА ҖЫР

Талбазыма – яшьлегемә
Кабат кайту язганмы? –
Исемең гел кабатланды
Күңелемдә, Талбазы!

...Мәктәп юлын очып үттем –
Канат куйды язлармы?
Урамыңда шашып йөрдем
Хисләремнән, Талбазы!

Кышкы кичләреңдә яндым:
Җанны утлар ялмады! –
Сиерыш елга бозын мин
Эреттемме, Талбазы?!

Ә сөйгәнем гүя биек
Күктән күз дә салмады:
Хыялга юл күрсәтте тик
Шул йолдызың, Талбазы!

Җырларымны аңламады –
Күңлемне ул алмады...
Син юаттың яшь җанымны,

Син көлмәдең, Талбазы!

...Еллар узгач, олыгайгач
Безнең яшьлек таллары,
Очраштырдың кабат – хисләр
Чәчәк койгач, Талбазы!

Аңа таныш бар гомерем –
Һәр яфрак, гөл тармагы...
Сүзсез генә кагылдык без
Үткәннәргә, Талбазы!
Ник Сыерыш елга тынган?
Тарайганмы ярлары?
Ташкан да ул кайткан... Безгә
Гыйбрәтме шул, Талбазы?!

Бар да әйбәт! Яшьлегемә
Инде үпкәм калмады...
Рәхмәт сүзе белән тидем
Талларыңа, Талбазы!

* * *

Нәркисләрең нигә төбәп карый:
– Югалтканнар булыр сезне, абый?!

...Югалдым ла үзем синең янда –
Хыялларда эреп, ал томанда...

Зәңгәр кичнең салкын, саф сулышы...
Кай арада хистән җан тулышты...

Исе, исе язгы бөреләрнең! –
Бөре кебек ачыла иреннәрең,

Пышылдыйлар, үртәгәндәй мине:
– Сезне, чынлап, көтәләрдер инде?..

Ә мин әле болытларда, күктә...
(Төшәргәме? – вакыт ник тиз үтә?!)

Ә ник кала алмыйм синең янда,
Яшьлегеңдә – биеклектә, язда?!

– Ястык кадәр булсын, язгы бозга –
Мавыгуга! – куркам таянырга!..

Хыяллардан чынлык күпкә үзгә! –
Шундый сүзләр укыйм синең күздә.

Каян бөек гакыл япь-яшь кызда?
...Ахры, мине тормыш читләп уза...

Нәркисләрең кызгангандай карый:
– Сезне...
        Җирдә эзлиләрдер, абый?!

**КЫШКЫ ИДИЛЛИЯ**

Шундый салкын!
Агачларда сыкы,
Син дә бәсле шәлгә уранган –
Тик күзләрең күренә... Якты алар! –
Без киләбез төнге урамнан.

Агыйделдән гүя, Юрүзәннән
Казан безне үзе чакырды:
Шигырьләргә, моңга ул – башкала,
Шунда булсын дәвам, ахыры...

Күге нинди! Йолдызлары – якын,
Хыяллар да шуңа балкыймы?
Син тыңлыйсың: шигырь сөйләп киләм,
Тавышым батыр,
хәтта акыллы.

Нинди бәхет:
Шигырь-Җыр очрашкан,
Моң тантана итә – юл алган.
Кайнар сулышыңны тоям,
Юкса
Күзләреңәчә син уранган.

Бәсле пәрдә...
Кемнән саклый сине?
Яман күздән?
Кышкы урамнан?

...Бик биектә хыял:
Безнең өстә –
Казан күге...
Җилләр – Уралдан...

* * *

Шундый садә, матур син оялдың...
Мин идемме сәбәпчесе аның? –
Әрсез караш белән әйтеп салдым:
– Әй гүзәл сез, ханым...

Син кызардың – битләреңнән үтте
Балкып гүя кичке кояш уты...
Нинди кич ул... кызу төш вакыты:
Җаныма ут капты!

Сафлык һәм инсафлык... Борынгы ул
Әдәп синдә каян, наз иясе?!
Халкың биргән күңел байрагымы?
Башка ни диясең?!

Кырыс бу дөньяда саф оялу –
Кызаруың – гаҗәеп байлыгың...
Гәүһәрләрдән кыйммәт – урлатмадың,
Ничек саклый алдың?!

Сүзләремне кичер минем... Ләкин
Шундый матур итеп кызардың син,
Мин тетрәндем хәтта...
Инде тагын

Күрсәм иде шулай оялганың.
Әзермен мин кабатларга, янып:
– Әй гүзәл сез, ханым!

* * *

*Равилгә*

Кемдер, Хыял, бүгенгеңне мактый,
Ә мин синең горур яшьлек яклы! –
Көчле иде бит ул, югары...
Мин дә бурычлыдыр аңа:
Рухны,
Әйдәп, биеккә ул чыгарды...
Яңа күтәрелеш дип танылган
Алтмышынчы еллар хыялын –
Сине – яшьлек аша сагынсыннар...
Тугры аңа минем уйларым...
Илдә күпме үзгәрешләр, җырда
Тулпар иде безнең, ирекле...
Еллар аша килә тояк җиле, –
Юкса вакыт сабыр ир итте...
Яну, ярсу түгел элекке.
Бәйгеләргә ашкынган чак үтте!
Кемнәрнеңдер һаман күрәсе
Килә безнең җилеп узганнарны...
Ә кемнеңдер килә: «Үшәнләнде
Күптән алар, күр! – дип көләсе.–
Узган дан хакында бәхәсләшеп,
Яши алар хәзер»,–диясе...
Аяусыз шул вакыт!
Тулпар түгел,
Бездә, бәлки, чынлап йөк аты?!
...Яшьлегеңне сагынам – шул елларга
Килик, Хыял, тагын бер кайтып?!
Яңа йөрәкләрне биеклеккә
Кемнең омтылышы чыгарыр?!
Кабатланмасмыни андый яшьлек?!
Күңелдә ул...
Сүнмәс чыраг ул!

## БЫЛБЫЛГА ЭНДӘШҮ

Кер әле, керче яныма:
Тәрәзәм ачык, былбыл!
Бүлмәмне тутыр моң белән –
Күңелнең кунагы бул.

Сөйләче: тиңсез җырыңның
Күпме ул гомер, яше?
Нинди ил, дәверләр гаме
Моңыңа күчеп яши?!

Үткәннәрдән киләчәккә
Тоташып сайрау өчен
Кем бирде сиңа, нәни кош,
Тарихны саклау көчен?!

Ә нинди телдә сайравың?!
Борынгы әнкә телме?! –

Аңлыйбыз сине... югыйсә
Һәммәбез төрле-төрле.

Һәр халык үз моңын эзли,
Күңел тавышын таба:
Безне мәңгелеккә дәшкән
Вакытмы синдә ага?!

И былбыл фәне, син чорлар
Чынлыгы белән көчле!
Илаһи да, гади дә син,
Һава, су, икмәк төсле...

Бәһасез алтын мирас син!
Нәселеңә, варисыңа
Шундый ук сәләт килерме
Якты моң ярышында?
Югалтмаслармы соң моңны?
Сез – Бөек Былбыл иле,
Моң – гомумдәүләт байлыгы,
Ул – милли дәүләт теле!
Йотылу, бетү юк аңа –
Былбылстанга, димен...
Моңыннан язган теленнән,
Дененнән язар иде...

Халык тарихы – Әнкә тел! –
Моң теле икән, былбыл!
Гомер!
Шул тел сагында син,
Мәңгелек гыйбрәт –
Моң бул!

## ЛӘЙЛӘЛӘР ЯЗСА...

– Менә ниндигә әйләнде дөньялар!
...Күптән үзгәрде син күргән гөльялан, –
Аңа ул чак кем сокланып узмаган? –
Синең хакта сөйли ник гөлләр һаман?
Менә ниндигә әйләнде дөньялар!

Син, озын чәчле хыялый бер гашыйк,
Килдең дә бер ул яланга сак басып,
Киттең үзең – гүя чынлыктан качып...
Хәзер аңлыйм: киткән алып хыяллар.
Менә ниндигә әйләнде дөньялар!

Мин ул чактагы «очынтык» кыз түгел,
«Биек янган салкын бер йолдыз» түгел.
Син уйлаганча, минме бер «таш күңел»? –
Тәкәббер яшьлегемнән оялам...
Менә ниндигә әйләнде дөньялар!

Җирдә бар да Мәҗнүндәй гашыйклармы?
Ә сөйгәнен аңламаганнар азмы?
Их, дим, нигә Ләйләләр каләм алмый? –
Алар чын булганны язып чыксалар!
Менә ниндигә әйләнде дөньялар...

Соңлап, бәлки, бу хисләрем уянган?..
Әйе, үзгәрде син сөйгән гөльялан;
Анда, белдем: синдәй гашыйк булмаган.
Исән гөлләрем исеменнән мин язам:
Менә нindигә әйләнде дөньялар!

## УЙЛАНГАНДА

*А.Г-кә*

Кырыс әкә! Нәкъ егерме ел элек
Бер хатыңда мине «искә алгансың»:
– Кара, нинди ялгыз ул, дусларсыз ул! –
Сиңа, миңа шундый язмыш язмасын!

Дус кадерен белмәс яшьтә булганга,
Бу сүзләрең сәерсендерде мине...
«Нинди ялгыз... дусларсыз!» дип сыйфатлау –
Горур, мәгърур ул, дип раслау күк иде.

Аннан әйттем: шулай алдан язмышны
Укып белгән, бәлки, җиңел холкымнан?
«Ялгыз, дусларсыз...»
Ялгыш та язгым
Алып китмәсен берүк ил-йортымнан!

Гомер бара... Уйланам да шул сүздән
Егерме ел җыя алмыйм исемне:
Егерме ел башым тотам –
Кешеләр
Таш атып куган
пәйгамбәр шикелле!

## ӘЙ, БӨЕК ЗАР...

«Бер күрергә зармын...» дигән халкым,
Өстәп әйтсен шагыйрь тагын ни?
Юкса миннән... Кандалыйдан элек
Язган «Сөю фәне»н Овидий!
«Җырлар җыры» калган Сөләйманнан,
Борынгыдан килгән, табигый...
Кыйтгаларны гизгән бөек зар бу...
Сөрелсәң дә ярың хакына,
Каһарманнар сыман, син үлемсез –
Мәхәббәтең калса халкыңда...
«Бер күрергә зармын...»
Кичер, Хафиз:
Миңе өчен ярның, шәһәрләр
Вәгъдә итмим инде – юлыгыр дим
Бу «юмартлык» бүген каһәргә:
Ил-шәһәрләр белән шаярмыйбыз...
Безнең чорда хәвеф, һәлакәт
Килмәсен дип яну... Ышанам тик,
Җирне саклар шул ук... Мәхәббәт!
Алып чыгар гүя кыл күпердән
Ул, җаныңда аны күтәреп,
Каршылыклар тулы бүгенгедә
Ул – һаман шул, Җирнең күчәре.
«Бер күрергә зармын...» Әй, йөрәкләр,

Тарихыгыз ничә мең еллык бит:
«Сөю фәне»н белә кешелек, –
Син – бөек зар, халык күкрәгеннән,
Шулай күкрәп һаман кал биек...
Йөрәк тарихында яшәр халкым,–
Мәхәббәттә...
Ә ул – мәңгелек!

## УТЫЗ ЕЛДАН СОҢ

*(Хис-поэма)*

Кайсы кыйтгадан бу аваз?
– Алло, синме?
 – Әйе, мин, – дим... –
Ә сез кем соң?
 – Танымыйсың?!
Бу – мин... Таң йолдызың синең!
Ишетәсеңме?.. – Мин һушсыз
Калдым гүя... Чынлапмы?.. Син?!
Күпме елдан соң... Төшме, йә,
Яшьлектә югалткан кешем!
Кичә генә аерылгандай,
Телефоннан гади генә:
– Саумы? – дисең...
 Мең елдан соң
Ләйлә шулай дәшсә менә
Бүгенгегә, Мәҗнүненә?!
Ни әйтерсең?
 ...Белсәң иде –
Күпме минем уй багланган
Исемеңә: сагынылган,
Назлар яуган... йә каргалган
Алиһәм син... Бүген каян
Синең аваз? Көтмәгәндә?
Ә бит үзем кыймадым мин
Эндәшергә үткәннәргә.
Гүя бер хыялый роман
Каһарманы – киләчәктән
Хәбәр килер дип берзаман,
Көтә идем... Менә бүген
Уйдан кичә бар гомерем!
Шул гомергә таҗ кидердең:
– Бу – мин, Таң йолдызың синең...

*

...Сәләмәләрдә үссәм дә –
Салам-Торхан кебегрәк,
Иң сәламәт хыял иде
Синдә дөнья өчен, йөрәк!

Бәхетен соң бөекләрдән
Кайсы хыял ким санаган?–
– Миндә Байроннар җаны! – дип,
Бер Такташмы кабатлаган?

«Таң йолдызым!», «Мэри»*, «Ләйлә»м!
Әле сине күргәнче үк,
Йөрәктәге Бөек Гашыйк
Үз дөньясын эзли иде,

Ахры... чынбарлыктан качып:
Гасыр уртасында илдә
Чәчәк аткан фәкыйрьлектән,
Бәхетстан дип тукылган
Коллыктан, ирексезлектән,
Сугыштан соңгы ачлыктан,
Зурларга, бацилла кебек,
Җиңүдән соң Европадан
Ияргән чын кансызлыктан,
Тамырын тирән җибәргән
Динсезлек – имансызлыктан
Йөрәк, бәлки, качкан иде –
Ул хыялга ашкан иде...

Әй, сугыштан соңгы, авыр
Моңлы авыл, кырыс авыл! –
Син дә йөрәгемдә кыен
Истәлекләр калдырмадың:
Юк, мохиттән өстен иде,
Чынбарлыктан биек – йөрәк...
Бер хәйләсез, бер кинәсез
Уналты яшьлек йөрәккә
Башка дөнья иде кирәк –
Качып чыктык шул көннәрдә
Хыял атын иярләргә!

*

– Кайсы гасырда яшисең? –
Укытучы апа классны
Шулай бер сыныйм дигәндә,
– Егерменче гасырда! – дип,
Берүзем җавап биргәндә,
Белмәгәнмен: йөрәк күптән
Шәрекъ, гареп илләрендә
Мең еллар элек яшәгән –
Мәхәббәт шагыйрьләрендә!
Яки ерак бер йолдызда –
Яңа бер Кояш астында...

Ят тоелганмындыр сиңа –
Тормышчан чая бер кызга...
Таң йолдызым!
Шуңа да син
Нурларыңны саран сиптең;
– Егерменче гасырдан мин! –
Дип алдаганым белгәнсең –
Ышанмагансың... Көлгәнсең...

*

Йөрәк!
Җирдә – мәктәбеңдә –
Кайсы чор каһарманына
Иярдең язгы бер көндә,
Директор кабинетында,
Тәртибеңне аңлатканда
Укытучылар алдында...
Ярның әнисе – янында...

– Ник тиргисез, аңламыйм мин...
Ышаныгыз ихлас сүзгә:
Бердәнбер гаебем – шул кызга
Хисемнең зур булуында!
Башка гаебем юк... – Шунда
Сүзсез калды бер кабинет,
Катып калды әниең дә:
Кемдер аңа яшьлегендә
Шулай хисен белдергәнме? –
Мәшәкатьле гомерендә
Мондый башсызны күргәнме?

...Әй көлделәр мәктәбемдә!
Убылмады баскан җирем,
Чайкалмадың син дә, дөнья;
Тугыз йөз илле тугызда
Мәктәбемдә – Талбазыда
Тормыштан бу иң беренче
Сынау иде «яшь Байрон»га;
«Мәри»га – Таң йолдызына
Багышланачак җырыма
Бу пролог-дәрес иде:
Булсын бар гаебең җырда –
Тик хисеңнең зурлыгында!
Менә шулай килдең, йөрәк,
Мәхәббәткә – зур юлыңа,
Әйе, бөтен барлыгыңа.
Ихлас хисләр иясе дип
Танылдым мин дусларыма. –
Мин рәхмәтле сиңа шуңа!
...Күпме инде бу хәлләргә? –
Юл башына...

*

Кайсы йолдыздан син, аваз?
Кай гасырдан?
Таң йолдызым,
Үткәнгәме чакырасың?..
Юл юк аңа... булса – озын...
Кайда Вакыт машинасы?
Бүгенгедә бит ансыз да
Без белмәгән хикмәтләр күп:
Оча торган тәлинкәләр
Күренә гел анда, монда...
(Күптән түгел – Воронежда!)
Алар ник киләләр әле –
Кемне эзли ияләре?
Әллә бик күп еллар элек
Җирдән киткән йөрәкләрме –
Мәңгелектән матдә-җаннар
Туганын эзлиләр бүген?!
Игезәктәй пар күңелен?!

...НЛОлар, тәлинкәләр –
Гасыр ахыры «бизәкләре»;
Йолдызларның аңлашырга,
Очрашырга теләкләре

Туган, бәлки, безнең чорда?!
Космосара ООНныңмы
Берләшергә чакыруы?!
Чираттагы зур яшәеш
Соңымы? Сөю ахыры?
Шушы дәвер минем хисне
Суытмаган бит юри дә;
Юкса кемнәр тугры хәзер
«Ләйлә»сенә йә «Мэри»га?
Синнән хәбәр булып, бәлки,
Өндәү килгән:
              – Алло, тыңла:
Гаебең түгел, бәхетең –
Хисеңнең зур булуында!
Мин аңладым моны хәзер –
Синнән соң гомер юлымда...
Кире кайт Таң йолдызыңа!

Кайтып бул-са-а-а...

Кашпировскийлар илне
Алынганда «дәваларга»,
Экстрасенслар шаукымы
Бар җирдә яңгыраганда,
Мин һаман үзгәрми калам:
Йөрәгем юлында барам...
Таң йолдызым! Ә син аңа –
Исемеңне гел яшереп,
Мин язган хис-поэмага
Бәяңне бир!

Вакыт ага:
Егерменче йөз ахыры –
(Гомер төшлегеннән ашты!)
Ил үзе дә үзгәрешләр,
Яңарышлар юлын ачты...
Тик үзгәрү авыр, ахры...

Таң йолдызым! Әмма җырда
Буламы яраклашырга
Яки оста алдашырга?!
Йә хиснеме онытырга?
Үткәннәрдән ваз кичәргә? –
Остазың Мәҗнүн исеменнән?
Йөрәгеңнән? Гомереңнән?
«Акыл белән»ме яшәргә?!
Гыйбрәтең шулмы яшьләргә?!
...Үзгәрмәгән изге гамь бар,
Халыкчан моң, бөек иман,
Үзгәрмәстәй ышаныч бар,
Идеал бар, дәшеп торган...
Үзгәрсә дә кояш, һава,
Икмәк, су тәме җиремдә,
Телебезне, моңыбызны
Саклар сөт калган күңелдә –
Фида гомер дә шул юлга:
Үлемсезлек, бәлки, шунда –
Хисеңнең зур булуында...
Юк, бирмәбез Мәхәббәтне
Иблискә – аның кулында
Галәмара үлем уты...

Ә без корал итеп Хисне,
Яшәү өчен яуга чыктык...
Киләчәккә Кешелек тә
Шулай үзен саклар, дөнья;
Бәлки, бердәнбер чараң шул –
(Һәлакәт аша узар юл!)
Мәхәббәтең булуында...

Мин ишетәм сине, аваз!
– Алло, алло!..
– Мин – юлымда...
...Моны яздым Казанымда,
Тугыз йөз сиксән тугызда...
Гаугалы Елан елында!

**ГАИЛӘ ӘДӘБИЯТЫ**

И, без нинди матур идек! –
Күбәләктәй җиңел йөрдек
очып сөю тирәсендә:
гашыйк син дә, гашыйк мин дә...
Идеалларны таптык, гүя –
булганыбыз Поэзия...

Ахыр – юллар бергә булмыш.
Җиңел генә бармый тормыш:
Үпкәләштек бераз гына,
Үртәштек тә аз-маз гына;
җилләр тынса, дулкын шыма,
эзе калса, кала азга...
Ну, болары инде – Проза.

Күңел – шайтан. Бер-береңне
көнлисең дә – Комедия!
Аңлашканда – тулы драма:
характерлар туры килми,
ә жанрлар ерак йөрми –
булу мөмкин Трагедия!
Катлаулы соң Әдәбият! –
Безгә дә бертөрлелек ят:
бер-беребезне өйрәнәбез;
өйрәтәбез,
хаталарны әйтеп, чәнчеп.
...Гаиләне ныгытырга да
кирәк икән шул ук Тәнкыйть!

* * *

Танымыйлар димсең синең кулны,
Анонимга поскан йөзеңне?!
Кыңгыр эшләреңне сизмиләр дип
Ышандырасыңдыр үзеңне?! –
Ялгышасың!
Мәкер магистры
Бул син, хәтта Иуда «таланты»н
Үзләштер –
Тик барыбер күрәчәкләр:
Шул ук мөртәт булып калгансың;
Иезуитча ярашсаң да көнгә,
Үзгәртеп тик битлек-карашың;
Табигыйлек ләкин киткән синнән,

Калтырана дәгъва һәр сүздә:
– Мин җиңәргә тиеш... –
Узурпатор
Фәлсәфәсе плебей-әрсездә!
Ә күңелдә безнең күпме йолдыз –
Чын фидаи, хаклык корбаны,
Кем хәтерли – карьера дип, алар,
Кайда мөмкин – хәйлә корганны?!
Кайчан булган бездә шундый сәнгать:
Таптап йөреп кеше башыннан,
Үзе кешелеккә хезмәт иткән, –
Язып вөҗдан, иман – барсыннан?!
Аңламыйлар, димсең?
Ялгышасың,
Чамалыйлар синең чын йөзне.
Зур сүзләргә төренсәң дә, мәкер,
Ялган –
Алдый алмас ул безне.
Юк, таныйлар синең стиль-кулны,
Әйтәчәкләр төгәл исемеңне...
Үзеңнән дә ваграк интригаларың
Сине күмеп китмәс дисеңме?!
Ялгышасың!

## УРТА КЕШЕ ФӘЛСӘФӘСЕ

Юаш булсаң, басарлар,
Усал булсаң, асарлар.
Урта гына кеше булсаң,
Ил агасы ясарлар.

*Халык сүзе*

Әллү, дөнья, бәллү, дөнья,
тирбәт мине, яшәт...
Әлегә мин риза синнән:
биргәнеңә –
рәхмәт!

Әйтә алмыйм кан койдым дип,
тир түктем дип рәтләп.
Даным да, медалем дә юк
(Салкында туңганым да юк!),
ә бик рәхәт... Рәхмәт!

Кем көрәште – көне узды,
ыгы-зыгы белән яшәп:
янды берәү, батты берәү...
Мөхәммәт йә Әхмәт...
Тапты шан йә нәфрәт...
Акыл белән гомер кичтем –
алдым фәкать рәхмәт.

...Әллү, дөнья, бәллү, дөнья,
тирбәт, озак яшәт.
Бар да матур, бар да әйбәт,
җылы, якты, рәхәт.
Рәхмәт! Рәхмәт!

## ГАНКА

Моң кошы бар –

ул Сандугач атлы.
Иң көяз кош – Тавис,
иң сүзчәне – Тутый, ахры.
Төн кошы – Ябалак,
көн кошы – Тургай.
Әкият кошы – Сәмруг,
татар кошы –
Тартар бугай...
(Шулай дигән Тукай!)

Яшәгән ди хәтта аңгыралык кошы –
Ганка!
...Үзең сакла!

## ЙОКЫСЫЗ ТӨН

Буран...
Авылымнан китә алмый ятам...

*Р.Миңнуллин*

Буран йөрде Сөн буенда,
авылда,
Тәрәзәмә кар куллары
кагыла...
Бер юл яза алмаган моңсыз
чагымда
кешнәү тавышы ишеттем мин
урамда.
...Әллә Пегас калган бүген
буранда?
Әллә аранын ватып ул
чыкканмы?
Күктә ай күренми – шуннан
куркамы?
Кешнәү тынды.
Ни өркетте
Пегасны?
...Кем сызгыра?
Суймасмы
Урлап ул аны?
Атның ал канымы тышта?
...Таң атты.

Әнкәй торып бик иртәдән
мич якты.
Өшәнгәндер, алып керик
Пегасны!

## ЙОКЛА!

Йоклыйсыңмы, ә, илһамым?
Син, шигырем? Йокла!
Тирә-юнең тып-тын ласа,
шау-шу, тавыш юк ла. –
Йокла!

Йокы – иске, изге бер эш,
бабайлардан йола.
Шагыйребез кабатлаган:

«Йокы, йокы...»
 – Йокла!

Дөньясында ни бар, анда
кемнәр ялкын-утта.
Сизмә берни, белмә, каләм,
кыймылдама, йокла!
Бул данлы бер битараф син,
борчу, гамең юк ла.
Төшең матур: кызлар иле,
гөлләр туе... Йокла!

Йокла, илһам!.. Әй, кара әле,
мәрткә үк син китмәдеңме?
Исәнме син, тукта!

...Тәнкыйтьтән соң ял итәмсең?!
Алай гына булса
ярый, туган, йокла!
Йокла!

## КҮҢЕЛГӘ ГАЗӘЛ

– Әй-я, күңел! Сиңа әйтәм, саңгырау булма,
«колагыңны» борып әйтәм, аңгыра булма:

Картны олыла, яшьләр юлына тыкма таяк –
нигилист йә консерватор булып куйма!

Өметсез эшнең булмасаң да оптимисты,
максатыңның оппортунисты син булма.

Булма кешелексез кешеләр тарафдары, –
берүк Иблис шайкасында да син торма!

Җыйна акыл, онытма уй-хыялны, тик
чынлыкта, тормышта фантазер булма.

Максатын-идеалын җуйганнардай,
флюгер кук әйләнергә әзер торма!

Солтаны бул нәфесеңнең, түгел колы,
шәп рифма бул, иярчен сүз – рәдиф булма.

Бакчачы бул гомер багына, карак түгел...
дөньяга да читтән генә карап торма.

...«Булма» сүзен күп ишеттең, куркам, күңел:
бернәрсә дә була алмый, харап булма!

* * *

*(Бирәүгә ишарә)*

Белергә тиеш сабагын
иҗекләп ятлый торган
бер күсәк шәкерт сыман,
Ул
ник мисал китерә Тукайдан?

...Чын Тукай кая?! Югалган...
Ул сөйли, сөйли һаман.

Бөек рухын ачалмаган,
һәм аңламаган хәлдә,
сүз пәйгамбәре хакында
ни әйтсен андый бәндә?!
Үзең күр чарасын, Тукай! –
Югыйсә гаҗәп безгә:
«Күзләре тездән түбән»нең
«Сүзләр»е хаҗәт кемгә?

* * *

Традицион шигырь! Миңа
Син кырын карыйсыңдыр:
Язганым да верлибр, ул –
Кытыршы, хорейсыздыр. –
Туфандай, каргыйсыңдыр?!

Тик мин ник әле табындым
Ул үлчәү-ритмнарга?
Омтылдыммы бу тормышны,
Үземчә, яңа тасвирга,
Тулы канлы җырларга? –
Көйләү теле генә түгел,
Кирәк, дип, заман теле:
Булсын хисләр кайнарлыгы,
Сурәтләр гадилеге!

Чигенү юк, бәлки, миңа? –
Артык ерак кителде.
Ә бәлки, кайтырмын сиңа,
Үзгәреп, мин беркөнне –
Башта кануннарны ваткан,
Аннан гадилеккә кайткан
Һәм классик шигырьне
Фанатикларча яклаган
Бөек Туфан шикелле!

* * *

Нинди яшь идек без,
байлар идек без хыялларга!
...Илләр гиздек, Парижларны күрдек.
Җиттек микән максатларга,
йолдызларга?!

Кар астында – күпме гөлләр! –
гүя ятим телләр,
илләр...
Гасыр, җылы биралдыкмы
без аларга?

## V. Бу – сезгә кылган догам...

**(1990–1994)**

## ШӘРЕКЪЧӘ БЕР ШИГЫРЬ

Гөнаһлы теләк-уемны
син бүген, дөнья, кичер.
Мин, бәлки, беркөн сорармын:
– Әй, сакый, шәраб китер!

Китер чын әрем ачысын,
тормыш җамында китер.
Китер мәхәббәт агуын –
минем җаныма күчер.

Әй, сакый, китер дан сүзен,
мәдхия утын китер.
Китер әбелхәят суын –
бер генә йотым китер.

Китер, әй, теләкләремнең
соңгысын, чиген китер:
ахырдан һушны китәрер
бер садә шигырь китер!

Әй, сакый! Барсын кире ал.
(Кешеңне, дөнья, кичер!)
Яшәртсә яшәртер икән
Бу шигырь... Тагын китер!..

## БОРЫНГЫ КАСӘ

Саксыз тию ярамыймы чын-чыннан?
Бәллүр касә!
Таныйм ласа чыңыннан!

Затлы бәллүр!
Зеңли, җырлый ул әнә,
Путасында утлы күзме? – Сүз яна...

«Шәраб эчмәгез сез миннән, гашыйклар:
Җанда сезнең ачы-татлы сагыш бар,

Сезнең өчен дәва – бәллүр чыңлавы,
Сусаганны кайтарачак чынлап ул!

Түгелмен мин Җәмшид, Хәйям касәсе,
Төбемдә, бел, Мәҗнүн-Кайс күз яше, –

Анда Ләйлә, Шириннәрнең моң, уты,
Әбелхәят түгел, мәхәббәт суты...

Бәллүр – тулы, түгәрсез, кагылмагыз, –
Сүзсез моңымны ерактан тыңлагыз!

Булырсыз хуш, исереп шул чыңымнан:
Ихлас йөрәкләргә мирас җырымнан...»

* * *

Йә, ничек? Тагын бер калкынып сүнүме?!
Шулмы бу? Актык талпыну үземе?
Халкым, инде җиңүгә бит бу адым! –
Юкса ятлар язган хөкем – үлемме?

Ә нинди көч юлны бүген киртәли?
Шатлансак, кисәтә җанны: иртә, ди;
Нинди фәлсәфә кулланыр сәясәт?!
Гаеп ителсә милләткә мәхәббәт?!

Ярсып ага тыелган ташкын-сулар,
Инде даулый үз юлын милли җырлар;
Вакытын көткән халкымда күпме көч! –
Үлмәгәнбез, әле байтак дәрман бар.

Әмма ник вак-төяк бәхәс, ызгыш соң?
Ачылсын җанда икенче сулышың!
Моңарчы «гөнаһ» саналган изге уй –
Халкыңны сөюдән тусын һәр эшең!

Ничек? Кемдер, иртә, диме? Соң, диме?
Тәмам сүнәргә, күнәргә өндиме?!
Тыңлама, каумем, маңкортны, хаинне,
Яндыр, факел ит соңгы кат җаныңны!

...Үзең хәл ит, халкым, үз язмышыңны!

* * *

Җан дусларым, кардәшләр, милләттәшләр!
Тауар-ишләр, табындаш, шигырьдәшләр!
Гасыр сөреме сөрмәләгән чал кашлар,
«Әтәч яшьлек» масайткан, гаярь яшьләр!

Яшә, нәслем, бавырым, каумем, димен,
Сезгә шушы хитабым – хатым минем! –
Барчабызны айнымаслык исертсен
Бары ирек хисе, милләтем, димен.

«Милләтче» йә «милләтпәрвәр» дисеннәр,
Бәхет ул – милләткә бәйле исемнәр.
Ничә мең ел канда, җанда үлмәгән
Халык исме байрак бүген – күрсеннәр.

Җырым! Сине шул ышаныч тудырсын,
Халкыңнан аерылу бары куркытсын.
Иң бөек, зур чынлык шушы – дөньяда! –
Шуны аңламаган ирне җир йотсын!

* * *

Бу җиһанда нинди фал ул
Кигәвен?
Хозур күрсәк бакча йә кыр гөлләрен,
Акыл һәм хис тудырган дөнья ямен,
– Мин дә бар! – дип, борнын суза Кигәвен.

Матурлыкның колы без, мәңге гашыйк;
Хисләребез сугара, җаннан ташып, –

Ашлыйбыз еллар буе рух гөлләрен... –
Шунда бер тәнкыйтьче мәллә Кигәвен?!

Мәхрүмме ул моңнан,
шуңа көнчеме?
Йә, көчсезлеген сизеп, еш тешлиме?!
Таһир-Зөһрә багында сакчы ләгыйнь –
Кара батырмы бер – әрсез Кигәвен?!

Җәйге дөнья вәгъдә итә җимешне,
Иҗат көзе булыр камил, килешле.
Тик... туйдырды шул ят кавем –
фиргавен! –
Һәр бәхетнең сагында ник Кигәвен?!

Гомерләрнең шул матур бакча ямен,
Күңелләрнең кабатланмас гөлләрен
Күрү – сәнгать безгә: җыр да шул юлда.
Гаҗәп, мин дә шунда, дисең, Кигәвен!

* * *

«Сасна кызы!» дип кабатлыйм...
Искә алам исем-атын,
Моңлы Мәмдүдә ул истә:
Күптән вафат остабикә –
Халкыма пәйгамбәр затын
Бүләк иткән изге Әнкә... –
Аның исемен кабатлыйм!

«Сасна кызы» димен аңа,
Соңгы җыры, яше белән
Шул туфракны сугарганга.
Шәт, бу җирдә туган яшьләр
Изге кылларны өзмәсләр?
Бәлки, иман яшәр, халкым?!
Бәлки, кайтыр илгә тагын
Тукай кебек йөз аклыгың?!
Яд итеп пакь Әнкә атын,
«Сасна кызы!» дип кабатлыйм.

* * *

«Кыл өстендә, – дисең, – язмыш, гомер...
Ә кылга аз калган
өзелергә...»
Гашыйк җаннар, бәлки,
Өстен язмыш-фалдан?

Әй уйныйбыз хәвеф сизми, гамьсез,
Син дә шашкан, мин дә...
Бу шаяру – булса соң мәртәбә
Дөнья-кыл өстендә?!

Саксыз калансак соң?
Бәлки, ул кыл
«Кылдан нечкә» калган?

...Шундый «башсыз» хисләр!
Язмышны шул

Кеше үзе язган...
Шуңа микән,
Хәвеф арткан саен
Сөю үсә һаман?..

Кыл өстендә дә мин аңа ышанам!

* * *

Тагын яндыра сихри көч,
Яндыра минем җанны...
«Егерменче йөз уты!» дип
Юанам? Акланаммы?

Язмышымамы сөенәм? –
(Шулай яратылганмын!..)
Үзем яндыра аламмы
Йөрәкләрне?
Янам – мин...

Яндыра мине нинди көч?
Бер уттан икенчегә
Күчеп барам, һаман янам –
Сүрелә алмыйм – нигә?

Аһ, исән калсам бусыннан,
Дим, кермәс идем кабат! –
Гел ерак йөрер идем мин,
Утларга читтән карап...

Юк шул, утлар Алиһәсе
Әсире итеп тота...
Котылу бармы соң алда? –
Анда да язмыш – утта...

Егерменче йөз язмышы
Дип, әллә юанаммы?!
Ничә мең алда тагы?

Мин – гашыйк Адәм җаны!

* * *

Мәхәббәт шагыйрен таный белегез!
Әй, кешеләр, аңа тик сүз бирегез!
...Янды фирка, байраклар бу гасырда,
Гашыйклар әләме исән – күрегез!

Ут янучы җаннар бар – сез күрегез;
Үзе булып калган алар – белегез!
Дуслары ашты «асманга» – постларга! –
Гашыйкларга тик хискә юл бирегез!

Мәхәббәттә янганнарны күрегез,
Сусаса җаннары – шәраб бирегез:
Җан сусавын басар җыр, хис шәрабы...
Айнымасак без хистән – кичерегез!

Бар гаебең ихласлык булган шагыйрь!
Аңлаган җирдә сине кайсы әмир?!

...Кыз урлаган ирне дә аклаган мир, –
Без дә шул заттан, хакимнәр, белегез!

Мәхәббәт шагыйрен аңлый белегез! –
Сәер җаннарны танып, баш иегез.
Президентлар! Илләр көтә, күрегез:
Мәхәббәт әләмен безнең элегез!

Гашыйклар һаман хак юлда, күрегез,
Ахыргача: – Хәерле юл, – диегез!
Сезнең гөнаһны күтәргән җаннары –
Мәңгелек өчен тик ярлык бирегез!

Гашыйк Гаташ гасыр ахырыннан дәшә:
Мәхәббәт шагыйрен яклый белегез!

* * *

Кайчандыр Син җәрәхәтләгән җанны
Кем ул, кем ул кабат терелткән аны?

Кем кошыма өмет канаты куйды?
Дәртләндерде, биекләргә очырды?

Салкын көннәрендә назлап җылытты?
Тән бит яралы җан кошын онытты...

Шоңкармы бүген исеме? Башкамы?
Заты бүтән, горур: күккә ашкан ул!

...Бүген тагын юлымда Син очрадың...
Бар дөньямны сихри ямьдә нурладың.

Тагын (гаҗәп!) тәндә тойдым Кош-җанны...
Әллә Синме миңа кайтардың аны?–

Кайчандыр үзең чит күргән шул җанны?

* * *

Озын чәчләр дулкын-дулкын... Юлмы ул?
Ике күзең ике тирән күлме ул? –

Тирбәләме якты урман шәүләсе...
Идел-йорт хисенең синме кәгъбәсе?!

Йә син Болгар асыллары нәсленнән
Серме – Сөнгә, Чирмешәнгә яшеренгән?

Әллә бу наз Кыпчактан кайтавазмы?
Яшь ирәннәргә чакыру –
                  авазмы?

Мишәр... нугаймы шәҗәрәң, матурым?
Нинди мирас булып җанга атылдың?

Чәчләрең – тозак: мин аяк-кул җуйдым,
Миңеңә карап,
            илемә юл җуйдым.

Күзләрең тирәнлегендә күңелем,
Буй кыз, сиңа фида, ахры, гомерем.

Бер гыйбрәтме Гаташыңның язмышы?
Читтә, бәлки, ил гаменнән җан, хисе?

Сөембикәләр варисы – милли яр!
Үзең юнәлт дөрес юлга – алып бар?!

* * *

Ул чак күпме бәхәсләштек,
Ярсып ук икәү сөйләштек;
Заманнарны тиргәп аттык...
Соңыннан... хистә аңлаштык.
Башкаемны җуйдым бугай!
Бу җыр башланды ла шулай...

Ул җәй җыры булды, ахры,
Без аерылгач, җанда калды,
Сүзләргә, кәгазьгә күчте –
Күпме сәлам-кошлар очты! –
Иясен тапмады бугай...
Күпме еллар узды шулай...

Җыр башлангач, бар дәвамы...
Очраштырды бу җәй тагы...
Һаман ярсып бәхәсләштек
Йә тынып сүзсез сөйләштек –
Хисләрең тыюлы бугай.
Әллә тормыш куша шулай?!

...Мең дә беренче генәме
Җирдә мондый хикәяне
Өр-яңа дип сөйләгәннәр?
Сөйгәннәр һәм үзгәргәннәр...
Ә без үзгә, үзгә бугай –
Үзгәрмичә янсак шулай?!

Мең дә... миллион да бер катмы,–
Безнең өчен яңа, якты
Җан тарихы, илаһи моң...
Искергәне бармы аның?
Гомер бушка узмас бугай
Моң юлында калсак шулай.

**СӘЕР БЕР УЙ**

Кавышмаса җаның сөйгән җанына,
Әверелмәсә тәнгә (!) яр кочагында,

Бу була, ахры, оялчан хискә «көч»! –
Йә ачуданмы үзеннән «ала үч»:

Хәтта нәфсе дә тартмаган берәүгә
Дәрте җиңә – иреген җуя бәндә.

«Яр» итә ул каргалган бәгъзеләрне...
Андыйлар соң ник үзгә – «назлы» әле?

Мәхәббәтнең яшерен исеме
«җимагъ»мы?
Җанга – җан, тәнгә тән кушылу тик
«оҗмах»мы?

...Йолдызым, син күктән баккан чагында,
Яндырсаң да мыскыл-әр учагыңда, –

Гөнаһлы җиргә, бел, ярың табына:
Йөзен сөртә ул гөлләр тузанына...

* * *

*Әмирхан ага Еникигә*

Бала итте бугай – шаштырды шатлык:
Аксакал белән түбәтәй алмаштык!

– Сезгә, яшькә, килешер, – ди, – укалы,
Ә миңа – бизәксез, гади булганы.

...Чын алтын көз! Уфада – туй дәвамы:
Сиксән биш яшь – морза әдип бәйрәме!

Гасырлардан мирас акыл сүзендә,
Татарның язмышы – моңы күзендә.

«Әйтелмәгән васыять»ләрен әйттеме,
Тарих төпкеленә уйны дәштеме?–

Илле яшьлек йөрәкне кыстым учка:
Очар кебек, әверелеп хәтер-кошка.

«Сөт калыр, Ватан китәр» шул, кызганыч...
Әмма исән рухта өмет, ышаныч.

Инде кыйбла җуймыйча барырсызмы?
Шул «изге сөт, кан»ның сез варисымы?»

...Мин дә хәзер чал чәчле ир бугай да,
Олы гамьнән читтәмен күк шулай да.

Гаҗәпмени – уй ташып, калсам шашып? –
Аксакал белән түбәтәй алмашып...

* * *

Яшерми көн-күздән
Гөлләр үз гөнҗәсен.
Табигать таләбе:
Нурга иркәләнсен,
Кояшка үрләсен.
Әмма кул тимәсен,
Ачылып, ал чәчәк
Җир өстен бизәсен, –
күзәт син...

Тыю мөмкин микән
Йөгрек тау чишмәсен? –
Саф сулар гөрләсен,
Юлы бүленмәсен,
Болганып китмәсен –

Ару тот тирәсен...
Юлыннан агар су, –
чишмә син!

Оялма яшь хистән,
Дәрт янган яшьлектән –
Ачыл бәхетендә:
Матурлый яшәүне
Гөл – үз вакытында,
Сулар – агышында,
Яшьлек – кавышуда,–
дөнья бу!

Табигать канунын
Үзгәртү юк безгә:
Яратылышыбыз
Яратыр өченгә!
Яратылу язсын
Һәр гөл, һәр буй кызга! –
Колак сал бу сүзгә, –
сиңа бу!

* * *

Кай җирне ямьлисең бүген?
Син Сембер ягындамы?!
Ә кемне эзләп сугыла
Бу дөнья давыллары
Җаныма?
Сөюем саклап,
Хыялга китсәм качып, –
Атауда түгел Гаташ, бел,
Дәрьяда синең гашыйк.

Җаныма сыймыйча, нурың
Тирә-юньгә дә күчкән –
Миндә икәнеңне күреп,
Киләме көнче көчләр?

Шулайдыр – кагыла һаман
Җилләре, сихерләре...
Миндә – синең җан... Ә шәүләң?
Авылыңда? Сембердәме?

Онытылган үзеңне эзләп,
Кайт – ялгызлыктан качып.
Мин һаман давыл эчендә...
Нурың яктырткан өчен дә
Адашмый Гаташ-гашыйк...

Бар дөнья яме бул –
Әмма
Җаныңа – миңа ашык!

* * *

Бу – Сиңа кылган дога, бу –
Чын күңелдән догам:
Язмышыңа якты иңсен –
Сакласын ут-судан
Мәрхәмәтле Ходам!

– Раббым, иркә яз гөлеңә
Үзгәрмәс пакьлек бир,
Дөнья керен тидермәслек
Иляһи сафлык бир!

Ялварам, тел ачкычы бир
Сөю-имтиханда...
Үзең терәк бул – ул ялгыш
Атлау ихтималда.

Җирдә сине яклау өчен
Күккә ашсын догам...

Шул догачыңны онытсаң,
Ак өметләрен хурласаң,
Кичерерме Ходам?!

...Бүген күңел – күккә илче,
Ышан: ихлас догам!

* * *

Ир күңеле таш, йомшармаса,
ул таштан су-яшь чыкмас! –
Тик хәмер йомшарта аны –
сәрхуш күңеле яшь тотмас...

Әмма хәмер түктергән яшь
нидән тәмсез, болганчык?!
...Таштан агып чыккан чишмә
якты сулы, саф, ачык...

Зурайгач, болгата ямьсез
уймы күңел чишмәсен? –
Сабый чакта хыяллар саф,
пакь шуңамы күз яшең?

...Исерек уй, хыялдан үзең
еракта йөрт, йә Раббы! –
Юкса гөлләр касәсеннән
нәрсә эчтек – шәрабмы?

Коштай гүя дәва иттек
яшь йөрәккә таң чыгын –
Касә-касә гөл яшен без
эчтек ул чак талчыгып...

...Балачакка кайттыкмы соң? –
күңел – саф, пакь чишмәле...
Яшьләрендә хәмер түгел, –
кыңгырау чәчәк тәме!

## СИНЕҢ МОНОЛОГ-ХАТ

– Син әйт: кайчан кайтыр юлга чыгасың?
Арыдым көтеп, күңелне шом баса...
Колак салам гөрләвекләр тавышына:

Синнән хәбәр булып яңгырый, ичмасам!

Син соң кайчан кайтыр юлга чыгасың?
Куркам: үзгәрсәң, элекке булмасаң?
Яз турында бик яраткан җырым бар, –
Шул җыр да никтер ишетелми, ичмасам!

Син, дим, кайчан кайтыр юлга чыгасың?
Табигать тотрыксыз: юлыңны су басса?
НЛОлар төшә, күбәйде күрәзә... –
Киләчәкне әйтсә икән, ичмасам!

Син әйт, кайчан кайтыр юлга чыгасың?
«Ахырзаман»да гаҗәпме «син ташса»?
Кыйтгалар акса, аерылса халыклар?
Аңлашырга тел-ымнары калмаса?

Бәлки, акылга килербез, ичмасам...
– Тәүбә! – димен, афәтләр юк, булмасын!
Бу каргануым да үземнән узмасын...
Син әйт, кайчан кайтыр юлга чыгасың?!

## ШӘКЕРТ БАБАМНЫҢ ЯШЕЛ ДӘФТӘРЕНДӘ САКЛАНГАН ҖЫРУ

Кәгазем беттеме минем язарга?
Каләмемме тырный... әллә карам юк?
Синнән хәбәрләр көтәм мин, ерак Яр,
Шуңа барсы төшә кулдан – чарам юк...

Хыялымда – таудан төшеп киләсең
Су алырга чиләкләрең белән син...
Чишмә янында сусаган мин ул, Яр,
Бер догадай исемең миңа, беләсең...

Табылды кәгазь дә – ниләр язарга?
Каләм – бар... Гыйшкым батарлык карам да...
Хәбәр бирмисең, татлы яр, бу айда, –
Дәрья-диңгезләр дә юк бит арада...

Шул сәбәпле гашыйгың, бел, тынычсыз,
Җитми җанын дөрләтергә җылы сүз.
Бер кәлимә сүзең көтәм, и Җан-яр,
Тәгам ризык капмыйм, калдым йокысыз.

Бәетләр, кем, җырулар килсә телгә,
Язмыйм – каләм күтәрер көч-дәрман юк...
...Савап микән: «ураза»мын, сине уйлап,
Ә Ходайдан читтә уем һаман ник?

...Гөнаһлымын, бәлки... әмма чарам юк!

* * *

Без кемнәр соң? Ходайдан ваз кичкәннәр?
Күңеленнән иман нуры киткәннәр?

Каян күбәйдек җирдә без – пис ирләр,

Денсез-моңсыз халыклар, кавем-илләр?

Буйсындык соң кайчан без Кара көчкә?
Язмышларны тапшырдыкмы... Иблискә?

Тугач ук – әнкә сөтеннән яздыкмы?
Фатихасыз калдыкмы без – аздыкмы?

Нинди хәл бу – «илдә яхшы калмаса»,
Барчабызны тоташ Дәҗҗал алдаса?

Ялган белән багланса һәр уй, бар эш,
Аң үлсә, җан сүнсә – качса намус?

Без – таш җаннар... бәлки, җансызлар иле?
Ут – рух өрер бер пәйгамбәрме килеп?

Кем уятыр йокы-афәттән шулай?!
Бер Ходаймы? Башка көчләр юк бугай...

Сүз буйсынган, күр, ничек Кара көчкә:
Бу җыр – догам укыла көчкә-көчкә...

* * *

Күренде ул миңа якты рәвештә...
Ак дигәнем, баксаң – кара фәрештә!

...Мәңгелеккә юл ачар пакь яшьлекнең
Дошманын үз итеп күпме яшь түктем;

Ихлас хыял, саф уемнан көлде ул:
«Чын матурлык төнен балкый!» – диде ул.

Шик уятты нурга – табынганыма, –
Юл адаштырды мәхәббәт багына...

Айнып, шашу булды «дәрес» азагы:
Гөнаһ тәме җанда... Вөҗдан газабы!

Уйлыйм хәзер: ничек аңа ышандым?
Гүя изге иманымнан буш калдым.

...Ни гаҗәп! Мин соңлап булса да куган
Шул рух бүген яшьләргә... остаз булган!

Көләләр, әйтсәм: «Ул – кара фәрештә...»
Ахры, кергән тагын изге рәвешкә.

Тагын Иблис менсә күккә – гарешкә?

* * *

Күңел, һаман эзлисең ни? Һәм каян?
Чик булырмы хыялыңа берзаман?

Менә бүген дә синең нәфсең кошы
Әллә бәйдән ычкындымы – әй очты!

Күккәме – юл? Йә җиргә төшәргәме?!
Юл башыннан – чишмәдән эчәргәме?

Үзгәргәндер ул төбәк вакыт узгач...
...Яз иде безнең яшьлектә, нур-кояш...

Соры тузан күмсә ак чәчәк-серне?!
Яшерсә еллар ярны – бердәнберне?..

...Күкрәде күк, яшенләп койды яңгыр.
Гомер керен юаргадыр? Шул фалдыр...

Бер тапсыз ак бит җандагы сурәте:
Җыр язарга – матурлыкка өйрәтте...

Аны бүгенге мохиттән эзлимме?
Яшьлек, синең каргыш төшәр түгелме?

Моңарчы биектә күрдек яр-дусны! –
Нәфестән гел өстен калсын җан кошы!

* * *

Килмәдең... көткәнемнеме белмәдең?
Үзең түгел, сәламең дә килмәде...

Горурлыгың баш бирмиме, башкамы?
Ни булса да, хыял чынга ашмады...

Шулай утка салып мине, кыз бала,
Үртисеңме: – Ян соң, сызлан, йә Алла!

Файда гына сиңа андый сызлану;
Тын күңелне кузгатачак ул яну –

Тойгы җилең белән моң-зар бетәчәк;
Җыр барсын да юып, пакьләп китәчәк...

Борынгылар зирәклеге, ахрысы,
Яшь җанында! – төшә миңа яктысы.

Шуны белепме – бу якка килмәдең?
Көттем: аh, хәтта ки хатта килмәдең...

**БИШЕНЧЕ КАЛӘМ. СИНЕҢ ХАТ**

– Ниндидер көч каршы, ахрысы, миңа:
Бер-бер артлы дүрт (!) каләм белән сиңа
Язмак булдым – тыңламады берсе дә...
Бишенчесе бары буйсынды менә...
Нинди көч соң? Ул нигә каршы миңа?

Әллә уйларым томанлы булганга
Сәер хәлләргә юлыгам бу айда:
Утырсам, арба-автобус туктала
Йә көтмәгәндә нәрсәмдер югала...
Гаҗәп түгелме? Аптырыйм шуңа да.

Яшерен бер көч... миннән үч ала бугай
Сине онытмавым өчен гел шулай...
Югыйсә, әйт, ни сәбәп бар соң моңа:
Шул каләмнәргә кадәр каныксын да!
Яшерен бер көч... көлә, шаяра бугай...

Нидер үрти эштә, өйдә һаман да...
Ямь табалмыйм бу язда Казанда да.
Китәр идем еракларга... ә кая?
Шул каршы көч көтсә мине анда да:
Качып булмаса аңардан кайда да?!

Каләмем, дим, инде син дә сынма, йә,
Түз инде тагын беразга, тыңла, йә...
Бел: кыен бәхетен юллап язганда,
Гүя соңгы өметенә таяна, –
Изге каләмгә ялвара кыз бала...
Карышма, бишенче каләм, ташлама!

## САСНА ПҮЧИНКӘСЕ АВЫЛЫ ЗИРАТЫНДА

Әкрен, әй, җил, тын да тыңла:
Монда – Тукай әнкәсе...
Чишмә җырлый... Гүя ул да
Шул әнкәнең тәңкәсе, –
Йә моңлы чулпы тавышы.
...Кызларның судан кайтышы.
(Тыңла, Шагыйрь әнкәсе!)

Һәр татар кызы баш исен
Бөек Ана кабренә;
Шаулый каеннар... Ул инде
Күчкән халык бәгъренә.
Монда бары кабер ташы
Сөйли: «Тукай әнкәсе...»

Ә чишмәләр тынмый җырлый:
«– Сасна кызлары, исән бит
Мәмдүдәнең тәңкәсе,
    чулпылары?
        Мирас итте
Якты моңын, ак күңелен
Сезгә – Шагыйрь әнкәсе...
Сездә – чулпы, тәңкәсе...»

## 1912 ЕЛ. ЗӘЙТҮНӘНЕҢ ТУКАЙГА БАГЫШЛАГАН ДОГАСЫ

– Мин Сезгә шундый теләкләр телимен:
Язарга теләгән барлык
        шигырь юлларыгыз
Үзләреннән-үзләре язылсыннар –
Яңгырасын җиһанга җырларыгыз...

Тик изгелектән яралсын ул җырлар,
Пакьлектән: иманыгыз – уйларыгыз...

Иң караңгы вакытыгызда да ташламасын
Туганнан алып
Сезне саклап килгән моңнарыгыз!

Мин Сезгә ихлас теләкләр телимен:
Сүрәдәй яңгыраса иде
шигырь юлларыгыз, –
Изге дин белән сугарыгыз!

Кыскартсын юлны иң ерак хыялга –
Йолдызларга җитеп, хис кылларыгыз,
Күкләргә тоташып «уй куллары»гыз,
Шуннан нур белән кайтсын, дим,
җырларыгыз!

Тоташсыннар алар төп яшәеш җебенә –
Уйларыгыз
Чишә алсын чиксез мәңгелекнең серен...

Догада кала татарның бер кызы –
Шагыйремә шундый биеклек телимен!
– Амин! – димен...
Зәйтүнәдер – чын мөселман атым минем...

## БОРЫНГЫ БӘЕТ

Хәятта ачылып капка,
Багка – матурлыкка баксам,
Хыял күлләренә батсам, –
Дәрткә дәрман шул булырмы?

Гөлчәчәккә якын барсам,
Энәләренә кадалсам,
Җаныма җәрәхәт алсам, –
Дәвачы да ул булырмы?

Китә алмыйча шул багтан,
Үз иркемнән әсир калсам,
Күңел җәем багышласам, –
Җимешләрем мул булырмы?

Көз сулышын сизеп беркөн,
Мәңгелеккә җыенсам мин,
Багъ аңлармы актык сүзем?!
Йә тәмам хафа булырмы?
Гөлчәчәк минсез сулырмы –
Гомер-баг капкасын япсам?..

## ЯЗГӨЛ

Галәмнең бу мизгеле –
Син пәйда булган көне –
Якты моңымы язның?!

Ә җыр, дисәм, яулыгың, –
Аны кайда калдырдың? –
Гүя әләмен назның?

Эзләп эзләрдән үттек,
Тапмадык, кире киттек...
Сөйләнде сүзләр – азмы?

Яулык болгап, бу көнне
Озатып булмый инде, –
Яулыкны... җуйдык аны...

Галәмнең гамьле өнен,
Ямь тулы бер мизгелен
Күңелгә уеп яздым:

Мәңгегә ул сөйләсен
Якты көн хатирәсен...
Яулыгың истә, Язгөл!

* * *

Иреннәрең утында дөрләде сүз:
– Хуплыйлармы? Тыңлыйкчы гөлләрне без.

Кичке җиләстә табигать тын калган.
Юк бер афәт гүя, шөбһә бер, ялган...

Күк омтылды Җиргәме? Минем йөзгә?
...Уй дәрьямда ике күз – дөньяң йөзә...

Алышынды анда төсләр, сурәтләр...
Тетрәнеп, читлеген шакый йөрәкләр.

Тоташты соң нинди утлар сулышы?
Үбүме бу – Җир һәм Күк омтылышы?

Шаулады карт тирәк, без арып сыенгач...
Сөендек – иренгә тамчы коелгач...

Төнне сызып үтте синең яшен-сүз:
– Бәхет түгелме? Янабыз... Яшибез!

* * *

Үзең китсәң дә – табигатьтә сүзең:
Көзге урманда йөрсәм дә берүзем,

Ишетәм сине: кыштырдап һәр үлән,
Һәр куак эндәшә синең өн белән...

Алтын төсләр – синең хисләр балкышы,
Таныш сукмакта – карашың яктысы...

Чаган яфрагы ул – йөрәк сурәтең...
Тибәр кебек – бары сулыш өрәсе.

Юк, һәр яфрак синнән сәлам – кулъяулык...
Миләшләрне назлап үбәм – кулга алып...

Бу матурлык безнең җәйдән калганмы?
Вәхи көтсәм, намазлыгым аланмы?

Дога укыйм тезләнеп – күктә күзем...
Өн ишетәм... Валлаһи, синең сүзең!

* * *

Кышкы урманда йортлар бар – ямь-яшел.
Яз төсендәге бер йортта мин яшим.

Тышта карлар... Ә уйда ут: еракта
Ракеталар ява бүген – Гыйракка.

Шул тарафка баккан бар дөнья күзе;
Эсселе-суыклы тора Җир үзе.

Бутаган дин, тел, илләрне сәясәт,
Кайсы дөрес? Кемдә хаклык, йә, син әйт?!

Илемдә кан азмы иде? Җитмиме?
Кан түгеп тә кан дошманлык бетмиме?

Кайда Акыл? Ник берсенең иркенә
Икенчесе кисә юл – гел җилкенә?

Каян синдә, Гасыр, бу афәт ташы?
Хәвеф арта: үз-үзен дөнья ашый?

Табигатьнең җитәрме көч-сабыры?
Нишләрбез, Гаташ – мәхәббәт шагыйре?

Кисмәсме безне нәләт чор кайчысы?
Һаман да уйда Бабичлар язмышы...

Урманда гел «гамьсез» йортлар, ямь-яшел...
Ә дөньяда төсләр күп – белеп яшим!

* * *

Сарылы-кызыллы чор!..
Кызыллы-сарылы көз.
Куакларны ут алган,
Сиңа кабынса, буй кыз?..

Ярда уйный яфраклар.
Кем язган утлы хатлар?

Хис – канатың, оч... Уй-җилкән
Кул астында, йөзеп кит...
Яндырыр кебек хыялны
Көз сулышы... кызу бит!

Чигенә күк Казансу.
Дулкын карашы моңсу.

Бар табигать чуарланган,
Күзләрдә дә үзгә төс...
Күңелеңдә – дөнья, күзәт:
Бәхет нинди төстә, кыз?!

Утын сүндерерме көз?
Җаныңа җитәрме сүз?!

* * *

Сизәсеңме, Гөльяр?
Көннәр кинәттән суытты...
Гөлләр күренеп боекты...
Осланда күк монар...
Китәсеңме, Гөльяр?

Күмелә таныш сукмаклар,
Коела сары яфраклар,
Җил – җан өзгән моңнар...
Ник елыйсың, Гөльяр?

Күпердән җәй үтте... Көздә
Югалырмы безнең эз дә?!
Күңел күнми моңар.
Син ни дисең, Гөльяр?

Яшьлеккә бит көз дә матур.
Алда күпме язың. Кайтыр
Кошлар... төсләр, нурлар, –
Синең гөлләр, Гөльяр!

Ә мин булмасам бу ярда,
Башкалар баш куяр талга, –
Без яраткан җырлар
Гел яңгырар, Гөльяр!

Ә бүген... көзге тамчылар,
Күңелдә яшь катыш гамь бар,
Сары төстә моңнар:
– Гөльяр... Гөльяр... Гөльяр...

* * *

«Карт куенында калач бар...» –
Калач, бәлки, язганым?
«Яшь куенында камчы бар...» –
Аһ, үткән шул язларым!

«Калачыннан бизәрмен...» –
Шуңа җырда ачы моң.
«Камчысына түзәрмен...» –
Гомер, ник тиз агышың?!

Кирәкме син, чал акыл,
Базар узган – юнь хакың.
Мәйданда – яшь йөрәкләр,
Хислерәк, көчлерәкләр...

Өзә җанны бу җырлар:
«Карт куенында калач бар,
Яшь куенында камчы бар».

Яраткач, түзәсеңдер... –
Ник күзеңдә тамчы бар?
Ул да – бәхет яшедер?
Минем калач – ачы зар...

* * *

Сагынсам оҗмах бакчасын, кәүсәрен,
Алдым шуннан мин-Адәм җан җәүһәрен!

Уйда – аң, канны уяткан фирдәвес,
Ничә мең ел! – Юатыгыз, тиргәгез.

Һаман җирдән күкләргә ашса күңел,
Дәшә, бәлки, аннан назлы әнкә тел?

Йә хәтерне тарта изге сөт хакы?
Яратылган туфрагым ни? Күк заты...

Бу ямьле Җир, мең гамьле Җир, моң иле, –
Гел сагынып, яд итсә һаман мине,

Җирме – ватан? Җавап тапмыйм, мин-Адәм...
Тәнгә туфрак – монда, ә рух – Галәмнән...

Ничек онытыйм мин, фирдәвес-кәүсәрем
Калдыргач шунда мәңгелек җәүһәрен?!

* * *

«Тимәскә иде бит миңа –
Кагылмаска иде сиңа...» –
Сүзләрең әллә үрти,
Күзләрең җитди: «Кит», – ди...

...Кагылдым шул кулларыңа, –
Тидемме хис-кылларыңа? –
Чакырып җырлый инде,
Чигенеп булмый инде!

Инде көлә күзләрең дә,
Шул югыйсә сүзләрең дә:
– Тимәскә иде миңа!..
Килмәскә иде сиңа...

Чәнчер энәләрең барын
Оныттым – кагылдым шул;
Табындым да яшьлегеңә,
Үзем дә кабындым шул...

Хәзер җырлыйм үзем менә:
– Тимәскә иде бит миңа –
Кагылмаска иде сиңа... –
Ә синең күзләр көлә:
– Болар бит – сүзләр генә...

## ГАШЫЙКЛАР ШӘҺӘРЕ

Безнең шәһәрдә яшидер сезнең яр, –
Бездәдер: килеп күрегез, дусларым!
Җан бәхетен таба монда гашыйклар, –
Безнең шәһәргә килегез, дусларым!

Безнең шәһәрдә гел ачык капкалар,
Кич-ахшамда да ябылмый, дусларым.
Шам-шәрифкәй ни ул? Җырга шәрәфтә
Моннан артык җир табылмый, дусларым!

Безнең шәһәрдә – асылма бакчалар, –
Бабилдагы кебек – гөлләр, дусларым.
Җырлый кызлар, яңгырый шат авазлар,
Гашыйклар кайгы белмиләр, дусларым.

Безнең шәһәрдәдер сезнең шәһәрьяр, –
Гөлгә охшаш ярлар монда, дусларым.
Җан сөйгәненә түли җыр мәһерен, –
Гаташыгыз күптән шунда, дусларым!

## ЭЧТӘЛЕК


Матурлык эчкән күзләр. *Р.Зәйдулла* ........................

**I. Тел ачкычлары (1972–1978)**

Тел ачкычлары ......................................
Гөлләр елый, улым... ..................................
Уел ............................................
Кунак ............................................
Сәлам ............................................
Биеклеккә карап .....................................
Кая ашыгасың? .....................................
«Хыялымда минем Кояш яна...» ..........................
Тукай урамында .....................................
Дусларча бер киңәш ..................................
«Кемнәрдер бер дәшкән иде мине...» .........................
«Кал җырымда, апрель булып кал син!..» .....................
«Ике урман арасы...» ..................................
«Атлар йөри утлап, атлар монда...» ..........................
«Болытлы көннең кояшы...» .............................
«Карлар яуды, яуды карлар...» ...........................
«Калган гомеремне әйтми сәгать...» ........................
Дөнья бит ........................................
«Нигә куркып яратырга, нигә...» ..........................
«Көзге утлар кабынып ялмадылар...» .......................
«Хатлашудан, бәлки, башладык без...» .......................
Кызыл яулык, кызыл гөлем ..............................
«Нечкәрә күк һаман күңелемдә...» .........................
«Кай төшендә соң син...» ...............................
Элегия ..........................................
Күңелемдә ике яз ...................................
Бәхетле бул!.. ......................................
Аңлашу ..........................................
Язгы ташу ........................................
Алма апа... .......................................
Язлар җиткәч ......................................
Төнге Идел .......................................
Безнең җыр .......................................
Бер хат ..........................................
Йолдыз җавап язмый .................................
«Гомер чишмәсеннән ерак итеп...» .........................
«Җирдә тагын нинди өн?» ..............................
Әгерҗе поезды .....................................
Таяк турында ......................................
«Ничек шулай үзгәрде бу күкшел ярлар?..» ...................
Хыял-рәссам ......................................
Кояш улы ........................................
Латыш укчылары һәйкәле янында ..........................
Бер югалту .......................................
Әмәкәйдә «Гамлет» ...................................

**II. Европада татар шагыйрьләре (1973–1985)**

Француз яулык ......................................
Европада татар шагыйрьләре ..............................
Орлеан кызлары .....................................
Сәяхәттән — мәхәббәт турында ............................
Чит илдән шагыйребезгә хат ..............................
Парижда ..........................................
Луврда, «Яңарыш» залында ..............................
«Ага Сена, ага Сена...» ..................................
Аллоуэйда, Бернс авылында ..............................
Ковентри .........................................
Испания турында җыр ..................................
«Истанбул!..» .....................................
«Азиз Нәсин!..» .....................................
Ташка язылган җыр ..................................
Феникс – үлемсез кош! .................................
Җитмешенче еллар белән саубуллашу ........................
Халкым белән .....................................
Җавап бир, Табигать ..................................
Алибилар булмас ...................................
Олҗаска .........................................
«Әй, суынмагыз, хисләрем...» ..............................
Такташ тавышы .....................................
«Яндырыгыз күперләрне...» ..............................
Яшьтәшләремә – шагыйрьләргә ............................
Озын-озак балачак ...................................
Сөн ярында, авылында ................................
Мөһаҗир .........................................
Чистай кызы .......................................
Тарих өне .........................................
Апалар ..........................................
Бәхетлеләр ........................................
Кырлай юлында .....................................
Җиде баҗаны яклап ..................................
Уянгач ..........................................
Бабич ...........................................
Йөзүчеләр *(Диңгез поэмасы)* .............................


### III. Гомер уртасыннан хатлар (1981–1986)

Яшьлегемә хат ......................................
Бәхет турында хат ...................................
Марс авылы малайларына ..............................
Остазга гимн-хат ....................................
Атлар турында уйлану-хат ..............................
Игенчеләр иленә хат ..................................
Эпилог-хат .......................................
Авыл сәхифәләре ....................................
Моңдашларым, чордашларым ............................
Җавап ..........................................
Маңкортлар .......................................
«Җәй бәхете» бәйләменнән ..............................
Сагынганда. Алтын яфрак ..........................
Статуэткага ..................................
«Ак сафари...» ................................
«Ахры, бераз...» ................................
Язмыш-каләм .................................
«Юк, чакырма мине...» ............................
Якында .....................................
Гәрәбә турында синең җыр .........................
«Хатларың күптән имзасыз...» ........................
Тагын... болан баласы ............................
Яшәү җыры ...................................
Мәрхәмәт ........................................
«Шагыйрьләргә тик илһамчымы син...» .......................


### IV. Йокы юк шагыйрьгә (1986–1990)

Йокы юк шагыйрьгә ..................................
Туганнар .........................................
«Бар ул мөтәдаһи!..» ..................................
«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!..» ............................
Ак һәм кара. 1911 ел .................................
«Югары ул — Тукай биеклеге!..» ..........................
«Кара да гынай урман уртасында...» ........................
«Ничек уйланмыйсың?..» ..............................
«Үпкәнеңнән бирле...» ................................
«Әтисезлек...» .....................................
«Их, ичмасам...» ....................................
«Җир — гаҗәеп...» ..................................
«Җырларыңның һаман искә алам...» ........................
«Кабул итәр микән килер гасыр?!.» ........................

«Яшерен яну диләр...» ................................
Хатын-кызларга җыр ................................
«Борынгылар илаһ-Венераны...» ..........................
Чишмә башында сөйләшү ...............................
Талбазы авылына җыр ...............................
«Нәркисләрең нигә төбәп карый...» ........................
Кышкы идиллия ....................................
«Шундый садә, матур син оялдың...» ......................
«Кемдер, Хыял, бүгенгеңне мактый...» .......................
Былбылга эндәшү ...................................
Ләйләләр язса... ...................................
Уйланганда .......................................
Әй, бөек зар... ......................................
Утыз елдан соң *(хис-поэма)* .............................

**Лирик шаярулар — усал елмаюлар (1965–1978)**

Гаилә әдәбияты .....................................
«Танымыйлар димсең синең кулны...» ......................
Урта кеше фәлсәфәсе .................................
Ганка ...........................................
Йокысыз төн ......................................
Йокла! ..........................................
Күңелгә газәл .....................................
«Белергә тиеш сабагын...» ..............................
«Традицион шигырь!..» ................................
«Нинди яшь идек без...» ...............................

**V. Бу — сезгә кылган догам... (1990–1994)**

Шәрекъчә бер шигырь .................................

Борынгы касә ......................................
«Йә, ничек? Тагын бер калкынып сүнүме?!.» ..................
«Җан дусларым, кардәшләр...» ............................
«Бу җиһанда нинди фал ул...» ............................
«Сасна кызы!» дип кабатлыйм...» .........................
«Кыл өстендә, – дисең, – язмыш, гомер...» .....................
«Тагын яндыра сихри көч...» .............................
«Мәхәббәт шагыйрен таный белегез!..» ......................
«Кайчандыр Син җәрәхәтләгән җанны...» ....................
«Озын чәчләр дулкын-дулкын...» ..........................
«Ул чак күпме бәхәсләштек...» ..........................
Сәер бер уй .......................................
«Бала итте бугай...» ..................................
«Яшерми көн-күздән...» ...............................
«Кай җирне ямьлисең бүген?..» ..........................
«Бу — Сиңа кылган дога...» .............................
«Ир күңеле таш...» ...................................
Синең монолог-хат ..................................
Шәкерт бабамның яшел дәфтәрендә сакланган җыру ..............
«Без кемнәр соң?..» .................................
«Күренде ул миңа якты рәвештә...» .........................
«Күңел, һаман эзлисең ни?..» .............................
«Килмәдең... көткәнемнеме белмәдең?..» .....................
Бишенче каләм. Синең хат ..............................
Сасна Пүчинкәсе авылы зиратында ..........................
1912 ел. Зәйтүнәнең Тукайга багышлаган догасы ................
Борынгы бәет ......................................
Язгөл ...........................................
«Иреннәрең утында дөрләде сүз...» .........................
«Үзең китсәң дә – табигатьтә сүзең...» .......................
«Кышкы урманда йортлар бар...» ..........................
«Сарылы-кызыллы чор!..» .............................
«Сизәсеңме, Гөльяр?..» ................................
«Карт куенында калач бар...» ............................
«Сагынсам оҗмах бакчасын...» ..........................
«Тимәскә иде бит миңа...» .............................
Гашыйклар шәһәре ...................................

Литературно-художественное издание

**Гаташ** Радиф
(**Гатауллин** Радиф Кашфуллович)

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

**В трех томах**

**Том 2**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Гаташ** Рәдиф
(**Гатауллин** Рәдиф Кәшфулла улы)

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

**Өч томда**

**2 том**

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2009.
Форматы 70×108 1/32. Шартлы басма табагы 11,90.
Тиражы 2000 д. Заказ О-9.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.